УДК 387.1

Рецензент

Филология фәннәре кандидаты *С.М.Гыйләҗетдинов*

Төзүчеләр:

Усманов Венер Мөдәррис улы

Гарипова Ләйлә Шамил кызы

**Мәҗид карый Кадыйров. Балаларга бер хатирә...** – Казан, 2022. – 140 .

Китапта заманында Көньяк Урал якларында киң җәмәгатьчелеккә таныш булган, ике мәртәбә репрессиягә дучар ителгән зур шәхес – Габделмәҗид Шәйхелислам улы Кадыйровның (1881-1962) тәрҗемәи хәле һәм «нахак белә гөнаһсыз мәзлүм булыб мәхбүслекдә йөрүе” хакындагы язма истәлекләре тәкъдим ителә.

Габделмәҗид Шәйхелислам улы Кадыйров (1881-1962) – татар җәмәгатьчелегенә кайчандыр Мәҗид карый исеме белән билгеле булган, еллар үткән саен онытыла барган шәхесләрнең берсе. Уфа-Оренбург якларында бүгенге көндә Мәҗид карый турында хатирәләр сакланганлыгы мәгълүм, татар язучысы, галим һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Зәки Зәйнуллинның «Стәрлебаш дөрелфөнүне» исемле документаль әсәрендә ул төп персонажларның берсе буларак урын ала.

Габделмәҗид бине Шәйхелислам бине Габделкадыйр бине Биктимер Казакъстандагы Исәнбай кышлагында 1881 елның март аенда дөньяга килеп, 1962 елда Оренбург шәһәрендә бакый дөньяга күчә һәм Эстәрлебаш зиратында җирләнә. Ул атаклы Эстәрлебаш авылының белемле, үтә дә зирәк, яхшы хәтерле, динле, намуслы, тәвәккәл, сәүдәгәрлек эшенә бала чактан бик сәләтле, зур хөрмәткә лаек мәшһүр шәхесләрнең берсе. Ул тормышы турындагы хәл-вакыйгаларны истәлек өчен һәм гыйбрәт булсын дип, күләме зур булмаган бер кулъязма китапка беркетеп калдыра: «Сәламәт вакытымда үз гомеремдә булып һәм күреп, вә укыган заманларымны белдекем кадәр нәсел вә нәсәбләремне язып, балаларга бер хатирә булсын микъдары илә түбәндә язмакга ният итдем», «нахак белә гөнаһсыз мәзлүм булып мәхбүслекдә йөрүем хакында аз гына язып, балаларыма бер ядкәр һәм гыйбрәт булу өчен бу вакыйганы язып калдыруны уйладым».

Кулъязма өч өлештән гыйбарәт: беренчесендә – «Иман шарты»; икенче бүлеге – үзенең тормышы, туган-тумачалары; өченчесендә – Эстәрлебаш мәдрәсәләре һәм мулла-хәлфәләре турында бәян ителә. Истәлекнең теле – баш өлешендә бераз кытыршылыклар булса да, гомумән, матур, гади,

аңлаешлы һәм төзек. Автор гарәп, урыс, фарсы телләре белән яхшы таныш, ләкин язмаларын саф татар телендә яза, алынма сүзләр белән «баетып» чуарламый. Аның язмаларында үткәннәр хакында уйланулар, балачактагы хатирәләр, авторның уй-кичерешләре, һәм башыннан үткән төрле хәл-вакыйгалар, шул исәптән, тоткынлыктагы авыр тормыш михнәтләре дә тасвирлана. Укыган, истәлек белән таныша барган саен, укучыда автор турында тик уңай фикер-тәэсирләр генә барлыкка килә, хөрмәт арта. Бу әлеге шәхеснең яхшы сыйфатларга ия булуы, бай рухлы, зыялы, чын кеше, хатынына ышанычлы ир булуы белән бәйледер. Большевизм идеологиясе басымы һәм алласызлык хөкеме астында да Мәҗид карый югалып калмаган, бирешмәгән. Ул, шушы авыр дәһшәтле елларда да иманына тугры калып, яраткан хатынына, балаларына вә туган-тумачаларына ышанып һәм таянып, тормыш авырлыкларын җиңеп чыккан. Язмышында күп сынаулар кичерсә дә, ул аңа бары рәхмәтле генә, тәкъдиренә язылганны рәнҗүләрсез, елау-сыкрануларсыз үтә. Кулъязмада үзенең бала һәм үсмер чакларын, мәдрәсәдә уку елларын, Эстәрлебаш авылында гомер иткән тормыш мизгелләрен бик сагынып искә ала, туып-үскән авылына чиксез хөрмәтен, мәхәббәтен белдерә бара. Мәҗид карый нинди генә эшкә тотынса да (сәүдәгәрлекме ул, үзенә йорт салумы, катлаулы гидротехник хезмәт башкаруымы яисә, җәмгыятькә файдалы, игелекле бүтән эшләрме) аның гел, максатчан рәвештә һәр эшне намус белән ахырына кадәр башкара торган булдыклы кеше икәне язмасында күренеп тора.

Мәҗид карыйның тормыш юлы халкыбыз тарихының сикәлтәле, фаҗигале чорына туры килеп, хатирә дәфтәрендә дә бер-бер артлы «болганчык еллар» урын ала. Шушы бер шәхес мисалында гына да тарихыбыздагы аянычлы вакыйгалар – канлы репрессия еллары, күпме чәлпәрәмә килгән язмышларны күз алдына бастыра әлеге кулъязма. Шул чорда кеше булып кала алган, кыйбласын югалтмаган Мәҗид карыйның тәрҗемәи хәле аша гына да күп гыйбрәт табарга мөмкин. Аның белән бергә мәхбүслек ачысын татыган тарихчы Һади Атласи, шагыйрь Сәгыйть

Сүнчәләй, Мәскәү имамы Габделвәдүд Фәттахов, казакълардан юрист Әхмәд Байторсынов, Башкортстанның Кунашак авылыннан Сөләйман мулла, Деникиннан Петроградны саклап калуда катнашкан башкорт полкы командиры Нуриәгъзам Таһиров һәм башкаларның аянычлы язмышлары хакында беркадәр мәгълүмат биргән әлеге кульъязма кыйммәтле ядкәрләрнең берсе буларак санала ала.

Китапның өченче өлеше Эстәрлебаш мәдрәсәләре, аның күренекле шәех-муллалары һәм хәлфәләренә багышланган. Бу бүлектәге мәгълүматларның төп өлеше (автор тарафыннан искәртеп үтелмәсә дә) Мөхәммәдшакир Тукаевның «Тарихы Эстәрлебаш» дип аталган хезмәтеннән алынып, автор аның кайбер урыннарын берникадәр кыскарта, кирәк дип тапкан урыннарда кызыклы яңа белешмәләр өстәп бара. (Мәсәлән, «Хан мәдрәсәсе», «Хәлиулла хәлфә мәдрәсәсе» яисә Эстәрлетамак сәүдәгәре меценат-иганәче Габделхаликъ Мәҗидов һәм башкалар турында). Шунысын да әйтергә кирәк, Мәҗид карый хатирәсе күпчелекне күздә тотмый, бары балаларына гына атап язылганлыктан, хакыйкый чынбарлыкны яктыртуда ниндидер күпертүдән азат, яки, киресенчә, кайбер кешеләрне сыйфатлаганда, аерым хәлләрне тасвирлаганда тыелып калу да бирелә юк.

Кульъязма истәлек дәфтәре, мәдрәсә елларыннан ук килгән матур үрнәк булып, гади дәфтәрләргә каралама рәвешендә язылып, акламага күчерелмичә төпләнеп, пөхтә итеп катыргы белән тышланган. Соңрак ул, мәрхүм Мәҗид карыйның балалары тарафыннан яңадан, икенче кабат, китап рәвешенә китерелеп төпләнгәндер дип уйланыла, чөнки, аерым-аерым өлешләрен ябыштырып ныгыту өчен кульъязма дәфтәрләрнең чит-кырларын тигезләп кискәндә, текст юлларының кайберләренә зыян салынган – алар төп өлешкә керми калганнар. Бигрәк тә, теге яки бу вакыйгаларга кагылышлы күпсанлы, кыска-кыска гына, бер яки берничә битлек өлешләргә бүленгән текст атамалары китапны төпләгәндә киселеп төшеп калган.

Аңлашыла ки, бу язма ядкәр көндәлек дәфтәр түгел. Мәсәлән, китапның икенче өлешен тәмамлаганда: «Яздым 1955 ел миляди, үктәбер

аенда, 1375нче һиҗрия дә рабигыль-әүвәл аенда, Күмертау шәһәрендә» дигән мәгълүмат беркетеп куелган. Текстлар башыннан азагына кадәр тотрыклы рәвештә пөхтә, аңлаешлы итеп язылмаган. Урыны-урыны белән я кара, я карандаш белән төрле кимәлдә (укылышлы һәм киресенчә – аерым урыннарда хәрефләре күренмәс хәлгә төшеп-бозылып, бөтенләй җуелып) беткән. Әлбәттә, бу күренешләр инде олы яшьтәге авыру, гомерендә күп афәтләр кичергән кешенең кәеф-сәламәтлеге торышына турыдан-туры бәйле булып, шулай язылгандыр. Автор язмасын бүлекчәләргә бүлеп, исемләп тә барган. Мәсәлән, «Атамыз белән Казакъстанга баруым хакында», «Истанбулда булган вакытымда», «Мәдинәи-Мөнәүвәрә сәфәре» һәм башкалар кайберләрен автор кире кайтып, өстәмәләр рәвешендә дә билгеләп чыккан.

Мәҗид карыйның язу үзенчәлекләренә карап, түбәндәге фикерне дә әйтергә кирәктер: ул бик төпле белемле вә чит илләрдә укып, мөселман мәдәниятенең югары сәнгать әсәрләре белән якыннан таныш булса да, аның матур язу «осталыгы» чамалырак булгандыр дигән нәтиҗәләр ясала. Шул сәбәпле, аның кулъязмасы зәвыклы итеп, каллиграфик үрнәкләр дәрәҗәсендә башкарылмаган, бәлки андый максат та куелмагандыр. Якыннарына хатирә калдыру, нәсел тарихын, нәсел җепләрен югалтмау, үз тарихы мисалында, бер шәхес мисалында халкыбызның яшәеше, гореф-гадәтләре, фаҗигале язмышыннан гыйбрәт, үткәннәрдән сабак алу, тарихыбызны онытмау өчен дә кулъязма, чын мәгънәсендә, тарихи документ ролен дә үти. Ике тапкыр репрессия афәтен кичергән кешенең тәрҗемәи хәле бер шәхеснең генә түгел, илебез тарихындагы афәтләрне, халык кичергән михнәтләрне гомумән күзалларга да ярдәм итә. Шулардан иң канлы ГУЛАГ фаҗигасе, «халык дошманы» дип нахакка әрәм ителгән гомерләр хакында кешелек онытырга тиеш түгел.

Кулъязманы уку барышында авторның язу стиле сакланды. Кайбер урыннарда истәлекнең бозылган, инде укырга мөмкин булмаган өлешләрендә, шулай ук төшеп калган кушымча, сүзләр квадрат җәяләр

эчендә бирелде, авыр аңлаешлы гарәп-фарсы сүзләренә астөшермәдә аңлатмалар биреп барылды. Кулъязмада еш кабатланып килә торган, укучы өчен укыганда чуарлык тудыра, фикерне чуалта торган кайбер гыйбарәләр дә төшеп калды, алар шулай ук квадрат җәя эчендә күрсәтелде.

Мәҗид карыйның киләчәк буыннарга тәгаенләнгән гыйбрәтле хатирәләре кадерләп сакланыр дигән теләктә калабыз һәм Уфа шәһәрендә яшәүче Г. Кадыйровның оныгы – Зөһрә Габделхак кызы Вәлиулловага чиксез рәхмәт сүзләребезне җиткерәбез.

*В.М.Усманов, Л.Ш.Гарипова*

Статья посвящена изучению жизнедеятельности признанного религиозного деятеля из с. Стерлибашево Кадыйрова Габделмаджида Шайхелисламовича (более известного в народе под именем «Маджид карый») через призму анализа его рукописной тетради с воспоминаниями. Долгие годы ценный материал бережно хранился у дочери М. Кадыйрова Марьям Мазитовны, потом, у внучки Муниры Мухсиновны в г. Оренбурге и в данное время в г.Уфе у Валиулловой Зухры Габделхаковны. В 2019 г. З. Г. Валиуллова передала нам копию тетради для дальнейшего последовательного и детального изучения. Состоящая из 243 страниц рукопись на татарском языке (на арабской графике), по тематическому принципу разделена на несколько частей, включая раздел религиозного содержания, история Стерлибашевского медресе и отдельная часть, посвященная воспоминаниям из жизни (начиная с ярких впечатлений детства, отрочества, путешествия в священные для мусульман земли Саудии, заканчивая записями о тяжелых годах репрессии). Эти памятные события, в свою очередь, своим смысловым контекстом показывают и описывают не только жизнь одного конкретного человека, но раскрывают сущность целой эпохи, надежды и чаяния, боль и обиды практически каждого жителя страны,

кому пришлось столкнуться с необоснованным обвинением в «измене родине» и получением ярлыка «враг народа». Вниманию читателей также предлагается наиболее трагичный и в то же время интересный в историческом плане фрагмент из дневника – записи о Гулаге.

*Язу калыр кәгазьләрдә заманлар буенча*
*Язучысы туфракда черегән булыр.*

Нахак бәла, гөнаһсыз мәзлум булып[1] мәхбүслекдә йөрүем хакында, балаларыма бер ядкәр һәм гыйбрәт булсын өчен, бу вакыйганы язып калдыруны уйладым.

Әмма бәгъдә[2] фәкыйрь сәламәт вакытымда үз гомеремдә булып һәм күреп вә укыган заманларымны, белдекем кадәр нәсел вә нәсәпләремне, балаларга бер хатирә булсын микъдары илә түбәндә язмакга ният итдем. Тугмыш атамыз Шәйхелислам бине Габделкадыйр бине Биктимер иске вакытда Уфа губернасы Минзәлә өязе Александр-Карамалы вулысы Татар Карамалы авылында 1843 нче елда тугмышдыр (хәзерге көндә Татарстан җөмһүрияте Сарман районының Татар Карамалысы авылы). Кадыйров фамилиясе бабамыз Габделкадыйрдан башлана. Габделкадыйр бабамыз вафат булгандан соң, атамыз, ничә яшендә калгандыр, бертугма агасы Габделгалим тәрбиясендә калмышдыр. Габделгалим шушы Карамалы авылында мөәзин булып гомер кичермешдер. Вафаты 1896 елларда булса кирәк. Карамалы мәкъбәрәсендә мәдфүндер, язулы ташы да бар иде. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Бу Габделгалим агамызны үзем сәламәт вакытымда күреп беләмен һәм атамыз сәламәт вакытында безем Эстәрлебашына килеп кунак булып китмеш иде. Тормышы яхшы гына, такта белән ябылган бер йорты һәм алдында яхшы гына бакчасы да бар. Бакчасында байтак умарталары бар иде. Мөәзинлек, игенчелек белән кәсеп итәр иде. Хаҗәтенә йитәрлек ат вә башка сыер вә сарыклары да бар иде. Йортының койрыгында ындыры бар. Шушыларны беләм. Авылдан читдәрәк умарталыгы һәм бар иде. 12 яшемдә атам мәрхүм белән барган вакытымда мине, бал алырга умарталыкга барып, анда арыш икмәгенә бал ягып биргәнне бик яхшы беләмен. Хода гомеремә бәрәкәт бирсә, балалары хакында бер шәҗәрә язсам кирәк. Атамыз Шәйхелислам 20 яшьләр чамасында Ык буенда Олуг Чакмак карьясендә мөдәррис Габдулла Гафуров хәзрәт мәдрәсәсендә берничә еллар укып, соңра Эстәрлебаш мәдрәсәсенә килеп, Бөгелмә өязенә карашлы Бәйрәкә авылындан килмеш Хәлилулла бине Рәхмәтулла бине Хәсән мәдрәсәсендә берничә еллар укып, шунда торып калмышдыр. Анамыз мәрхүмәнең атасы Вәлиулла бине Рәхмәтулла бине Хәсән мәзкүр Хәлилулла белән бертуган буладыр. Фәкыйрьлек хәлендә булу сәбәпле, укулар беткәннән соң, яз вә җәй көнләрендә урак-печән эшләрендә эшләп, кыш көнендә үзенә хәраҗат хәзерләп укымышдыр. Бәйрәкәдә тормыш, Вәлиулла Рәхмәтулла углы вафат булу сәбәпле, гаиләсене агасы бабамыз Хәлилулла

[1] Мәзлум булып – рәнҗетелеп.
[2] Әмма бәгъдә – шуннан соң.

хәлфә барып, Эстәрлебашка үз тәрбиясенә алып кайтмышдыр. Шундан, 1875 нче елларда улса кирәк, үзенең агасы Вәлиулла Рәхмәтулла углының кызы, минем тугма сөт анам була, Галимәне атамыз Шәйхелислам Габделкадыйр углына кияүгә бирмешдер. Мондан соң атамыз, анамыз белән бергә, шул ук 1877 нче елларда Әстерханга карашлы Бүкәй иле дигән, Казакъстан мәмләкәтенә Сары Үзән суы буенда Таловка дигән урында Исәнбай дигән кышлакда торып калмышлар. Атамыз ир балалар, анамыз кыз балалар укытып, 1882 нче елга кадәр торып, янә Эстәрлебашка күчеп кайтканлар. Фәкыйрь шу йирдә март аенда 1881 нче елда тугып, ике яшемдә бергә Эстәрлебашка кайтканмыз. Шунда атамыз 40 сәнәдән артык Эстәрлебашының эшче вә никрут-фәлән балаларын ахыр гомеренә кадәр укытып, 1918 милади, 1336 һиҗри елында 2 нче май чәһәршәнбә көн көндез сәгать икедә әманәт җанны Җәнабе Хакга тапшырмышдыр.

Эстәрлебашның олуг мәкъбәрәсендә Нигъмәтулла Харис хәзрәт вә Зәйнулла хәзрәтләренең төрбәләренә якын, үзем сәламәт вакытымда, мәрхүм анамызны аяк очына бер-беренә аяклы-очлы дәфен кылындылар. Күпчелек белән җеназасыны мәхәлләмезнең олуг имамы Габдулла бине Мөхәммәдхарис бине Нигъмәтулла укып, 4 нче май көнендә 6 нчы шәгъбанда җомга көн кич сәгать 6 да гүр иясе булдылар. Зияратына язылмыш ташында ошбу рәвешдә “һазә мәркаде әл-галим әл-фазыйль әл – камил мөгаллим әс-сыйбъян матә әрбәгыйн сәнәтә Шәйхелислам бине Габделкадыйр бине Биктимер фи сәнәти өлеф вә сәләс миәт сит вә сәләсин мин әл-һиҗрия (1336) вә фи сәнәти 1918, 2 нче май, таибә Аллаһ сәраһү вә җәгаләл-җәннәтә мәсваһ”[1]. Атамызның тормышы Эстәрлебашында иген игәрлек йиргә хуҗа булмаган сәбәпле исә, борынгы канун буенча читдән кешеләргә йирле халык белән бәрабәр җир бирелмәде, шулай да булса, бер-ике десятинә җир иҗарәгә[2] алып яки берәү белән уртак булып, үзенә йитәрле иген сачеп торган. Тормышына бер сыер, бер кәҗә булыр иде. Бәгъзе вакытда бер аты да булыр иде. Боны да җәйлек хаҗәтне үткәрер өчен яз башында алып, кышлык утын вә печәнне хәзерләп, көз көнне сатар иде. Каралтысы – алты почмаклы бер өе, бер мунча, бер келәт – һәммәсе агачдан, маллары өчен абзарлары бар иде: “Тора торган өемез, йортымыз олуг мәсҗед тугрысында тау буенда, йортымызның арты тауга чыгар иде. Мәсҗед белән йорт арасында мәдрәсәләр булыр иде”. Утынны үзе кисеп, печәнне үзе чабып, үзе ташыр иде. Ике елда бер мәртәбә барып, үзенең укытып торган йиренә ат

[1] Бу галим, фазыйл һәм камил балалар укытучысы Шәйхелислам бине Габделкадыйр бине Биктимер кабере. 1336 (1918) елның 2 нче маенда вафат булды. Аңа Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте иңсен һәм урынын җәннәттә кылсын.

[2] Иҗарәгә – факытлы файдалануга.

белән барып кайтыр иде. Бүкәй иле Казакъстанда Таловка дигән йирдә мәшһүр Исәнбай авылыдыр. Эстәрлебашындан йиде йөз километр озаклыгындадыр.

***Атамыз белән Казакъстанга баруым хакында.*** Шушы йиде йөз километрлык йиргә 1889 нчы елда үзе белән мине һәм алып барыр иде. Барган вакытымызда Тук суы аша үтеп, Сарутинский станциясендән Уральскига, андан казакъ сахрасы белән 300 чакрым бардык. Яланда кунып барыр идек, чөнки юлымызда чабан – мал багучы казакъ өйләре булса да, алар янында кич йокларга тугры килмәс иде, чөнки өе тирәсендә атка ашатуга үлән булмас иде. Малчыларның өйләрендә туктап, коеларындан, булмаса, өйләрендән яланда кайнатыр өчен су алып, катык вә кымызларын эчеп, 4-5 километр еракка китеп ятыр идек. Бу вакытда мин сигез яшемдә идем. Барып туктавымыз белән мин, бакыр чәйнек алып, тирес белән ут ягып, чәй кайнатырга тотыныр идем. Атамыз исә вакытлы газета укырга тотынып, газетны [укып] бетерүгә чәй кайнатып, тын сахрада һич тавыш юк, тик малчы казакъларның ат тавышлары гына ишетелмәкдә иде, рәхәтләнеп чәемезне эчеп, мине йоклатып, үзе йокламый төнлә атны саклап чыгар иде. Таң беленү белән атымызны җигеп, янә юлымызга китәр идек. Бу йирләрдә көнләр бик эссе булу сәбәпле, иртә-кич салкын белән йөреп, көндезендә ял итәр идек, тәртәне күтәреп күләгә ясап, атамыз бераз йоклап алыр иде. Мин булсам, ат карап утырыр идем. Бондан соң Ялпактал (Сламихин) дигән казачий халыкларның столицасы мәшһүр иде (Уральски обласе). Монда Эстәрлебашында тугып үскән Гобәйдулла бине Зәйнулла Галикәевнең йортына төшдек. Эстәрлебаш Зәйнулла ишанның углыдыр (Әмир ишан дип мәшһүрдер). Бу Гобәйдулла хәзрәт әүвәлдә Эстәрлебаш мәдрәсәсендә тәхсил кылып[1], соңра Бохарага барып, ишанлык дәрәҗәсене алып кайтмышдыр. Кайтканның соңында боны мәзкүр Ялпактал әһалисе имам кылып алмышлардыр. Соңра бу Гобәйдулла хәзрәт, мәдрәсәләр салдырып, күп кенә казакъ шәкердләренә дәрес биреп, һәм мәшаехлек юлыны кыладыр. Миһманпәрвәр[2], сәхи[3], халыкга мәхәббәтле адәм иде. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Монда берничә көн кунак булып, әүвәл максад булган Таловкага Исәнбай авылына сәфәр итдек. Мондан 60 чакрым йир иде.

### *Казакъстанга барып йитеп, укуга башлавым хакында*

Юлда атамызның шәкердләре булган Госман, Ногман исемле, шуларның аталары Субиргән дигән казакъ авылында кунып, икенче көн

---

[1] Тәхсил кылып – белем алып.

[2] Миһманпәрвәр – кунакчыл.

[3] Сәхи – юмарт.

Исәнбай авылына барып җиттек, ул вакытда бу авылның адәмләре, казакълар гадәтенчә, Ликрәм дигән күл буенда киез өй белән аккош кебек тезелеп, күлне әйләнеп, җәйләүдән кымыз эчеп, куй ашап, күлдән үрдәк атып, кәеф-сафада торалар иде. Монда килү белә Мөхәммәдгали Исәнбаев өенә төшдек. Казакъча ләкабе Кәлүшиндер. Без бару белән үзләренең өйләренә – бер 10 таяк чамалы булыр иде кунакханә, бәләкәй генә киез өй иде – икәвемез киткәнче шул өйдә тордык. Барып төшкәч, казакъ карчыклары мине күрү белән: “Уй-бай бәнагый, үземезнең кулымызда туган баламыз гуй, туган йиренә сагынып килгән гуй” – дип, мине кочаклап үбделәр. Бер карчык: “Ир туган йирендә, эт туйган йирендә” дип әйткәнләр гуй” - диде. Аркамдан сөеп, сау-сәламәт дип сораша башладылар. Мин дә әйткәнләренә җавап бирә бардым. Монда ике [ай] чамасы торып, соңра сентябрь айларында Эстәрлебашына кайтып, сәфәр итдек, сәламәт кайтып җитдек. Укый башлавым биш яшемдә вакытымда: өйдә атамыз әлифба, соңра “Иман шарты” дигән китапны укыта башлады. Андан бәгъзе төрки китапларга кушды. Алты яшемдә “Кәлям шәриф” укытам [дип] ишан хәзрәткә - мәшһүр хәзрәт, мөрид булып килгән Бәләбәй өязенә карашлы Ык буе Сарлы авылының Әхмәдша хәзрәт иде. Тәбәррек[1] яхшы хәзрәт дип, шуңардан “Кәлям шәриф”не укырга башладык. Хәтеремдә ярты гына “Кәлям шәриф” иде. Анам мәрхүм хәзрәткә хәергә бирерсең дип, кулыма йикерме [тиен] акча тотдырып чыгарды. Һәркайусы Аллаһның рәхмәтендә булсынлар, амин. Шундан соң әткәм белә бергә үзенең мәдрәсәсенә алып йөри башлады. Андан гарәпчә китап укы дип, “Шорутес-салават”, осуле “Әт-тәүхид” дигән китапларны төшендем. Бу китапларны бераз укыган соң, гарәпчә таный инде дип, 7 яшемдә Габделкәбир хәлфә Динмөхәммәд углы (Эстәрлебашка 20 чакрымлык Тәтер Арыслан авылындан килмешдер) - бу хәлфәдән углы Габдулла, Габдеррәхим бине Әмирхан Ибраһимов – өчемез бергә, 1896 миладиядә сарыф укый башладык. Шушы елларда остазымыз Габделкәбир хәлфә, ашказаны белән авырып, август аенда 1317 һиҗриядә вафат булды. Мондан соң Фәтхулла хәлфә Фәттахетдин углы Дим буе Усак Кичү авылындан килмеш – барча шәрикләремез бергә шушы хәлфәдән дәрес укый башладык. 1902 нче елдан башлап 1904 нче елга кадәр Эстәрлебашында “Русско-татарская школа”да укып, шәһадәтнамә алдым, учителемез Макар авылының Мирсәид Баишев дигән кеше иде. Ун яшемдә вакытымда хәреф вә нәхү, фикъһ китаплары укый башладым. Нәхүдән “Шәрхе мулла”, фикъһедән “Мохтасарел-викая”, “Гайнел-гыйлем” кеби китапларны укып һәм дә Эстәрлебашында олуг мәдрәсәләрдән саналмыш Хәбибулла Мөхәммәдхарис

[1] Тәбәррек – хөрмәтле.

углы Тукаев җәнабләренең дәресенә дәвам итә башладым. Монда укыган дәресләрем “Шәрхе мулла” (“Мулла җами”), “Тарикаи Мөхәммәдия”, “Гайнел-гыйлем” кебек китаплар иде. Шушы вакытым яшь кенә бала булсам да, сакаллы зур шәкердләр белән бәрабәр укыр идем. Яшь булсам да, хәлфә, балалардан беренче укучы дип, күблек алдында мактап, минем дәрәҗәмне күтәрер иде. Һәрвакыт  хәзрәтләрнең ифтар мәҗлесләренә һәм бәйрәм ашларына яхшы укучы бала дип әйтеп, ашка чакыра иделәр. Әй мин фәкыйрь дә, сакаллы хәлфәләр һәм зур шәкердләр белән бергә ашка барып кайту вә кәефләнеп мәдрәсәгә кайтып, мактанып йөрер идем. Мәрхүм остазымыз Хәбибулла хәзрәт, декабрь ахырларында булса кирәк, Эстәрлетамакка барып суык тиеп кайтып, тир авыруы белән авырып, берничә көндән соң ахирәт йортына юнәлде. Мәхдүм остазымыз бик халис[1], тәвазыйглекле,[2]  чын галим бәндәләрнең беренче табәкасендә[3] дияргә ярый, һәртөрле фөнүндән хәбәрдар улмыш иде. Әүвәлдә Бәләбәй өязе Ык суы буенда Олуг Чакмак карьясендә мәрхүм Габдулла хәзрәт Габделгафуров мәдрәсәсендә укымышдыр. Соңра, Бохарага барып, ничә еллар тәхсил идеп һәм Ниязколый әт-Төркмәни хәзрәтләрдән гыйльме тарикаига иҗазәт[4] алып кайтмышдыр. Эстәрлебашына кайту белән, беренче нәүбәтдә, мәдрәсәләрне вә мәсҗедләрне яхшы рәвешдә төзәтеп, мәдрәсә араларына агач ултыртып, бик яхшы кылды. Соңра мәдрәсәдә олуг хәлфәләргә дәрес укый башлап, бөтен фикерне гыйльме заһирне рәваҗләндерү[5] булып, голүме батыйн белән мәшгуль булмады: “Беренче голүме заһирне яхшы белү кирәк, бу тәмам булгач, голүме батыйны белән шөгыльләнергә мөмкин” дип әйтер иде, чөнки голүме заһир савытымызны әүләнә савытны яхшы тазалагач, голүме батыйнны салырга мөмкин дия иде. Шул сәбәпле, ишанлык берлән шөгыльләнмәде. Бөтен фикерне голүме заһирдә һәрвакыт бөек галимләремезнең әсәрләрене, бигрәк Шиһабеддин Мәрҗани хәзрәтләренең “Вафиятел-әслаф”, “Назурәтел хак”ны моталәга кылып[6], һәрвакыт шәкердләргә  сөйләр иде. Хәтта Пушкин җәнабләрене чын шагыйрь дип, аны хөрмәт кылыр иде. Янә кайтып, үземнең хәлемә киләм. Атамыз, фәкыйрьлек белән тору сәбәпле, миңа бәгъзе вакытлар мәдрәсәдә укыганда кәгазь-каләм, тиешле китапны алу кыен иде. Ипдәш арасында бик ким булып йөрер идем. Атамыз атнага бер мәртәбә, иске гадәт буенча, атна кич булса, хәлфәгә бер тиен я ике тиен, хәтта ярты тиен дә булыр, барысы 60, 70 тиен кадәр булыр иде, атналык вазыйфа шул

---

[1] Халис – чын, саф.
[2] Тәвазыйглекле – тыйнак.
[3] Табәкасендә – дәрәҗәсендә.
[4] Иҗазәт – рөхсәт.
[5] Рәваҗләндерү – алга җибәрү.
[6] Моталәга кылып- өйрәнеп.

иде. Шул акча белән атналык тормышны үткәрергә кирәк. Шул сәбәпле, миңа кайдан артдырып бирсен. Монда җирләнерлек юк, бәгъзе вакыт базардан бер табак, ике табак алып кайтып бирсә, куанычымдан башым күккә тияр иде. Өс-баш туңмаслык бар, аякда пима, бәйләм оек, табан ямаган, боңарга да шөкер. Шул хәлдә булып да мине укытырга тырышдылар, Аллаһның рәхмәтендә булсыннлар, амин. Һич мине йорт эшенә кушмады, абзарны, сыерны разый карар иде. Миңа башка нәрсә тик – укырга. Мәдрәсәмез, өемезгә якын булу сәбәпле, аш-чәй вакытында йөгереп кайтып кына ашап-эчеп китәр идем. Шундан соң ничек дә булса кәгазь-каралык бер эш табып, шуның белән укуны дәвам итдерергә кирәк иде. Югарыда язылмыш шәрикем Габдеррахман белән икәвемез шәрик булып, икәвемезгә 80 тиен сумма табып, аз-маз каләм-кәгазь кебек нәрсәләр белән мәдрәсәдә сораган шәкердләргә сатар өчен сәүдә итә башладык. Атнада бер генә базар булу белән башка көннәрдә мондай кирәкле нәрсәләр табылмый калыр иде. Базарда 80 тиен суммага тиешенчә кәгазь-каләм, кара алып каламыз да, атна арасында апдыраган шәкердләргә сатамыз, атнада 15-20 тиен файда кыламыз, димәк, үземезгә кирәк кадәр кәгазь-каләм, кара була. Шундан бер көн хәлфәмез мәрхүм моны сизеп калып, безләргә шелтә бирде: укыган кеше мондай эшне мәдрәсәдә кылмагыз дия, шундан соң хәлфәмезнең шелтә бирүенә буйсынып, мәгазинемезне ябарга тугры килде. Бер-ике көн үткән соң сәрмаямызны[1], калган товарларымызны бүлешеп алдык да, һәр икәвемезгә 80шәр тиен акча булды, вәссәлам. Инде ничек  кирәклек акча табарга? Бу вакытда яхшы гына язу яза идем һәм дә китап төпләү, күзлек һәм каләм савыты кебек футлярлар ясый идем. Шулай итеп, бәгъзе китаплар язып, борын заманда булган сугыш бәетләрене язып, тузган Корьәнләрне төпләп, биш-ун тиен акча таба башладым. Шундан соң атамыздан кәгазь-каләм акчасыны сорамый башладым. Шулай ничек дә булса бер һөнәр табып, укуымны дәвам итдереп бардым. Яшем 15-16 килгән вакытымда аз гына кеше арасына керә башладым. Инде бу вакытда кешенеке кебек кием вә башка-аякга башка заманчарак кием киясе килә башладым. Әлбәттә, атамыздан боларны сорар оят, алар тектереп бирсәләр дә бик иске рәвешдә, борынгы кебек текдерәләр, башка шәкердләрнең заманчарак булуындан, мин дә шундай киясем килә. Ипдәшләр аякларына читек-ката киеп йөриләр, бәйләгән оек табанына күн салынган. Андан биш вакыт намазга һәр тәһарәт алган саен аяк юарга тиешле булу сәбәпле, кыш тышда суыкда бик кыен була иде.  Кайтып, атамыз мәрхүмгә читек тектереп бир дип еглаган идем, бичара, юкны бар кылып, беренче мәртәбә читек текдереп бирде, Аллаһның

---

[1] Сәрмая – капитал, байлык.

рәхмәтендә булсын, миңа мондан зур шадлык булырга тиешле улмас кеби куандым. Шадлыгымны бер хода беләдер. Мин башка шәкердләр кебек аяк юмый гына хөсне тән кылып, тәһарәт алып, мәсҗедкә йөри башладым. Шулай итеп, уку вакытны үткәрә башладым. Инде яз көне ни эшләргә кирәк, иген бик сәчелә, ялан эше юк, янә кыш мәдрәсәдә үткәрергә бер чара кирәк дип уйлана башладым, чөнки башка балалар кебек күп уйлап йөрергә күңелем бик аз төшә иде. Шундан уйлап, аз-маз акчам белән, булмаса, этидән алып, кулга кәрзинкә алып, җәяүләп, күрше башкорд авылларына барып, акчага күрә күкәй алып кайтып, зуррак күкәй белән сәүдә кылучыларга бирер идем. Алар миңа бер йөз күкәйгә 15-20 тиен файда бирерләр иде. Шулай итеп, көн дә ике җыеп кайтам, 30-40 тиен эшләр идем, башка минем кебиләр көненә 8-10 тиен печән җыярга, күче белән тартдырырга  йөрерләр иде. Әлбәттә, мин боларга караганда күбрәк эшлим. Авылларда башкорт хатынлары: "Безгә лимон табып алып кил, эсседә чәй эчәргә лимон табдырмай, моңа без сиңа күкәй эзләп куярмыз", - диләр иде. Шулай итеп, миңа янә бер сәүдә юлы ачылды. Базар көнләрендә Уфадан Шафранлардан лимон-әфлисун сатучылар килер иде. Шулар белән танышып, сөйләшеп, миңа базар хакындан кимрәк кылып: "Акчама йитәрлек лимон бирсәгез икән , - дип сорадым, - "Ярый, бик яхшы, бирермен", - диделәр. Күбрәк бирергә дә мөмкин, акчасыны икенче базар бирерсең, - диярләр иде. Бер 40-50 лимон [лык] акча алып калдым да, икенче көн янә күрше башкорд авылына барып, лимонны күкәйгә алышдырып кайтыр идем. Бу вакытда күкәй бер дистәсе 10 тиен, лимон 5 тиен булыр иде. Бер дистә күкәй белән 1 я 2 тиен калса, бер лимондан бер тиен яки ике тиен эшләр идем. Шулай итеп, оборот ике яклы булып китде. Иртән җәяүләп китеп, кич кайтам: бер сум я артыграк эшли башладым. Нәфес инде күбрәк табарга керешә башлады. Янә бер фикер килде, көнгә фәлән йиргә барып кайтырга бер ат яллап, ераграк рус авылларына йөрергә уйладым. Көненә 50 тиенгә ат табып була иде. Рус авылларында йөреп, 500 йөз, я кайчакта, бер мең алып кайтыр идем. Кайтам да әлеге кешеләргә тапшырам. "Молодец, күбрәк җый", - диләр иде. "Җыяр идем дә, акча аз бит" - дидем. "Кирәк булса, азрак акча бирермез" - диләр иде. Ярар алайса дип, икенче көн тагын ат алып авылларга китәм дә, ике мең, өч мең җыеп кайтам. Шулай итеп бу җәйне үткәреп, көз мәдрәсәгә 10-15 сумма берлән кердем. Хәзер бай булдым инде, 15 сум акча булды. Ул вакыт боңа бер сыер алып була иде. Шулай да булса, кайбер көн атамыз мәрхүм кешегә печән җыярга, чүмәлә тартдырырга көнлеккә йибәрер иде. "Ялан эшләрен дә күреп өйрән, синең акчаң миңа кирәк түгел" дияр иде. Көнлек хакы 10-12 тиен булыр иде. Янә икенче [ел ] килде, укырга керергә вакыт йитде. Шәрикләремез чит авыллардан килделәр, укуны башладык. Исәп шул:

15-20 сум акчаны кыш мәдрәсәдә хәраҗат кылам, янга тагын акча кирәк булыр дип, ничек дә булса бер нәрсә эшләргә кирәк тотам. Октябрь 20 сендә Эстәрлетамак ярминкәсенә барырга уйлыйм, каникул көн барып кайтырга буладыр. Барам да, ярминкәдән шәкердләргә ярарлык кәгазь, һәртөрле кара, хушбуй, сабын, исле кулъяулык кебек – акчам йитәрлек товар алып кайтып, мәдрәсәдә шәкердләргә сатар идем. Шулай итеп, суммасыны саклап, язга чыга идем. Яшем 16-17ләргә җитеп калды. Яз булды, укулар тукталды. Чит шәкердләр бар да авылларына китеп калдылар. Инде миңа да бер кәсеп кирәк, уйлыйм, лимон белән сәүдә кылып, чит базарларга йөрисем килә иде. Уфадан лимон сатарга килгән кеше белән сөйләшеп: “Миңа, мөмкин булса, сатып түләргә дип, бер-ике, өч ящик лимон биреп китегез”, - дип, илтимас кылыр[1] идем. Алар да, яхшы, дип, бирәмез, дип җавап биргәч, 3 ящик лимонны алып калдым да, сатарга тотынам. Инде базарларга йөрергә ат-арба кирәк булып калды, бер хәрәкәт кылып, көз түләргә дип, бер ат алдым, арба алдым, шулай итеп, базарларга йөри башладым. Якын базарларга рус авылы Артюков, Карагыш, Качаган, атна буена базарларда йөреп, теге лимонларны сатып бетерәм дә, индеге базарда хаҗаинлар[2] килүгә акчаларны түли идем. Ат да булды, арба да булды. Янә лимонны күбрәк алырга уйлап, мәгълүм хаҗаинларга әйтдем: “Уфадагы зур байларыгыз белән танышдырып, шулар, сезнең әйтүеңез буенча, күбрәк лимон бирсәләр иде”, ярар, диделәр. Бу кешеләр Эстәрлебашка килгәндә фатирга үземезгә төшә торган булдылар. Шундан Уфага фәлән көндә бар, алып бирермез дип вәгъдә кылуга ышанып, Уфага китдем. Барып, теге кешеләр мине зур бай Фәттахетдин Әхтәмов [исемле] кеше белән танышдырдылар. Бай әйтде: “Ярый, вексель бирерсең, соңра түләрсең” дип, вексельгә кул куеп, йөз сумлык 10 ящик лимон бирделәр. Поезд белән Шафран станциясенә төшереп, андан 60 чакрым ат яллап, Эстәрлебашка алып кайтыр идем. Байларга да танышып алдым. Вәгъдәсенә тиешле фарызлыны түләп, һәрдаим Уфага барып торыр идем. Бартерга миңа 20-25 ящик бирә торган булдылар. Шулай итеп, көзгә кадәр хәрәкәт кылып, яхшы ук сумма ясап алыр идем. Уку вакыты җитсә, атны сатар идем дә, көтәргә алынган атның акчасыны түләп, соңра мәдрәсәгә керер идем. Шул рәвешчә, 1904 нче елга кадәр үткәрдем, бер-ике ел фрукта вакытында Уфада магазинда алма, виноград, карбыз, кавын – шундайларны сатарга мәгълүм Әхтәмов мине приказчик булып хезмәт итәргә чакырды. Анда барып хезмәт кыла башладым. Айлык 12 сум тәгаен кылып, үз йортында үзендән ашап, үзендә торыр идем. Ул заманда 12 сумга 80 метр

[1] Илтимас кылыр – үтенер.
[2] Хаҗаинлар – хозяиннар, хуҗа.

читсә[1] алырга мөмкин иде. Сәүдә вакыты үткәч, хисабымны алып, авылга мәдрәсәгә кайтыр идем. Өскә-башка киемләр дә алып кайтыр идем. Шулай итеп укыдым. Инде бу эшдән дә күңелем башка фикергә төшде, ул да булса, читкә китеп, Истанбул, булмаса, Мәдинә, Мәккәгә барып уку фикере керде. Эшләргә кирәк, анда баруга, бердән, көч йитәрлек түгел иде. Икенче – тора торган йортымыз бик искергән иде. Ничек дә бу ел өйне яңадан салырга кирәк иде. Атамыз, анамыз, кардәшем Фәрхисорур, мин – бер генә углы – идем. Әти әни белән сөйләшәләр: өйнең иске бүрәнәләрен чыгарып, урынына яңа бүрәнә кушып, ремонт кылсак булыр диләр. Мин тыңлап тордым да: “Иске иске булыр, бөтенләй яңа карагай бүрәнә салырга кирәк”, - дидем. “Һәй, балам, боңа ниндәй көч кирәк, аны кайдан табарга кирәк”, - диделәр. “Мин искедән төзергә теләмим. Аллаһ җан бирергә җүн бирер дип, ничек дә яңадан саламыз” - дидем. “Ярый, син дигәнчә булсын, салыйк” - диделәр. Моңа ничек кыламыз, һәммәбездән җыйнасак, йөз сум кадәр акча чыга торган булды, янә берәр таныш булган ага-энедән, кешедән берәр ярдәм сорармыз дидем, ярый, диделәр. Шундан авылымызда мәшһүр Габделкадыйр мәхзүм Тукаевка бардым да әхвәлне сөйләдем, чөнки бу кеше мине яхшы күрә иде. Бу миңа җавап бирде: “Эстәрлетамакдан карагайдан йорт эшләп бирә торган кешегә көзгә түләү шарт белән, үзем вәкил булып, кул куеп бирермен”, - диде. Бу кеше вәкил булып кул бирсә, хәтта минем сумга ышанырлар иде. Шундан мин куанып кайтдым, атамызга әйтдем, эш шулай, Габделкадыйр мәхзүм вәкил булып эшләтеп бирермен дип. Ярый, алайса, дип әйтделәр. 1904 нче ел февраль аенда Габделкадыйр мәхзүм белән Эстәрлетамакка барамыз да, ул бүрәнә белән сәүдә итүчеләрдән Нәҗмеддин исемле кешене күреп әйтде: “Моңа шул үлчәүдә карагайдан бура эшләп биреңез. Ләкин хакыны көз түләү шарты белән. Үзем, вәкил булып, түләргә кәгазь бирәмен, ишеген, идән, түшәм, бөтен тәрәзә яңакларын, өй-түбә башын, ишеген куеп, пыяла, түбә, тимерне үземез табармыз. Шундан башкасын эшләтеп бирәсез. Күпме хак сорыйсыз?” - диде. Бу әйтде: “Бер йөз. 25 сум задатка, 25 сум хәзер бирерсең, калганы вәгъдә булыр” - диде. Без дә бу кеше белән вәгъдәләшеп, эшләргә булдык: “Март аенда йортыңыз эшләнү белән килеп алырга хәбәр бирермез”, - диде. Шулай әйтеп кайтдым. Атамызның коты чыкды, ничек тәмамлармыз дия. “Башы булса, бак, булыр, әти”, - дидем. “Тимер кирәк, пыяла, кадак, буяу – барын да табарга кирәк бит”, - диде. “Хода кушса, бар да булыр, башлаган эш юлда калмас”, - дидем. Март ае йитде, 15 мартда хәбәр дә килде - өйне алырга килеңез, тәмам булды,

---

[1] Читсә – ситса.

дия. Инде ничек китерергә кирәк. Тотамыз да авылда дуст-ишләргә, агай-энегә үтенәмез бер ат биреңезче дип, димәк, өмә итәмез.

***Йортымны салыр хакында, бу йортны алып йортымдан чыгару.*** Бу көнләр карлар эреп, юллар йомшаган вакытда һәм дә кешеләрнең эшсез вакыты иде, атлары буш, шулай бер көндә 36 ат барып, икенче көнне йортны алып да кайтдылар. Йорт китереп, бураны өеп куйдыкымыз инде, кала яңадан өйне фундамент салып күтәрергә. Апрель ахырларында балта остасы Габдрахман агага (нимес Габдрахман ләкабе[1]) ишек, ике кат тәрәзә, башкаларын, бөтенләй бетереп, бирдекне 36 сумга сөйләшдек. Чәй-шикәр, азык тиешле вә башка ашамлыкларны бирү шарты белән май аенда өемез тәмам булды, тик түбә тимере алып ябарга калды. Иске өйнең бүрәнәләрне ал ягына алты почмак итеп кушдык. Шулай итеп, тимер ябу, ике пич чыгарырга калды. Димәк, өй булды, тимерне ничек табып да, ничек алырга калды. Ул заманда заготовка дигән идарә халыкка, бигрәк авыл йирләренә өч ел вәгъдә белән ябу тимере бирер иде. Вулысдан кәгазь алып бару кирәк иде. Вулысдан кәгазь дә алдым, Эстәрлетамак барып, июль башлары иде, йитәрлек тимерне поты ике сум 70 тиен хак белән вәгъдәгә алып кайтдым да, башын да ябдырып алдык. Айтуган авылы Сәлах дигән оста ябып бирде. Шундук пичләрне чыгартып, һәммәсе тәмам булды. Тик түбәсе генә буялмый калды.

Ошбу көндә шушылай тырышып салган йортымны 1929 елда инкыйлаб мөнәсәбәте белән, бай кулак дип, атамызда һәм үземдә укыган шәкерд, инде мин ул вакыт өйдә юк идем, 6 баланы, ике ятим кардәшем, җәмәгатемне йортдан куып чыгарып, кереп ултырды. Шулай итдереп, бөтен гаиләм кышкы февраль аенда урамда ятып калдылар. Бу шәкердемез [...][2] иде. Вулысда эшләр иде. Рәхәт, тыныч яшәсен, ләкин Ходаның эше башка икән. Гарәпләр әйтә: “әл-инсан йүдәббирү валлаху йукаддиру”, диләр. Бәндә уйлый, план кора, әмма Хода үзенекен кыладыр. Берничә ел үтмәде, бичара хөкүмәт тарафындан халык дошманы булып, мәхбүс булып югалып китде. Йорт аңардан да торып калды. Хәзерге көндә баҗамыз тиешле Лотфрахман Габдрахман углы Галиев – *(без дә 1935 елда Үзбәкстанга барып йорт салдык*) пенсионный капитан, Ватан сугышында хезмәт иткән кеше торадыр: өй дә ошбу көндә Эстәрлебашда тау буенда без салган рәвешдә сәламәт иде. 1954 елда кайтып күрдем.

***Казакъстанга беренче мәртәбә баруым. Казанга Болгар хәрабәләренә бардым.***

---

[1] Ләкабе – кушаматы.

[2] Кульязмада әлеге кешенең исеме язылса да, мәгълүм сәбәпләр аркасында, биредә күрсәтелмәде.

1898 елларда булса кирәк, бер дөньяны сәяхәт итәсем килде. Бу вакытка кадәр поездда ултырып йөрегәнем юк иде. Ата-анама киңәш кылып, минем үземнең туган йиремә Казакъстанда Таловкага барып (Исәнбай авылы), бер йөреп кайтасым килә дип, алар рөхсәт биргәч, аз-маз юллык акча табып сәфәр кылдым, бу июнь айларында иде. Беренче Шафран станциясенә барып, Уфага китдем. Поездга беренче ултыруым булып, икенче Уфа шәһәрен күрдем. Берничә көндән Ак Иделдә пароход белән Казанга китдем. Казанда бер ун [көн] күреп, бөтен шәһәрне – бабаларымызның мәркәзен, Сөембикә манарасыны, музаханәләрен, Кабан күлләрен, пароход белән йөреп, барын күреп, мондан Самарга (Куйбышев) китүгә уйладым. Казанда Кабан күле буенда Галләм хәзрәт мәдрәсәсендә тордым. Ике катлы мәдрәсә иде. Җәй укып ятучы шәкердләр дә бар иде. Казанның олуг мәкъбәрәсендә фазыл мөхтәрәм Шиһабеддин бине Баһаведдин хәзрәтләренә зиярәт кылдым, язулы ташы бар иде, 1306 сәнәи һиҗриядә вафат итмешдер. Мондан Волгада пароход белән Самарага юнәлдем. Волга буенда Казандан 150 чакрым чамасында Спасский затон пристаненә төшдек. Мондан 15 чакрым йирдә борынгы Болгар шәһәренең хәрабәләрене күрдем. Урыны да бер рус авылы икән. Асаре гатикалардан бер мазар, янә бер зур коббә бар иде. Эчендә иске каберстандан чыкмыш адәм сөякләре тултырып куелган иде. Һәм байтак кына зияратка куелмыш язулы, сынган ташлар да бар иде. Гарәпчә язылмыш иде. Бәгъзе берсен азрак укырга була иде. Урамда рус балалары: “Старинный деньги (акча) сатамыз, аласызмы?”, дип кычкырып йөриләр иде. Кайсы руслар сарык сатамыз дип йөриләр иде. Бәгъзе кешеләр килеп, борынгы мөселманлар зияратына барып, корбан чала торган, [шул рәвешле] әрвахлардан ярдәм тели торган булганлар. Хәзерге көндә, Үзбәкстанда булган кебек, болар хәзрәте Гали зияраты дип барып, бәгъзе бер урынларда корбан чалып, кабердән ярдәм телиләр...

Болгар хәрабәләренә барган вакытда Казанның Борнаев мәхәлләсенең имамы Шакир хәзрәт дигән кеше һәм башка зияратка баручылар бар иде. Пароходда бергә барып, хәрабәне бергә күреп йөрдек, болар белә кайтып, пароход пристаненә килдек. Алар Казанга кайтып китделәр. Миңа бу көн Самарага китүгә пароход булмау сәбәпле, канторда йокларга туры килде. Иртәсе көн иртүк пароход булып китдем, монда йитеп, Самара шәһәрене бер-ике көн күреп, андан Саратов шәһәренә пароход белән китдем. Инде мондан Покровская слобода шәһәренә чыгып, Волга аша Саратовның каршысында Уральскига бара торган тимер юл буенда Азинка дигән станциядә билет алдым. Берничә станса Уральскига йитмәйдер. Бу станцада атамыз мәрхүм белән бертугма агамыз тора дип анамыздан ишедеп белә идем. Дәүләт адресын белмәсәм дә, барып төшдем, тирә-якларында 15-20 чакрым

ераклыкда башкорт авыллары бар икән, шул көн баткан вакытда ат яллап китдем төнгә каршы, бер башкорт [белән] барып йитдек. Болардан сорадым: Гыйззәтулла Вәлиуллин [дигән] кешене беләсезме дип. “Бар, безнең авылда тора”, - диделәр. “Мөмкин булса, төнлә барып булмас, йортына рөхсәт итсәңез, бу кичә сездә кунарым да, иртәләп барыр идем”, дидем. Ярый, диделәр, китергән извозчикга хакын түләдем дә озатдым. Иртәләп өенә сорап барсам, ул хәзер өйдә юк, 50 чакрым бер базарга китде, байларга урак урырга ялланырга, диделәр. Ун көнсез кайтмас, диделәр, миңа да кыен булып калды. Хәбәр бирергә мөмкин булмасмы, дип сорадым. Мөмкин, бераз көтеп ятырга кирәк булыр диде. Бу Юныс исемле яхшы гына кеше, башкортча киездән текгән өе бар, азрак бия дә сава, кымызы да бар. Шушы Юныс ага: “Кунак, бездә торырсың, хәбәр килгәнче” - дип, монда ун [көн] ятып, 11 нче көн дигәндә агагыз кайтып төшде, диләр. Бичара, яланга авыл янына акбүздән чатыр тегеп ята. Киез өе юк, башкортлар гадәтенчә җәй көне кышлакда тормыйлар. Фатирымдан карап ятам, бичара, әкрен генә атлап миңа килә иде. Килеп күрешде, мине ул яхшы белми дә иде: “Сезләрне агамыз дип зиярәткә килдем, Эстәрлебашдан апаңыз Галимә углы Габделмәҗид буламын”, - дидем. Әйтүем белән, мескен, яшен агызып кочаклап, дөньяда мине дә туган итеп килеп күрешүче бар икән дип елый-елый дога кылды да, мине, чемоданларымны күтәреп, чатырына алып кайтды. Җиңгәмез һәм ике углы – берсе Габделмәҗид, икенчесе Гыйбадәтулла исемле иде. Икенче көн куй суеп, дустларын чакырып, мине кунак итеп, башка кешеләр дә кунак булып, берничә көндән үзенең кола атны җигеп, стансага ултыртып, юлыма 3 сум акча биреп озатды. Аллаһның рәхмәтендә булсын, бик юаш, бик яхшы адәм иде. Мондан Орбух стансаны аша Александров Гайга билет алып юнәлдем, юлда Ново-Узинский дигән калага төшдем. Сәбәбе исә – монда Питрау ярминкәсе икән, бу исә июль башларында иде. Бу ярминкәгә мин барган Исәнбай авылындан килүчеләр булмасмы дип уйладым. Чөнки, атамызның сөйләвенә караганда, Исәнбай авылы кешеләре монда мал сатарга киләләр икән. Казакъча Чуртанлы дип тә йөртәләр икән. Ярминкә барып, мал базарына тотам[1] белән бара торган авылымыздан атамызның шәкерде Сибгатулла Гатаулла углы Исәнбаевны очратдым, таныр-танымас килеп сәлам бирдем, каранып торды да: “Әй-бай, Мәҗид имәсме”, дип, янә, шулай, дидем. Мин дә беренче баруым сәбәпле, бу кешене аз гына төсмерләдем. “Я, мине алып кайтыгыз, - дидем. “Яхшы, бу көн кунамыз, иртән кичләтеп йөрермез”, - диде. Мондан Исәнбай авылы туксан чакрым иде. Болар малларны сатып бетермәгән. Кич булгач, яланга кунарга китдек, чөнки төнлә

---

[1] Тотам – извозчик.

малларны ашатырга кирәк иде. Шул сәбәпле, яланда куналар. Кичен яланда йокладык. Башка казакълар да тирә-ягымызда күп иде. Иртәләп торсам, Сибгатулла әйтде: “Иртәләп мин даладан монавы кәгазьләрне табып алдым”, - диде. Карасам, минем түш кесәмдә булган паспортларым вә башка кәгазьләр, аз-маз акчам да бар иде. Кесәмне карасам, пычак белән ярып алганлар, кесәмә теккән 15 сумлык бер алтыным бар иде, шул торып калган. Болары исән булгач, һәм паспорт калгач, куандым. Икенче көн янә ярминкәгә чыгып, алар малларны сатып, кич таба төя, арба белән кайтуга чыгып китдек. Арбада бер көн кунып, сәламәт туган авылым Исәнбай авылына кайтып китдек. Һәркайусы килеп күрешеп: “Әй-бай, кайдан килеп калдың?” дип, мулла исәнме, абыстай исәнме дип, сораша башладылар. Танымаган кешеләр бу кем ногай бала дип әйтәләр иде. Баягы үземезнең Сары мулланың баласы кара мулла дияләр иде, чөнки казакълар минем атамны сары төсле булуы белән “сары мулла” дип йөреткәнләр икән. Минем бу авылга килүем икенче мәртәбә иде. Монда бер-ике ай кунак булып, мондан 60 чакрым Ялпакталга бер тай менеп барып, мәгълүм Гобәйдулла хәзрәтдә бер хәфтә[1] кунак булып кайтдым да, сентябрь башларында Эстәрлебашка кайтып китдем. Юллык акча бирделәр һәм атамызга да бераз бирделәр. Шулай итеп, 50-60 сум акча белән кайтып йитдем. Кайтуым белән мәдрәсәгә укырга кердем, чөнки шәрикләрем укуга килгән иделәр. Шулай итеп, янә бу кышны укып чыкдым, яз булса, борынгыча ат алып, янә лимон сәүдәсенә тотына идем, көзгә кадәр һәм авылларга йөреп, күкәй дә җыеп кайтыр идем, шулай бара идем. 1901 нче елда янә шул Казакъстанга Исәнбай авылына һәм дә Ялпакталга барып, җәй көнләрдә йөреп кайтдым, 1903 нче елда янә июль айларында шул ук Исәнбай авылына бардым, минем фикерем - Истанбул, Мәккә-Мәдинәгә бару. Шуңарга бер юл тапмаммы дип йөрү иде. Янә Ялпакталга бардым, Гобәйдулла хәзрәттә берничә көн кунак булып торгач, мин хәзрәткә фикеремне чишдем. Безгә бер ярдәм кылсаңыз, мин Мәдинәгә укырга барыр идем, дидем. Хаҗ баручы казакълар булса, шуларга хезмәт итеп булса да китәр идем, әгәр дә сезләр казакъларга әйтсәңез дидем, хәзрәт дә каршы әйтмәде, ярый, бер уйлап күрик диде. Монда бераз тукталырга тугры килде. Сентябрь ахырлары якынлап калды. Хәзрәтнең углы Һидиятулла һәм берничә казакъ шәкердләр Каргалыга укуга барачаклар иде. Мин дә шулар белән бергә кайтуга уйладым, Самарга кадәрле, андан мин аерылып, Уфага китдем, алар Оренбург китәчәкләр иде. Ярый, бер көн хәзрәт әйтде: “Ата-анаңыздан рөхсәт алып, заграничный паспорт белән рузаның ахырларына кадәр килеп җит”, - диде. Бәйрәмдән соң хаҗилар юлга чыгачаклар иде.

[1] Хәфтә – атна.

Шундан мин бу ибдәшләрем белән бергә юлга чыгып, Александр дигән стансадан Саратовга билет алып китдек. Саратовдан Самарага пароход беләикенче класска 4 сум 5 тиенгә билет алып, Самарага җитдек. Шунда мин ибдәшләремә дидем: “Әйдәңез, минем белән Казанга барыңыз, мин дә инде Истанбулга китәчәкмен, бер йөреп, Казанны күреп, бер тарихи эш булып калыр”, - дидем. Болар да, мәслихәт диделәр дә, артык багажларны пароход конторына тапшырып, шул көнне барымыз да пароход белән Казанга юнәлдек. Казанга барып, берничә көн күреләчәк урынларны күреп, боларны янә Самарага озатып, үзем Каменский пароходына ултырып, Уфага китдем. Идел буенда Чалмалы дигән пристаньгә төшеп, мондан 70 чакрым атамызның авылы Карамалыга бардым. Баруымның сәбәбе – ул вакыт минем паспортым шул Карамалы вулысындан алынып йөрер идем. Әсасан[1], мин шул авылда туган күренә идем. Мин дә вулысдан һәм становой (начальник милиции)дан үземә “заграницкий” укуга китәмен дип, губернатордан заграничный паспорт алуга справка алдым да, шундан Минзәлә шәһәренә бардым, чөнки мин Минзәлә өязенә карый идем. Минзәлә исправникдан справка алып, икенче көн пароход белән Уфага юнәлдем. Барып, Уфа губернаторына гаризамны биреп, язуга 15 сум акча түләргә кушды, түләп, капитансаны[2] тапшырып, икенче көн барып, алты айлык паспорт алып чыкдым. Бу 1904 елның 4 нче ноябрендә иде. Мондан Эстәрлебашына кайтдым, соңра атамыз һәм анамызга әйтдем: “Мин инде, рөхсәт итсәгез, Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә укырга китәмен”, - дип, берсүздән, укуга баруыңа разыймыз, Хода безгә дә бер ярдәм бирер диделәр дә, ничек китәсең, диделәр. Мин әйтдем: “Менә алты айлык заграничный паспорт алып кайтдым”. Соңра Ялпактал Гобәйдулла хәзрәт әйтде: “Ата-анаңыз рөхсәт бирсәләр, паспорт алып кил дә, мондан хаҗиләренә кушып йибәрермен. Юлда аларның тиешле хезмәтләрен кылырсың, янә алар русча белмиләр, тәрҗеманлык кылырсың” ди, шуңа ышанып, мин ният кылдым.

***Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә сәфәрем***

Кулымда азрак акча бар иде. 45 сумга атымны сатып, агай-эне кардәшләр аз-маз ярдәм кылдылар. Шулай итеп, мин декабрь башларында рамазан аенда сәфәргә чыгарга булдым. Атамыз, җизнәмез Ниязгали, ике ат йигеп, мине озатырга Шафран станциясенә алып китделәр. Миндән авылында Сөләйман ага Кирәев дигән кешегә килеп кунып, иртәсе көн Шафранга бардык. Бу авылдан Шафран алты чакрым иде. Александр дигән стансасына билет алып, шул көнне поездга ултырдым. Әткәм, поезд кузгалгач, артымдан йөгереп килеп, йыглап, дога кылып калды. Аллаһның

[1] Әсасән – нигездә.
[2] Капитанса – квитанция.

рәхмәтендә булсын, амин. Янымда 55 сум илле [тиен] акчам калды, тәвәккәле Ходага дип юнәлдем.

Пенза, Саратов аркылы Александров Гайга барып төшдем. Бу сәнә Русиядә япон сугышы вакыты иде. Юлда гаскәр күп, бик тыгызлык булды. Александров Гайдан 90 чакрым Ялпакталга юнәлдем. Рамазан аеның егермеләре иде. Хәзрәткә килеп төшдем, хәл-әхвәлне бәян кылдым, яхшы, диде: “Мона миндә бер казакъ карты әманәт өч йөз сум акча тапшырып иде. Минем өчен берәр кешене йибәреп, хаҗ кылдырырсың дип, байтак вакыт үтеп китте. Аз акча дип, хаҗга баручы булмай торадыр. Син укуга барсаң, аз булса да, шушы әманәтне мин сиңа бирергә уйладым. Сәламәт барып, хаҗ кылсаң, ул казакъларның балаларына тапшыру өчен хаҗ кылганлык шәһадәтнамәсен бирерсең. Бу елга кулыңызга бер йөз йигерме биш сумны бирәмен. Баруыңызга йитеп торыр. Син бит анда берничә ел каласың, киләсе ел янә шулай йибәрерсең, - диде. - Бәлки юлда югалтып калдырырсың, шуның өчен азлап йибәрермен. Насыйп булса, баручы хаҗиларны белеп куйдым. Алар бергә бергә алып барырмыз, диделәр. Руза гаедне уку белән сәфәргә чыгарырсың”, - диде. Бу вакытда Өршәкбаш Карамалы авылы Хәбибрахман мулла углы Исхаков Габделмәҗид карый хәтем кылмакда иде. Рузаның ахыргы ун көнендә муллалар, картлар, мәсҗедкә кереп ятып, шунда ун көн торырлар иде. Өйгә кайтмасдан мәсҗеддә ашап-эчеп йоклап ятырлар иде. Дине рәсми буенча бу игътикяф дигән бер сөннәт гамәлләрдән хисап кылыныр иде. Авылдан карый белән безләр, хәзрәтнең кунагы булу сәбәпле, шәһәргә байларга ифтарга барыр идек. Чөнки хәзрәткә мәсҗеддән чыгып йөрергә ярамыйдыр. Адаш карый бик абруйлы иде. Өстә камай тиен тун, муенда мамык шарф, чалма да бик ак. Мин булсам – бер авыл малае, өстә начар, аякда алама бүрек, башда иске генә бүрек. Байларның яхшы ат чаналарында янәшә ултырып китәмез. Бу карый әфәнде пош-пош килеп барыр иде. Минем янымда ултырып барды. Шундан кадер кичәсе дигән, 27 рамазанда буладыр, шул көн карый хәтемне тәмам кылачакдыр. Икенче тәравих намазында кеше бик буладыр, чөнки, бердән, хәтем, икенчедән, кадер кичәседер. Хәтемдән соң җәмәгать карыйга һәм мулла-мөәзинләргә, гариб картларга сәдака бирерләр иде, бәлки миңа бер ярдәм булыр нияте белән итсә кирәк: “Син тәравихкә алданрак барып, алгарак ултырырга тырыш, - диде. - Мин дә халыкга ишарә кылырмын, аз-маз сәдака бирерләр, укырга баручы шәкерд кешегә аз булса да ярдәм булыр”, - диде. Азмы-күпме акча төшде. Иртәсе көн адаш карыемыз хафа булып калган... “Әй ходаем, хәерле сәфәр насыйп ит, сәламәт Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә барып, ошбу Кәлямулланы хифыз кылып кайтып, шушы мәсҗеддә хәтем итсәм иде” - дип еглап, Ходага теләк кылдым. Һәм уйлаганымча булып чыкды. Чынлап

еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, диләр, дөрест имеш һәм җәнабе Аллаһ Кәламдә әйтә: . وَإِذَا سَأَلَكَ عِبَادِي عَنِّي فَإِنِّي قَرِيبٌ أُجِيبُ دَعْوَةَ الدَّاعِ إِذَا دَعَانِ فَلْيَسْتَجِيبُواْ لِي وَلْيُؤْمِنُواْ بِي لَعَلَّهُمْ يَرْشُدُونَ[1] Шулай итеп, юлдаш була торган хаҗиларым мине, бергә алып, авылларына китдек.

***Мәдинәи-Мөнәүвәрә сәфәре***

Ялпакталда 8 чакрым Аккүл дигән йирдә бу хаҗиемызның авылы иде. Бу юлдашымның исеме Тимергали иде. Бу кичдә монда кундык, кич белән куй суеп, күрше агай вә энеләрне җыеп кунак итде. Алар белән видагълашып[2], озатып йибәрде. Бу килгән кешеләр һәркайусы бу Тимергали агага ярдәм итделәр. Иртәсе көн мондан кузгалып китеп, юлдаш була торган икенче хаҗиемызның авылына бардык, анда янә бер кич кунып, юкарыдагыча ага-энеләре белән бәхилләшеп һәм зиратларына барып, үлгәнләргә Коръән укып китдек. Бу Киләш исемле иде. Янә өченче көн Батыр мулла дигән янә бер юлдаш каршылап, минем туган авылым Исәнбай авылына барып кундык. Икенче көн биш-алты казакъ юлдашларымыз илән Алмалы стансасына юнәлдек, (Александр Гай) мондан 45 чакрымдыр. Янә берничә хаҗга баручы казакълар монда янә килеп кушылып барамыз. Бергә өченче класска Севастопольга билет алып юнәлдек. Хәерле сәфәр булсын дип, Саратов, Харьков аркылы Севастопольга барып йитдек. Юлда вагонда бу казакъларга куй кортыны табакга изеп, эчәргә хәзерләп бирә идем. Караңгы торып эшем – корт изү. Махсус вагонда барыр идек. Хаҗилардан башка кешеләр юк. Бу декабрь айларында иде. Көнләр суык, Севастопольдә бер биш[көн] тордык. Монда паспортларымызны регистрировать итдек. Пароходка йитәрлек хаҗилар җыелу сәбәпле, пароход китәчәк булды. Хаҗиларга махсус русское обществоның (Царица) дигән пароходы иде. Билет хаклары Севастопольдән Җиддәгә кадәр өченче класска барып кайтуга йөз дә биш сум иде. Баруга гына 55 сум иде. Әлбәттә, бездәй укуга баручыларга авырлык кылыр иде. Безләр бай хаҗилар түгел. Шундан соң берничә укырга бара торган шәкердләр пароход конторына гариза бирдек: “Без хаҗи түгел, укуга баручылар. Безләргә буш билет бирелсә икән”, - дия. Ул вакытларда укучы шәкердләргә, кулында шәһадәтнамәсе булса, ярты билет бирерләр иде. Димәк, 50% киметә иде. Кантор безгә: “Җавап бирелмәз, ученикларга буш биреп булмый, скидка белән ярты хакга бирәмез” - дип җавап бирде. – “Хаҗилар пароходка кереп бетсенләр, сезләр ахырга калыңыз, шундан соң керерсез” – дип, һәм шулай эшләп, безләргә Җиддәгә кадәрле 27 сумга билет бирделәр. Паспортларымызның бер талонын җыртып алып

---

[1] Уа иза са-алакә ‘ибади ‘анни фа-инни кариб; ужибу дә’-уәтәд-да-’и иза да-’ани фал йастажибу ли уал-йумину би ла-’аллахум йаршудун (Бәкара сүрәсе, 186 аять).

[2] Видагълашып – саубуллашып.

калып, пароходка үткәрделәр. Бу вакыт кич сәгать унлар иде. Монда Кузнецкий өязе Бәлдәнке авылының Искәндәр Мәннанов дигән ибдәш белән танышып, бергә табакдаш булып ултырып китдек. Бу Мәннанов исә Мисырга укырга бара иде, фабрикант Дибирдиевләр хисабындан, үзе Коръәнхафиз иде. Әүвәлдә Коръәнне Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә укымышдыр. Севастопольдән төнге сәгать уникеләрдә Истанбулга карап, диңгезгә кереп китдек. Пароходта йиде йөз кадәр үзбәк, казакъ, кыргыз, Кырым [татарлары] һәм башкалар бар иде. Пароходта юлдаш казакъларым бер дә тынычлык бирми башладылар. Без өченче катда, алар астагы катга ултырган иделәр: “Корт из, моны изеп бир, аш пешер, андан соң чәй кайнат”, - дип, бер минут бушлык юк иде. Мин дә, уйланып, булмаса, боларны ташларга кирәк дип, ташларга булдым. Пароходта әле бу беренче көндә агырлык кылды. Җиддәгә кадәр 15 көн барырга кирәк. Истанбулда болар бушатмаслар. “Йөри торган урынларны күрә алмам” дип, боларга әйтдем: “Рөхсәт итеңез, мин сезгә хидмәт[1] кыла алмыймын, Истанбулда мин шәһәрдә тамаша кылып йөресәм, сезләргә вакытында аш-чәй хәзерләүче булмаса, сез дә рәнҗеп калырсыз. Бу – Ходай юлы, хаҗ сәфәрендә берәү берәүне рәнҗетүгә ярамый, әле барасы сәфәремез күп”, - дидем. - Сезләрдә көн-төн ашау-эчү кайгысы, миңа – шәһәрләрне күреп, сәяхәт кайгысы. Шул сәбәпле аерылырга тугры килә”, - дидем. Болар үзара мәслихәт кылышып, усы бала үзе бер төрле күренә дип, янә азау кылдылар. Бер көн Кара диңгездә барып, өченче көн иртән яктыруга Босфорга кердек. Истанбулның бәгъзе биналары күренә башлады. Бөтен хаҗилар пароход өстенә чыгып, әнә, Истанбул күренә дип, шадлык белән гөҗ киләләр иде. Пароходымыз башына төрле флаклар күтәрде. Хөкүмәткә сәлам бирү һәм хаҗиларга махсус яшел, карантин флаклары җилбердәп килә. Пароходымыз акрын гына барыр иде, Истанбулга каршы буксир пароходы килеп, пристаньгә пароходны алып керәдер иде, чөнки бу сәфәрдә диңгез пароходлары күп йөрү сәбәпле, каршылы борылу ихтималы булганлыкдан, пароход үзенең йөрешен туктатып, фәкать буксир гына алып йөрер иде. Бу сәфәрдә мотор белән төрек начальниклары килеп, пароходка кереп тәфтиш кылып, шәһәргә керергә рөхсәт кәгазе бирделәр. Диңгез буенда пароходка каршы төшкән барында кызыл фәсле флаклар күп иде. Берәүләр кычкыра: хаҗилар күпме, берәүләре казакъ, үзбәкләр бармы дия пароходымызда йөри. Йөз хаҗи бар дип җавап бирделәр. Шундан, пароход капитаны чыгып, хаҗиларга игълан кылды: “Истанбулда биш көн торамыз, багажларыңызны алып төшеңез, иртән чыгып шәһәрдә йөреп, кичне пароходка кайтып кунарсыз”. Пароход тирәсендә төрек полицлары, киемләренең башына ай

---

[1] Хидмәт –хезмәт.

йолдызлы флак кадаган, халыкның төшкәнен карап, көймә белән хаҗиларны тугры ләмрәкханә[1] йибәрерләр иде. Таможня көймә белән килеп, ләмрәкханәгә туктап, сарайга кертделәр. Монда кулымыздан паспортларымызны алып калып, үземезне шәһәргә чыгарып йибәрделәр, һәркем белгән кешеләрен эзләп китде. Хаҗиларны күбрәк дәлилләр,[2] юлбашчылар алып китделәр. Инде казакълардан аерылып китдем. Мин Севастопольдә бергә ултырган юлдашым Искәндәр Мәннанов белән бергә чыгып китдек. Кайда барамыз инде. Мин әйтдем: “Минем бер ай мондан элек килгән ибдәшләрем бар. Адреслары белән шуларны табып алышырга кирәк, - дидем. - Авылдашым авылымызда ут күршесе иде. Габдулла дигән якташны табуым кирәк”, - дидем. Авылда Габдулла Әхмәди углыны Пугач дип ләкаб кылырлар иде. Бу Габдулла хаҗи 1895 нче елларда Истанбулга һиҗрәт кылып киткән иде. Хатыны шулай ук авылда күршемез Сәгыйдә Гобәйдулла Шәрипов кызы иде. Искәндәр юлдашым әйтде: “Мин дә бер таныш адәмне эзләп барам”, - диде. Чөнки авылдан аның исеменә 1000 сум акча перевод кылган иделәр. Шуның өчен бу кешене табышым кирәк, аерылышуыбыз да иртәгә фәлән сәгать фәлән йирдә очрашырмыз, кайсымыз килсә дә, шунда көтеп торырмыз, дип аерылышдык. Чәнберле Таш мәхәлләсендән Эстәрлебашында бергә укыган Кәмаледдин Галләмеддин углы Рәхимкулов Эстәрлебашка якын Кәркәле авылындан. Икенче юлдашым Гаидмөхәммәд Миргали углы Әхмәров Эстәрлебашында яшь вакытымыздан башлап бергә укыган шәрикем иде. Боларны табып алып, бу кичә боларда кундым. Иртәләп шәһәргә чыгып китдек һәм вәгъдәләшкән урынга Мәннанов та килмеш иде. Минем өс-баш киемем татарча булу сәбәпле, урамларда хәерчеләр артымдан калмады: “Хаҗи вир”, дип теләк кылырлар иде. Боларга бирә барсаң да күп, шул сәбәпле, мәҗбүр булдым өс-башны мондагыча киенергә, мәгазинга кердем дә, өстемә пальто, аякга шиблет[3], башка кызыл фәс һәм галстук куеп, шунда киендем дә, иске киемләрне магазин хуҗасына кичкә кадәрле әманәт кылыб калдырдым да, чыгып китдем. Инде европеец булып алдым, урамларда хаҗи вир дип сораучылар да юк булып калды. Инде бу юлдашларымыз илән бәрабәр шәһәрне күрергә башладык. Беренче, мунчага барып юынып чыкдык, андан Әйа-Суфия җамигысыны барып күрдек һәм башка тиешле урынларны күреп, бу көнне кич йитеп, кичендә отельгә, безнеңчә гостиницага барып кунарга сөйләшдек дә, кичен барып кунып, иртән җомга көн булу белән җомга намазына Солтан Габделмәҗид җамигысына, Йолдыз Сарай дигән, шунда җомгага китдек. Фаэтон алып

---

[1] Ләмрәкханә – пристань.
[2] Дәлилләр – юл күрсәтүче, гид.
[3] Шиблет- штиблет.

ултырдык, барып, мәсҗед янына туктап, шунда җомга вакытын көтеп тордык, күпчелек мәсҗед тирәсе гаскәр белән уратылып алган иде. Рәшәткәнең тыш ягында кырык башка ничә меңләр хаҗи вә башка кешеләр дә күп иде. Мәсҗедкә җомганы солтан укып чыкмый торып, башкаларны мәсҗедкә кертмиләр иде. Вакыт җитде, бер вакыт берничә фаэтонлар белә һәм атлы сакчылар белән пашалар (министрлар) һәм бар иде. Солтан килеп, мәсҗедкә кереп китде, җомга укыгандан соң, чыгып кайтып китделәр. Каравыл гаскәрләр дә полк-полк духовой музыкалары белән кайту ягына юнәлделәр. Хәзер безләргә кереп, намаз укырга рөхсәт булды. Кердек, мәсҗеддә Солтанның ишеке башка булып, шундан күп баскыч белән югарыга чыгар икән.  Юкарыда бер бүлмә рәшәткәле, Солтан намазны шунда үзенең министрлары белән укый икән.

***Истанбулда булган вакытымда***

Җомгадан кайтып, ашханәдә ашап чыкдык да, миңа хәзер юкарыда язылган Габдулла хаҗины табып алышым кирәк. Андан Истанбулда күп еллар мөһаҗир булып торучы Габдеррәшид әфәндене табып күрешергә кирәк иде. Бу әфәнде Бөгелмә өязе Мәллә суы буенда Чубар авылыннан иде, атамыз туган Карамалы авылына 20 чакрымлык юл иде. Бәгъзе вакытлар Русиягә ага-энеләренә кунак булып кайткан вакытында Эстәрлебашка килеп, безгә төшәр иде. Атамыз мәрхүмнең якын замандашларындан булу сәбәпле, бу кешене күрергә һәвәсем бар иде. Ибдәшләрем белән сөйләшеп, мин шул йиргә барамын, сезнең белән кич фәлән йирдә очрашырмыз дип китдем. Габдулла әфәндене күрергә кирәк, чөнки безнең авылымызда ут күршесе иде. Икенчедән, пароходтан төшкән вакытда капитан Җиддәгә кадәр 13 сутка, 13 көнлек юлымыз бар, шуңа йитәрлек юл азыкларыңызны алыгыз дип игълан кылган иде. Диңгез юлы да, нинди азык алырга, башка нәрсәләр кирәк, безнең белмәвемез сәбәпле, Габдулла әфәнде безгә тиешле азык вә башка кирәкләрне алып бирер дип уйлап, күрүемез мәтлуб[1] иде. Аны табып алып, ибдәшләр янына килдем, юлдашым Искәндәр Мәннановка әйтдем: “Менә минем һәмшир,[2] бу безгә юлга кирәкле нәрсәләрне алып бирер”, - дидем. Ул да, мәслихәт дип, берничә сум акча бирде дә, барын үзең кара инде, диде. Шундан Габдулла әфәнде белән Бал Капал базарына барып, кирәк нәрсәләрне ала башладык: икмәк, пәнир (сыр), май, дөге, сухари, аш пешерергә мангал (учак) күмер, чәй-шикәрне – кирәк барын да алдык да, ике хәммал (носильщик) алып, пароходка алып килдек. Көймә белән барын да пароходка кертдек. Иртән кидәчәк буларак, мондан әсас[3] шәрикем

[1] Мәтлуб – тиеш күрелгән, таләп ителгән.
[2] Һәмшир – абый.
[3] Әсас – төп.

Габделмәҗид Әхмәров да безнең белә китәргә уйлап, ул да пароходымызга керде. Янә берничә укуга баручы үземезнең татарлардан ибдәшләр керделәр. Алар Истанбулга бурзак[1] килгәнләр иде. Болар – берсе Бәләбәй өязе Ык буе Тымытык авылына якын Миргалишир, икенчесе Харис Заһидов Чукмарлы авылы Сарапул өязе Кадерле авылыннан, Бубида укыган, өченчесе – Зыя Рәхманкулов, Орскида Әхмәдләтыйф хәзрәтдә укыган. Барымыз алты юлдаш, бер-бергә казандаш булып, Истанбулдан юнәлдек, хәерле юл, амин. Мәрмәрә диңгезен, Дарданел бугазын үтеп, Ак диңгезгә барып чыкдык. Ак диңгездә берничә көн йөреп, порт Сәгыйд шәһәренә йитдек. Бер көнлек юлдан порт Сәгыйддән, биек урындан, прожектор белән диңгезгә яктылык бирәләр иде. Порт Сәгыйдкә килгәч, юлдашым Искәндәр Мәннанов пароходдан төшәргә булды, чөнки ул Мисырга барачак иде. Капитан пароходның бер көймәсене биреп, бер матрос белән чыгарып йибәрде. Безләр, хәерләшеп, Искәндәрне порт Сәгыйд шәһәренә озатып йибәрдек, мондан Мисыр (Каһирә) поезд белән 6 сәгатьлек юл иде. Пароходымыз канал белән йөреп китде (ягъни Сүәеш каналы белән). Канал эшләнгән 1869 нчы миладида Мисырда Сәгыйд паша заманында, шуның өчен порт Сәгыйд дип исем бирелгән. Каналның озынлыгы 184 километр, киңлеге өстән 100 метр, төбендән 22 метр, башда тирәнлеге 8 метр, хәзердә күбрәктер. Юлда канал эчендә Исмәгыйлия дигән күлләргә очрап, шунда пароход якорь салып туктады. Чөнки бу көн 25 нче декабрь – русларның рождество бәйрәмләре иде. Монда капитан, матрослар бер көн бәйрәм итделәр, көнләр бик эссе булу сәбәпле, капитандан рөхсәт сорадык, су керер идек дия. Пароход янына бер көймә төшерде дә, шул көймәдә төшеп, чишенеп, су кердек. Икенче көн мондан юнәлеп, Сүәеш шәһәренә барып җитдек. Мисырдан ага торган Нил мөбарәк суы шушында килеп, каналга коя икән. Пароход, берничә сәгатьләр туктап, пароходка су алды. Суны гарәпләр көймә белән китерерләр иде. Андан насос белән пароходка алырлар иде. Су алып тәмам булу белән Бәхре Әхмәр (Красное море)гә карап юнәлдек. Пароходта бу көн Мөкәрәмә шәрифләренең якынларындан Сәид Габдулла Җәфри исемле, Истанбул дарелфөнүнендә укучы талибә, каникулга кайтып бара икән, бер-беремез илән танышып, бергә юлдаш булып, уйнап-көлеп барамыз. Сәид Габдулла матур гына, карарак төсдә, сачы бөдрә, яурупача костюм-галстукда иде. Берничә көндән соң пароходымыз Янбуг пристаненә йитеп, ярга җитмәсдән 100 таяк кадәрле йиргә якорь ташлады да, пароход туктады. Бу Янбуг Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә китә торган пристань иде. Мондан Мәдинә тәвә белән биш көнлек юлдыр. Тугры Җиддәгә баручы хаҗилар һәм безләр Җиддәгә китдек. Янбугда

---

[1] Бурзак – алданрак.

пароход янына гарәп балалары йөзеп килеп, вир хаҗи, дип, хәер сорарлар иде. Көтү кебек җыелышып килеп, көн буена аяклары белән суда йөзеп торырлар иде. “Вир, хаҗи, Аллаһ сәламәт, мәмләкәт сәламәт”, дип кычкыралар. Бичара хаҗилар, кызык күреп, ун тиенлек, егерме тиенлек көмеш тәңкәне диңгезгә ыргытыр иделәр. Тәңкә суга йелбер-йелбер итеп төшеп барганда, хәзер килеп йитеп, тәңкәне алып, халыкга күрсәтеп, үзләренә салырлар иде. Күзләрен ачып, судагы тәңкәне эзлиләр, ничек күзләре чыдый, чөнки диңгез суы тозлы, ачы була, авызга кабып булмай. Ә болар, күзләрен ачып, акча эзлиләр. Үзләре акча белән тулгач, берәм-берәм судан чыгып, авылларына кайтып китәрләр иде. Икенче көн мондан Җиддәгә карап юнәлдек. Бер көн чамасында Җиддә күренә башлады. Шәһәр якынлаша башлагач, диңгездә батып яткан пароходларның мачталардагы баулары гына йелпердәп торалар иде. Бу юлларда диңгез астында ташлар күп була икән. Өсте су булып күренсә дә, бер метр кадәр генә ташлы таулар була икән. Шуларның арасындан корт йөргән кебек пароход әкрен генә керә. Күп йөри алмады. Шәһәр биш километрдай калгач, пароход якорь салды да, флаклар күтәрде. Шундан соң фарсылар корган көймәләр белән гарәпләр чабышып, кем узардан килә башладылар. Хөкүмәт мәэмүрләре[1] дә килеп, пароходтан тәфтиш соңында төшәргә боердылар. Хаҗи, кил, дип, кайулары баскычдан менеп, юкарыдан арканга бәйләп, йөкләрендән көймәгә төшерә башладылар һәм көймәгә 15-20, күбрәк дә кеше ултырыр иде. Шулай барымызны берьюлы алып китделәр. Без Җиддәгә чыгамыз дип барсак, бер утрауга алып барып туктадылар да: “Төшеңез, я хаҗи”, дип, гарәпләр кычкыра башлады. Бу урын карантинханә икән, барчамызның кием я паспортларымызны, өстемездә килгән ихрамларымызны[2] салдырып алып, барын дизенфекциягә бирделәр, һәммәбезне ялангач көенә тимерчыбыклар белән бүленгән йиргә бикләп куйдылар. Һәрбер бүлмәдә 100ләп кеше, ялангач ябылган мал кеби тимер челтәрдән карап торамыз. Көн бик эссе иде. Киемләремез паровойдан чыгу белән әлеге киемче гарәпләр янә безләрне алып, шәһәргә алып китделәр. Бу вакыт сәгать 4-5 чамасында булырга кирәк. Киемләремез белән таможня сараеның баскычы төбенә туктатып, таможня сараена алып керделәр дә, һәрбер милләтнең үзләренә махсус дәлилләре булса икән. Казанлыларның, үзбәк-казакъларның – һәркайусының дәлилләре паспортларымызны алып, үземез диктовать итеп, исем-фамилия, паспорт нумерасыны язып алыр иде. Мондан дәлилләр без – татарларны – аерып алып, дүрт катлы бер өйгә кертделәр. Һәр бүлмәгә егерме я утыз кешедән урнашдырдылар...

---

[1] Мәэмүрләре – хезмәтчеләре.

[2] Ихрам – хаҗилар өсләренә кия торган кием.

Шушында ятамыз. Иртүк: “Торыңыз, Мәккә барырга кәрван дөяләре хәзер булыр һәм дә шул вакыт паспортларыңызы да бирерләр” - диделәр. Шундан базарга чыгып, чәйханә-каһвәханәләргә кереп, чәй-каһвә эчеп, әлхасыйль,[1] тамакларымызны туйдырып алдык. Юлда танышкан Габдулла әл-Җәфрине Мәккәдән яхшы ишәкләр белән каршы алырга Мәккә шәрифенең якынларыннан берничә адәм килмеш иде. Габдулла безгә килеп әйтде: “Мин китәмен, теләсәңез, ишәк алыңыз да, бергә-бергә китәрмез” - диде. Безләр дә: “Рәхмәт илтифаңызга, тәшәккер кылдык. Насыйп булса, саба кәрван белән барырмыз, сәламәт булсак”, - дип, аны озатып калдык. Хода беләдер, хәзрәте Хава анамызның зиярәте дип алып барып, дәлилләремез зиярәт кылдылар. Икенче көн иртә белән фатирымыз алдына кәрван дөяләре лагерьдан тулып, бакырып-иңрәп, чүкеп яталар иде. Шундук дәлилләр килеп кереп, исем-фамилия белән паспортларымызны биреп: “Һәр ике адәм бер төягә йөкләреңезне бәйләп, өстенә менегез”, -диделәр. Тиешле юл хакыннан җыеп алдылар. Көндез сәгать 10 лар чамасында Җиддә мөбәракәдән Мәккәйә сәфәр итәмез, һәркем бер ихрам белән иде, чөнки безләр ихрам бәйләп, хаҗымызны ният кылып идек. Мәккәи-Мөкәрәмә Җиддәдән 60 километр йир иде. Крепость капкасыннан чыгып китдек. Юлда һәр тарафда гарәп балалары су сатып ултыралар иде. Һәр йирдә чәй вә каһвәханә төшеп эчеп китәр идек. Көнләр эссе, тау арасы, бер таудан икенче тауга кадәр сигнал биреп, төрек гаскәрләре кәрванны озатып калырлар иде. Чатырлары тау башларында. Бу заманда бу йирләр төрек кулында иде. Ярты юлда Бәхра дигән нөзүлдә[2] кунып, икенче көн сәгать 6ларда Мәккәгә барып кердек. Монда да үземезнең казанлы дәлилләр каршы алып: “Без, - дидек, - Нәҗмеддин әфәнденең өенә, мөмкин булса, төшәр идек”, - дидем. Бик яхшы, диде һәм дә алып барып төшерде, өч катлы таш йорт иде. Үземезнең Русия байлары тарафыннан салынган, килгән шәкердләр һәм фәкыйрь хаҗилар хаксыз шунда төшәрләр дип, бу Нәҗмеддин әфәндене мөдир кылып калдырганлар. Казанлы Нәҗмеддин әфәнде тәкиясе[3] белән мәшһүрдер. Алты юлдашларымыз барымыз да бер бүлмәгә җирләшдек. Безнең бүлмәмездә 7-8 ел Мәккә ултырган хазирымыз Кәлямулла Фәррахеддин әфәнде бар иде. Бу мөбарәк Уфалык Хәкимовлар тарафыннан укуга бирелмеш икән. Үзе Бәләбәй өязе Турай авылыныкы иде. Бер мең тукыз йөз унынчы елларда кайтып, авылы Турайга имам булмыш иде. Аллаһның рәхмәтендә булсын, олуг Русия инкыйлабы вакытында, мулла дип, инкыйлабчылар тарафыннан бигайрихак[4]

---

[1] Әлхасыйль – бер сүз белән әйткәндә, кыскасы.

[2] Нөзүлдә – юлда берәр йортта вакытлыча туктау.

[3] Тәкия – мөридләр җыела торган урын.

[4] Бигайрихак – хаксыз.

мәкътүл улмышдыр[1]. Аллаһның мәгъфүр бәндәләре җөмләсендән һәм дә дини шәһидләр зөмрәсендән[2] улсын иде. Икенде ахшам намазы өемездә укып, ястү вакыты якынлаганда дәлилләр килеп, безләрне Кәгъбәтуллага барып тәваф кылдык. Хәрәм шәрифдә Кәгъбәтулла хозурын йөз меңләп халык ястү намазны укып торалар иде. Безләр дә укып, намазымызны тәмам кылдык да, соңра Кәгъбәи шәрифне тәваф кылып һәм Сафа белән Мәрвә арасында сәгый кылып[3], бу көнлек бурычымызны тәмамлап кайтдык. Безләр иртәрәк килүемез сәбәпле, гарәфәткә чыгарга бер ай кадәр вакытымыз бар иде. Әле һәр көн һәр этрафдан мөслиминләр меңәрләп килеп ятырлар иде. Һәм Мәдинәи-Мөнәүвәрәдән дә һәмшир шәкердләр килеп, алар белән танышып алдык. Хаҗ көнләре якынлап калды, Гарәфәткә чыгу якынлашды. Шулай булса да, бер ай буена тик ятмадым, хаҗилар кәфенлек дип, ак нәрсә 15-20 метр алып, зәм-зәм суына манып алып китәрләр иде. Зәмзәм суы берничә йөз савыт алырлар иде. Мин шул кәфенлек материалларыны, зәмзәм коесындан чиләк белә су алып кайтып, казакъ хаҗиларына 15-20дән кәфенләрен, ничә йөз зәмзәмләрен сандык алып (сахра диләр) тутырып бирә идем. Бер кәфен мануга 50 тиен, бер һәм зәмзәмне сахрага тултырырга 2 сум, 3 сум бирәләр иде. Шулай итеп, аз-маз юллык хәреҗ[4] табу хәрәкәтендә булыр идем. Иртәгә Гарәфәткә чыгамыз дигән көн бик каты авырып калдым. Әйтәләр: һава тота, шундан диләр. Эсселек 39-40 булып калды. Бик хәлем авырга калды. Гарәфәт чыкмасдан мөмкин түгел. Анда булмасаң, хаҗ булмый, икенчедән, йортларда һичбер адәм калмый, ятып калсам, үлсәм, агызга су салучы да юк инде. Нишләргә? Ибдәшләр әйтә: ни күрсәк дә бергә күрермез, үлсәң дә кулымызда үләрсең, дәфенләремез, Хода кушса, бәлки сәламәтләнерсез дип, мине Гарәфәткә алып чыгуга карар кылдылар. Һәрхәлдә, болай ташлап китүгә булмаса, чык, бер ишәк алырмыз да, икемез ике якдан төртеп алып барырмыз, диделәр. Ходага тапшырып, ибдәшләр әйткәнчә, юлга чыкдык, хәлем бик агыр иде. Юлда (Минәдә) кунып, иртәләп Гарәфәткә барамыз икән, төшеп кунарга чатырлар, чәйханә, ашханәләр бар икән, шунда төшдек дә мин ятам, өстемдә ихрамдан башка кием юк. Аллаһның рәхмәте булсын, төнлә бер исһал (эч китү) булды ки кара дегет кебек, шундан соң эсселек төшеп күзем ачылды, иртәләп торып юлдашларымның ярдәме белән Гарәфәт тавына барып йитүгә насыйп булды. Көндән-көн хәлем яхшыра барды. Гарәфәтдә торып кичен дә Мөздәлифә дигән урынга кунып, иртәләп таң белән Минага юнәлдек. Бөтен ничә йөз мең

[1] Мәкътүл улмышдыр. – үтерелгән.
[2] Зөмрәсендән – төркеменнән.
[3] Сәгый кылып – тырышып.
[4] Хәреҗ – чыгым.

урында духовой музыкалары Төркиянеке, Мәккәнеке, Мисырныкы, Иран хөкүмәтенеке уйнап, юлда һәм караван кузгалган вакытларда уйнарлар иде. Һәм берничә минутдан туп атарлар иде. Мина дигән урынга килеп төшдек, корбан гаеде көнне кояш чыкган вакытда ике тарафы биек таулар икән, кечкенә генә бер шәһәр исемендә иде. Монда Ибраһим пәйгамбәремезнең углы Исмәгыйльне корбанга бирәбез дигән урыны, диләр. Шәһәрдә почта-телеграф бар вә башка дөкянләр бар иде. Хаҗ гамәлләрендән бу йирдә Җәмратель-гакабә исемле таш ата дигән урыныдыр. Һәм бу йирдә таш атып, корбан чалып, сачләремезне алдырып, ихрам чыгып, үз киемләремезне кидек. Бу йирдән Мәккә Мөкәррәмә алты километр иде. Шунда Минадан ишәк яллап кайтып, Кәгъбәтуллага фарыз булган тәваф зиярәтене кылдык да, кайтып, Минага килеп, ике кич кундык. Бу вакытда Мәккә Мөкәррәмәдә бик аз адәм бар иде. Һәм шул вакытда Кәгъбәтулаһның пәрдәсене ябалар иде. Ишекесе ачык иде. Без дә, форсатдан файдаланып, Кәгъбәтуллаһ эченә кереп, ике рәкәгать нәфел намазы укып чыкдык. Башка вакытда ишекене ачмыйлардыр. Икенче көндән соң Минадан барлык хаҗилар бергә Мәккә Мөкәррәмәгә кайтып урнашдык. Инде Мәдинәи-Мөнәүвәрә хәрәкәтендә була башладык. Димәк, янымызда фарыз булган хаҗны тәмамладык. Әлхәмдүлиллаһ. Инде берничә көнләр Гомрә хаҗ, ягъни нәфел хаҗ кылалар икән. Ата-анамызга вә башка кушкан хаҗиларга кылыр идек. Биш километр чамалы йирдә, мәсҗед әт-Тәнгыйм диләр, бер мәсҗед бар, шунда барып кайтуга ишәк алып барып, шунда ниятләп ихрам киямез дә, ике рәкәгать ихрам намазы укып, бу хаҗымызны ниятләрем, атамыз фәлән-фәлән углының рухына дога кыламыз да, Мәккәгә кайтып, Кәгъбәтуллага йиде мәртәбә тәваф кылып, Сафа-Мәрвә арасында йиде мәртәбә йөреп, соңра сачне алдырасың да, димәк, бер нәфел хаҗымыз тәмам булды. Бу шушыны гомрә хаҗ диләр. Көненә дүрт-биш мәртәбә кылып була, барып кайтуга ишәк хәзер, бәһасе 1 сум, я сиксән тиен тора. Бу хаҗны кылу өчен хаҗилар биш сумдан башлап, йикерме биш сумга чаклы бирерләр иде. Кешесенә карап. Шулай итеп, бер атнада йөз сум акча табып алыр идек. Инде Мәккәдән Мәдинәгә китүгә калды. Карар кылдык: Җиддә аша пароход белән Янбугга, андан Мәдинәгә барырга, чөнки юл мәшәкате йиңелрәк туры кәрван белән барсак, 12 көн төя белән һәрвакыт сахрада кунып барырга кирәкдер. Юлларда бәгъзе урынларда су да табылмый кала. Шуларны уйлап, мондан китүгә булдык. Йөкләремезе Җиддәгә бара торган таныш хаҗиларның дөяләренә салдык да, үземез җәяү чыгып китдек. Безләр өчен шәһәрдән дөя алу кыйбатчылык кылды. Шәһәрдән чыкгач, дөягә шуларның сатлык дөяләре булса, шуларга арзан хак белән менеп китәмез дип уйладык да, кәрванга ияреп, юлга чыкдык. Бераз шәһәрдән чыгып, буш дөяләр күренә башлады,

хакларын сөйләшеп карадык, Җиддәгә кадәр алда дөяләр күп булыр әле дип, җәяү китә бирдек. Барамыз, бер дә дөя юк. Юл авыр, көн эссе, аяк асты ком, бердән тигәнәк аякга кадала, баскан саен аяк артка китә, ибдәшләрем мине кыздыралар, син алда арзан була, тәвә күп булып әйтдең дип, мин дә боларга каршылашмый кына барамын. Шулай итеп, алда тәвә арзан, күп була дип, куна торган йиргә дә барып йитдек. Аяклар яна: тигәнәк кадалган, кан чыгып тора, әрни. Иштә[1], кайвакыт арзан эзләп, кыйммәтдән дә калырсың, ди. Шулай икән, дөрест, кесәңдә булса, җаныңны сакла икән, икенче тәвә яллап, Җиддәгә барып йитеп, хаҗиларымызны табып, алардагы нәрсәләремезне сәламәт кулга алып, бер-ике көндән пароходка ултырып, Янбугга юнәлдек. Бер көнлек юл иде. Икенче көн барып йитеп,  пароходтан чыгып, фатирларга урнашдык. Монда бер дүрт-биш көн ятырга тугры килә, чөнки кәрванга кеше күбрәк җыела, көтәләр, су бик кадерле иде. Һәм дә кыйбат, уртамызга бер тәвә йөге суны бер алтынга алдык да, чиләк кадәрле булыр, ул да яңгырдан җыелып сакланган су иде. Бер көн игълан кылдылар: иртәгә Мәдинәгә кәрван чыга дип. Йөгереп барып кассадан билет алдык да, китүгә ятакларымызны җыеп, тәвәләр җыелып яткан урынга килдек. Мондан Мәдинәи-Мөнәүвәрә биш көнлек юл иде. Шулай итеп, биш рафикларымыз илән Мәдинә карап юнәлдек. Бишенче көн Мәдинәи-Мөнәүвәрәйә сәгать өчләр вакытында кердек. 10 чакрым кала бер тау юл буенда, Җәбәл-мәфрүхат диләр, шунда йөгереп менеп, коббә сәгадәтене күрдек диләр ки. Менмәсдән берничә ибдәшләр белән кәрван алдындан җәяү йөгердек, кәрвандан бер сәгать элек барып, Мина һәм мәйданында туктап, чәйханәдән чәй эчеп алдык, кәрван да килеп йитде. Мәккәдә күрешкән идек, Шафран стансасында якын Миндән авылының мөһаҗир Корбангали әфәнде безләрне каршылап чыгып иде, ибдәшләремез дә килде, Габделмәҗид Әхмәров белән мине, нәрсәләремезне хәммалга[2] күтәртеп барды. Аллаһның рәхмәтендән, амин. Яхшы адәм иде. Чәй-фәлән эчкәндән соң, тәһарәтләнеп, Җәнабе рәсүле Раббил-галәмин төрбәи шәрифәсенә юнәлдек. Баб-әссәлам дигән ишекдән кереп, салават, сәлам биреп: “وَقُل رَّبِّ أَدۡخِلۡنِى مُدۡخَلَ صِدۡقٍ وَأَخۡرِجۡنِى مُخۡرَجَ صِدۡقٍ وَٱجۡعَل لِّى مِن لَّدُنكَ سُلۡطَـٰنًا نَّصِيرًا”[3] аять кәримәсене укып, Мүәҗҗәһ сәгадәткә барып туктадык.  Үземнең кандай йирдә торганымны уйлап, һушым китә язды: ”Әй Ходаем, бу урынны бәндәгә күреп зиярәт итәргә насыйп итдең бит”, мең-мең Ходага шөкер кылдым да, торып, кулларымызны баглап, салават вә сәлам, соңра үземезгә Ходам атам-

---

[1] Иштә – чынлыкта.

[2] Хәммал – йөк ташучы.

[3] Уа Куль Рабби адхильни мудхаля сидкин Уахриджни мухраджа сидкин уадж`аль ли мин лядунка Сультана ан Насыра. “Исра” сүрәсе, 17 сүрә, 80 аять. Әйт: Раббым, керәчәк урынга тугры юлдан керт, чыгачак юлымны да тугры ит. Дөреслек белән эш кылырга миңа ярдәм ит.

анамыз һәм барча мөэмин бәндәләргә Ходам шәфәгате сорап дога кылдык. Хода кабул итсен.

***Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә җитеп, пәйгамбәремезнең кабер шәрифен зиярәт итдем. Мәсҗедән-Нәбавинең ни рәвешдә булуы.***

Янә хәзрәт Әбүбәкер, хәзрәте Гомәр разый Аллаһы рухына дога кылып һәм хәзрәте Фатыйма разыйаллаһы ганһәнең рухына дога кылдык. Димәк, бу Хөҗрәи сәгадәт эчендә дүрт кабер бар икән. Хөҗрәи сәгадәт – Хәраме шәриф исемендә Мәдинәнең олуг мәсҗеде, шуның эчендә мәсҗеднең бер почмак тарафында бу Хөҗрәи сәгадәтдер дип тә әйтәләр. Хәраме шәриф исә бик зиннәтле берничә йөзләп таш баганалар белән эшләнеп, һәрбер дүрт башына бер коббә кебек эшләнгән, эчдән караганда Казан кебек булып тора. Эч тарафы яхшы майлы буялып, һәртөрле аятьләр язылган. Коббәләр эченә бүлеп-бүленеп, Әмин дигән пәйгамбәремезне мәдех кылган китап язылган. Пәйгамбәремез заманындан бирле ничә мәртәбә зурайтылган, һәр кайусының кем заманында зурайтылганы язылган. Ярты ачык ябылган ягында идәнләре мәрмәр ташындан җәелгән. Багана төпләре җиз белән кыршаулап куелган. Ачык тарафы идәне комлык, башка нәрсә юк. Эчендә бер кое бар, хәзрәте Фатыйма коесы диләр. Бик кыйбатлы 70-80 лампалык ак кызыл пыяла, чуклы зур кандилләр, андан башка агач яфраклы рәвешдә бронзадан эшләнгән. Иң әгъла[1] Бохараның ефәк келәмләре түшәлгән намазлык урынына хасил келәм гаять зиннәтле һәм кешегә рух бирерлекдер. Ашкадар буенда Чытырман авылының әл-Могыль исемле бер старшина хаҗга барган вакытында Хәраме шәрифе нәбәвигә кереп чыкгач, әйтә икән, мин Николай падшаның дворецында булган идем, исем киткән иде. Бу мәсҗед андан да артык зиннәтле икән дип сөйләгән. Хәраме шәрифнең биш ишеге бар: Баб әс-сәлам, баб әр-рәхмәт, баб әл-мәҗиди, баб ән-нисаи, Баб әл-Җәбраил исемендә һәм биш манарасы бар. Хатынлар биш вакыт намаз, гаид җомгаларга киләләр. Мәсҗеднең бер нүешендән[2] аларга рәшәткә белән бүлеп куйганлар. Баб ән-ниса дигән ишекдән кереп, шундан чыгалар. Ястү намазындан соң мәсҗеднең ишекләре бикләнәдер. Һичбер кеше калдырмыйлар, фәкать хәрәм агалары кала диләр. Болар – ирлекләре алынган кара хәбәши нәселләре, шулар төн буенча мәсҗед эчендә каравыл булып йөриләр. Хәраме шәриф хакында язачак нәрсәләрем күп булса, хәзергә шушының белән канәгатьләнеп, башка максудка киләмез. Инде мәдрәсәгә урнашу мәсьәләсе калды. Айлыклы мәдрәсәләрдә хәзер генә бүлмә табылыр кебек күренмәде. Шулай да берничә көндән бәлки булыр, хәзер сез мәдрәсәдән бер айлык урын алып тор, җайлап урын табармыз диде Каргалының мәрхүм Гобәйдулла әфәнде. Шундан

---

[1] Әгъла – яхшы.

[2] Нүешендән – почмагыннан.

мәдрәсәдән бер хөҗрә, ягъни бүлмә алдым, урынсыз калганчы урынлы булып торырмын дидем. Мәдинәнең тиешле зиярәт гяһләренә[1] йөреп, зиярәт кылдык. Мәсҗеде "Коба", Өхед тагы янында хәзрәт Хәмзә зияраты вә башка Өхед шәһидләренә зиярәт кылып кердек. Бер көн Гобәйдулла әфәнде әйтде: "Бездән, безнең мәдрәсәмездән бер казанлы Бәдреддин исемле, Каргалы Исхак мулла углы булса кирәк, иртә сәгать тукызда минем янга кил, мәдрәсәмезнең хуҗасындан шуның урынына сорап карармыз" - диде. Бу мәдрәсә Хәраме шәрифнең Баб әс-сәлам капусының кергән вакытда уң тарафында Бәшир ага мәдрәсәсе иде. Мөхәммәдия мәдрәсәсенә каршы ул капуның сул ягында сәхабәләр гасырында бу мәдрәсә урынында Мәрван сәхабәнең йорты булган имеш. Бәшир ага дигән кемсәнә мондан ике гасыр мөкаддәм[2] Истанбулда төрек хәлифәләренең сараенда хезмәт иткән икән. Ул бер сәбәпкә бина Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә нәфи кылмышдыр. Ахырында Истанбулга кайтып, шунда вафат итмешдер. Кабере Әюб әл-Әнсари җамигысының янындадыр. Баш очында язылмыш ташы һәм бардыр. Ошбу Бәшир ага мәдрәсәсенә барып (мөдәррисе Гариф хуҗа дигән кеше иде), хөҗрәсенә кереп, безгә мәдрәсәгездән бер бүлмә бирсәңез икән дия. "Әүладым, хәзергә безнең мәдрәсәмездә урын юк", - дип җавап бирде дә, гафу итеңез дия, кулыны үбеп чыкдым. Китдем бик мәэюс[3] хәлдә генә. Икенче көн һәмшәриемез Гобәйдулла әфәнде: "Иртәгә килерсең, бүлмәгә шунда хуҗага янә бер рәҗа кылырмыз,"[4]- диде, чөнки бүлмә барлыгын бу беләдер. Икенче [көнне] барып керсәм, Гариф хуҗамыз Гобәйдулла әфәнденең бүлмәсендә чәй эчеп ултыра икән: "Нә вар, әүладым?" дия сорады, - "Дәһа[5] җәнәбеңезнең алдына килдем. Мөмкин булса, безләрә бер бүлмәңез" - дия Гобәйдулладан сорый башлады. Бу талибә Казанда яхшы укып килгәнме дия. Ул да авылда бик яхшы адәм дия мактап куйды да, шундан хуҗа: "Казанда нә үтдең, сарыф, нәхү укыдыңызмы?" - диде. "Әйе, укыдым" - дидем. Әл-кәлимәтел-ләфыз, мөфрәд - ни дигән сүз? - диде. Җавап бирдем. "Янә әл-кәлимәтнең әлиф, ләм вә җенес өчен нас вәхдәте[6] өчен бонлар арасында башкалык бар ди, нә дийүрсең," - диде. Бәндә җавабында диям. Әлиф, лямнең  җенесдән вәхдият җенесе аламыз да вәхдәт җенес туып, шул вакытда та әлиф-ләм дә бәрабәр булачак, дидем. Шундан Гобәйдулла әфәнде: "Фәрраш[7], ачкычны бирерсез", - диде. - Айлык килүре юк вакытча гына

---

[1] Гяһләренә – урыннарына.
[2] Мөкаддәм – элек.
[3] Мәэюс – өметсез.
[4] Рәҗа кылырмыз – үтенербез.
[5] Дәһа – тагын.
[6] Нас вәхдәте – текст бердәмлеге.
[7] Фәрраш – каравылчы, мәчет-мәдрәсә карап торучы.

торасың, кандидат булып, кайчан айлыгы бар, бүлмә бушап калса, шундук мине шул айлыклы бүлмәгә чыгаралар. Бер ай да үтмәде, бер шәкерд китеп калды. Мин дә мәдрәсәнең икенче катында бер бүлмәгә күчдем, Ходага шөкер, җан тынычланды.

***Мәдинәдә кемләрдән дәрес укуым. Коръәнхафиз кыла башлавым.***

Бер Ходага тапшырып**,** дәрес башларга калды**.** Беренче дәрес мәдрәсәнең үзенә вакыйф тарафындан куелган. Иртәләп бер ярты сәгать кадәр укып, вакыйф Бәшир аганың рухына дога кылмакдыр. Бу дәрес мәдрәсәдәултырган шәкердкә мәҗбүр иде. Мәдрәсәдә юкарыда язылмыш Гариф хуҗа иде. Икенче мәгърибиТунислек мәликел-мәзһәб әш-шәех Гомәр әфәндедән дәрес башладык. Барча шәрикләремез белә нәхүдән әл-Фәйтә ибне Малик, “Тәфсире Җәләләйн”, “Мифтах әл-голүм”, башка берничә фәнләрдән үзенең йортына барып укыр булдык, чөнки Хәраме шәрифдә бик күпчелек тәшвиш була. Шул сәбәпле, өенә барыр идек. Андан әш-шәех Габделкадыйр әт-Тыраблиси иде. Бу шәехдән “Сәхихел-Бохари”, боның йортына барып укыр идек. Андан Гайсә хуҗа Ширвани Мәдәнидән бәяне могайән, әш-шәех Хөсәен Һинди осуле фикъһ, әш-шәех Ризван рәхмәтуллаһы галәйһидән “Дәляил-хәйрат” вә башка хәдис силсиләләр укыдык. Әш-шәех Фалих дигән Мөхдисдән бераз ”Әрбәгыйн-и хәдис” укыдык. Шулай акрынлык белән генә укып, сәламәтлекдә бер сәнәне үткәрдек. Рәҗәп аена кадәр андан соң рәҗәбия диләр. Бу вакытда бераз тәгътыйль[1] була, чөнки Гарәбстан өлкәсендән кабаиль гарәпләр Раузаи-Мотаһһарага зиярәткә киләләр. Шул сәбәпле, шәһәр мәшгуль була, андан хаҗ вакытында бер ай тәгътыйль була, дәресләр булмый. Шунда бездәй шәкердләр хаҗга барып вә күңел ачып, һава алышдырып кайтыр, миңа бу ел хаҗ баруымыз мәҗбүр иде, чөнки әүвәлге хаҗны кеше өчен кылдым. Инде үзем кылырга кирәк, чөнки, бай булмаса да, бер кеше Мәккә Мөкәрәмәне күрсә, хаҗ фарызы буладыр. Бу ел шул хаҗны эда кылдым[2]. Хода кабул итсә иде, амин. Җамигъ шәкердләр һәм юлдашым Габделмәҗид вә башкалар барымыз да бардык, кайсылары хаҗилардан бәдәле хаҗ[3] алды. Кайсылары бай хаҗиларга юлга тәрҗеманлык кылып хезмәт итеп бардылар, һәр ничек дә барып кайту расход табыладыр. Хаҗымыздан сәламәт килеп, икенче ел дәрес башлар вакыты якынлап калды. Фәкыйрьгә бер фәкыйрь төшде. Кәлямулланы хифыз кылсам дигән бер Ходага ышанып, ярдәм эстәп, Раузаи Мотаһһарагә барып, җәнабе пәйгамбәргә, Ходага салават, сәлам биреп ният кылдым. Хафизга тотынырга Мисырлы Хәсән карый шәкердләрендән Мөхәммәдшакири бине Хафиз, шул

[1] Тәгътыйль – каникул.
[2] Әда кылдым – үтәдем.
[3] Бәдәле хаҗ – үз урынына кеше яллап хаҗга җибәрү.

шәехдән айга бер алтын бирелмеш шарт белән Кәлямулланы шуның тәхлиле буенча башладым. Һәр парәнең[1] башыннан бер кәгазь ятлап, утыз көндә утыз кәгазь ятлый башладым. Шул тәртибдә сикез айда ятлап чыкдым. Һәр көн остамызның алдына барып тыңлатып, киләчәк көнгә үзе укып бирер иде. Бер рәт ятлап чыкгач, тукыз ай тәкрар итдем, җәмгысе унйиде айда тәртип ятлап бетдем. Җәнабе хакның ярдәм бирүенә шөкеранәләр кылып, үземә үзем хәйран булып калдым, өнемме бу, төшемме бу хәл дия. Бу вакыт яшем егерме икедә иде. Бу хафиз белән бәрабәр һәркөн ике дәресемне дәвам итдереп килдем. Шулай итеп, янә хаҗ вакыты йитеп калды. Хаҗга барырга булдык, берәүдән бер йөз сумлык кына бәдәле хаҗ кылырга алдым да шул ук ибдәшләремез илән хаҗ китдек. Янбуг-Җиддә аша барып, тиешле хаҗымызны әда кылып кайтдык. 1324 нче һиҗриядә киләчәк рамазан шәрифдә вә Хәраме шәрифе нәбәви, Раузаи Мотаһһарада тәравих белән хәтем әйтүгә ният кылдым. Рамазан шәриф дә килеп йитде. Ходага тапшырып, үземә махсус Хәраме шәрифе нәбәвидән хәтем әйтәмен дип, хәрәмнең мөдирендән сорап, баб әс-сәламдән кергәч, озак түгел кыйбла ягына михраб маликидан ерак түгел урында урын насыйп кылды. Беренче рамазандан башлап, 23 тәравихда хәтем итүгә һәр көн бер чирекдән укуга тугры килде. Шул бер тәравихда укый торган Коръәнне көн буе тәкрар кылырга кирәк. Бер парә чирек Коръәнне һәркөн утыз кәррә утырырга кирәк. Шулай итеп, һәркөн100 бербөтен укырга тугры килде. Егерме өч көндә, башка һичбер нәрсәгә карамасдан, эшемез шул булды. Мирсәид Мозаффаров дигән ибдәшем бер мәдрәсәдә күрше бүлмәдә тора иде. Ул да минем белән бергә Коръән ятлар иде. Ул да хәтем итәргә булды. Икемез бер үзбәк шәкердне ифтар сәхәремезгә хәзерләргә керешеп, тиешле акчамызны биреп куйдык. Хәтем беткәнче шулай безне тәрбияләде, үзе һәм бергә ашар иде. Шулай итеп, мәсҗеднең әтрафында йиде карый бергә хәтем башладык. Без икәү, янә Гатаулла исемле казакъ карый, Каргалыда укыган, Хәйрулла хәзрәтдә, Пенза губернасы Хвалын өязе Мастак авылы Бәдреддин карыйның углы Гасыйм әфәнде иде. Янә бер үзбәк карый иде. Икесе хәтеремдә юкдыр. Шулай итеп барымыз да хәтем әйтдек. Хәтем кичәсендә укый торган урынымызны төрле фонарьлар белән, яхшы келәм намазлыклар җәеп куйдылар. Боларны Хәраме шәрифнең фәррашләре эшлидер. Хәтем кичәсендә үземезнең укый торган остаз кәрамләремез һәм башка һәмшәри шәкердләр, башка гарәп вә төрекләрдән күп кешеләр җыелмыш иде. Остазымыз тарафыннан хәтем догасы кылынып, соңра Мәдинәи-Мөнәүвәрә рәсеменчә җыелган халык хөрмә, манпасилар өләшенде, ибдәшләремә әйтеп, алдан хәзерләтеп,

[1] Парәнең – кисәкнең.

мәсҗедкә кәрзинкә белән алып килеп куйган иделәр. Булган кешеләргә өләшеп, янә бер дога әйтелеп таралдык. Хода кабул итсен, амин. Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә рәсем хәтем әйткән карыйга сәдака бирү гадәте юк. Билгакес[1], карый үзе сәдака өләшә. Юкарыда язылды, бу хәтем Хода ризалыгы өчен булган хәтем буладыр дип уйладым. Егерме өч тәравихда артымда самигъ[2] булып торган бер гарәп егетенә бер алтын бирдем. Соңыннан һәмшәри ибдәшләр чакырып, бер аш кылып, кунак итдем, Хода өчен булсын, амин. Шундан соң дүртенче хаҗ вакытымыз йитде, янә ибдәшләремез белән Мәккә Мөкәррәмәгә хаҗга китдек. Борынгыдай Йәнбәгъ-Җиддә аркылы сәламәт Кәгъбәтуллага тәвафымызны кылдык. Бонда укучы үземезнең Эстәрлебашдан китмеш мәрхүм остазымыз Хәбибулла бине Мөхәммәдхарис Тукаев хәзрәтләрене мәхдүме Габдрахман әфәнде иде.

***Авылдашымыз, остазымыз Хәбибулла Тукаев углы Габдрахман вафат булуы, аның дәфене хакында.*** Боның белән бер-беремез туганларча сөйләшеп, сүземез бетмәс иде, ул да сагынган. Мәгаттәәссеф[3], бу елда Мәккәдә ваба рәнҗүе чыга башлады. Бик куркышып калдык. Ходаның тәкъдиренә нә чара диярлек йөрдек. Бер көн, Гарәфәтдән әүвәл иде, Хәраме шәрифкә өйлә намазына барып, Габдрахман әфәнде белән бергә кайтдык. Юл уңаенда юкарыда бер язылган иде, Нәҗмеддин әфәнде тәкиясенә кереп, Фәррахеддинне күреп чыгыйк дип кердек. Керсәк, ул, бичара, каршы алып, рәхим итеңез, мактап йөрисез икән дип, пешереп торган ашны безнеултырып кунак итде. Ул вакытда Габдрахман да, мин дә Мәккәдә мәшһүр Шәехморад йортында тора идек. Кайтып да кердек, бу бичара Габдрахман, аллаһ, эчем авырта, ди башлады. Боңа мәшһүр рәнҗү эләкгән икән: ач йөри, көзән җыера, нишләргә белми: “Тиз докторга алып барыңыз”, дип үтенә башлады. Шундан тизлек белән докторга ләчинкә[4] белән күтәреп алып бардык, докторны таба алмадык, инде нишләргә кирәк. Әйтделәр, шәһәр докторына алып барыгыз дия, анда алып бардык. Ул хастаханәгә алып барырга кушды. Бу хастаханә махсус ваба авыруы белән авыручыларга төзелгән икән. Димәк, карантинханә. Монда башка кешеләрне кертмиләр иде. Бер доктордан үтендек, бу бер олуг адәмнең баласы, хаҗи дәгел, бурада[5] уку өчен килмеш адәм дия, мөмкин булса, яхшырак урынга куйсаңыз икән дия. Бойлә дип, больница мөдиренә бер записка язып бирде дә, янә күтәреп алып китдек. Ибдәшем Габделхәмид белән икәвемез бергә йөримез. Мәккәнең тышында

[1] Билгакес – киресенчә.
[2] Самигъ – тыңлаучы.
[3] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.
[4] Ләчинкә - носилка.
[5] Бурада – бирегә, монда.

бер чүп түгә торган урында икән. Күрсәк: ничә йөз хаҗилар комда аунап ята иделәр. Һинд, әфган, үзбәк, казакъ вә башка милләтләрдән күп, кайусы су ди, кайусы мәэ ди, гарәпчә, кайусы панай ди, һиндчә. Бу бичараларга су бирә торган кеше юк иде. Шунда үлеп калсалар, чокыр казылган, хезмәтче гарәпләр күтәрәләр дә, этеп, чокырга ташлыйлар иде. Хәйран калдык. Бер биш-алты данә чатыр да корып куйганлар иде. Моның эчендә берничә караватлар да бар иде. Докторның кәгазе буенча безнең Габдрахман һәмшәриемезне бер чатырга караватга салдылар. Эчәргә сорады, чәйханәдән чәйнек белән чәй алып килдек. Көн батуга якын калды. "Габделхәмид, юлдашым, - мин әйтдем. - Мин бик арыдым, кайтып ял итәм инде, төнләсен янында торыңыз", - дия. Миңа кайтырга булды. Шундан исәнләшеп киткән вакытымда: "Мәҗид, бәхил бул!" дип кычкырганы хәзер дә колагымда торадыр. Кайтып йокладым, таң беленүгә Габделхәмид кайтып килде, тиз бар, бик начарланып калды, дия. Шундук ашыгып йөгереп барып җитәм һәм хәзер генә җан тәслим кылган иде. "Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун"[1] аять шәрифәсенә буйсынды, дога кылдык. Тәмам. Инде калды гүрләргә, монда үлсә, хәзер казылмыш чокырга ташлыйлар. Бу безгә бит киләчәк вакытымызда йөземезгә каралык улачакдыр. Мәккәи Мөкәррәмәнең гомуми зияраты – "Җәннәтел-Мүәллә" диләр, шунда куешымыз кирәк иде, чөнки ваба авыруы булу сәбәпле, мондан башка зиярәткә чыкмыйлар. Ничек дә булса докторны күреп илтимас итдек: "Бирегез мәетне, үземез алып гомуми зияратка куямыз", - дия. Доктор әфәнде бераз рөхсәт итми торса да, кулларны сары май белән майлагач, рөхсәт бирде: "Тик үзеңез яхшылап юарсыз". Мондагы гарәп санитарлар, юдык дип алдап, киемләрен алып калып, кәфенләп китерәләр иде. Гарәпләр кәфенләп табутка салып алып килделәр дә, доктор әфәнде болардан сорады, юдыгызмы дип сорауга каршы, шулай, юдык, дип җавап бирделәр. Шундан доктор, ачуланып, ник алдыйсыз, юмагансыз бит, диде. Шундан бу гарәпләр "валлаһи юмадык" дип әйтделәр. Шундан ике гарәпне яллап, табуты белән алып китделәр дә, алып бардык "Җәннәтел-Мүәллә"гә, чөнки гомуми үлек юа торган йорт шундадыр. Барсак, егерме кадәр үлек, табуты белән тезелеп, юылырга керергә торалар иде. Көтү озакка бара торган булды. Ничек дә госелханә башлыгы аксакал шәехкә кереп үтендек, мөмкин булса, без талибене тизрәк юып бирсәңез икән дия. Таиб, бик хуш дигән сүз, шулай итеп, бу шәехнең, күп юу сәбәпле куллары ярылса кирәк, янә сары май белән кулларын майлагач, шундук безнең мәетне алып китеп юып чыкардылар. Кайда бармак йитә, шул сары май эшне йомшата икән. Бер мең сигез йөз туксан беренче

[1] Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун – без Аллаһ бәндәләре. Без аның хозурына барачакбыз.

елларда булса кирәк, Габдрахман мәрхүм атасы белән бертугма абзасы Габделмәҗид Харис Тукаев ничә еллардыр Бохарада укып кайтып, бер кыш Эстәрлебашында шәкердләргә дәрес әйтеп торды. Соңра Җаек суы буенда Илек дигән шәһәрдән Гобәйдулла хаҗи Килдышев дигән сәүдәгәрнең кызы Мәхфузәне никахлап, Эстәрлебашка төшереп, соңра шул елны ук хаҗ сәфәренә китде. Бу вакытда Габделмәҗид хәзрәтнең бертугма борадәре Габделкадыйр Мөхәммәдхарис углы Тукаев Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә укуда иде. Хаҗга барып, борадәре Габделкадыйрга кушылып, хаҗда Гарәфәтдә бергә булмышлар. Бу ел Мәккәдә ваба хасталыгы пәйда була. Шул рәнҗү белән Габделмәҗид хәзрәт Мәккәдә укып, борадаре Габделкадыйр Мәккәи Мөкәррәмәнең “Җәннәтел-Мүәллә” мәкъбәрәсенә дәфен кылып, башына таш яздырып куйдырган икән. Безләр дә бу каберне табып алып, шуның янына Габдрахман мәгъзүмне җирләдек. Боның вафаты 1908 нче миладиядә иде. Мәрхүмнең васыяте буенча калган акчасыны, бәгъзе бер киемләрене якдаш хаҗилар белән Эстәрлебашына анасына юлладык һәм сәламәт алганлар икән. Мәккәдә ваба авыруы бик көчәя башлады, хәтта урамларда үлеп ятучылар була башлады. Үземезгә дә нә була инде, Ходадан теләп йөримез. Шулай да Мәккәдән тизрәк чыгып китәсе килә иде. Ходаның рәхмәте, бер көн, уйламагандан, бер ягмур яуды. Шул көндүк ваба рәнҗүе дә су сипкән кебек бетте. Бер үлүче булмады, безләр дә, әлхәмдүлиллаһ дип, Мәдинәгә тугры, тиз йөри торган кәрвандан төяләр табып алып ялладык да, ибдәшләремез илә барымыз бергә Мәккәдән Мәдинәгә карап сәфәр итдек. Бу исә Мәккәи Мөкәррәмәдән дүртенче хаҗымыз соңра видагълашып аерылдык. Бу тиз йөри торган кәрванны гарәпләр ракиб һәҗин[1] тәвәләре дип әйтәләр. Бу кәрвандә чит хаҗилар бик аз була, фәкать Мәдинә әһленә вә башка бездәй талибәләр кебек кешеләр йөрер, әмириләр Мәккәдән Мәдинәгә барып кайтуга дип яллап чыгалар. Кәрванда өч йөз утыз йөз кадәр төя буладыр. Юлда алты сәгать йөри, алты сәгать ял итә. Шул рәвешдә йөри, көн уртасында эссе вакытларда йөрми, төнлә сәгать уникеләрдә кузгалып китә. Шул рәвешчә, Мәдинәгә сәфәрдә барамыз. Мәккәдән 1 нче куныш Вади-Фатыйма исемле урын иде. Сулы, яшелчә үләнле урын иде. Берничә көндән соң юлымыз бәхре әхмәр буенда Рабигъ дигән гарәп карьясенә йитешүемез кирәк иде. Рабигъга барачак кичәдә төнлә бик каты күк күкрәп яшен яшьнәп ягмур яуды, төяләр бара алмас булдылар. Аяклары тая, төн караңгы иде. Сахрадан тау арасында яшен генә якты күрсәтеп куяр иде. Туктап, төяләремез астында утырып тордык. Таңда якынлап калса кирәк, кәрван башлады, безләр чокыр урында туктаганмыз икән, хәзер күчеп калыйк, юкса,

[1] Ракиб һәҗин – тиз йөрешле.

ягмур ташуы килеп басачак диделәр. Безләр дә акрын гына төяләремезне йитәкләп, тау буенарак барып туктадык да, шунда ятыра да башлады. Утлар ягып, өст-башымыз бик су булу сәбәпле, бераз елындык да, иртә намазын укып, кузгалып китдек, үземез җәяү хәлдә, төяләремез акрын гына атлап баралар иде. Рабигъ дигән карьямез бер биш километр калса кирәк. Шунда барып йитдек. Ни күз белән күрәсең, ягмурның суы ташып килеп, юлымызны майлап куйган иде, чөнки Гарәбстанда таулар бар да кара таш булу сәбәпле, бөтен су таудан төшеп, бер юл табып, бер дәрья хасил буладыр. Гарәпләр боны сәбил дип әйтәләр, судан үтүгә мөмкин түгел иде. Шушы Рабигъда өч көн ятып, дүртенче көн төяләремезнең корсак астындан судан үтеп китдек. Ходага шөкер дип, хәтта ки Мәдинә әһлиясе кәрван вакытында килмәү сәбәпле, юлда бер хәл булгандыр дип куркышып торганлар, чөнки кәрван Мәккәдән чыгу белән фәлән көн чыкдык дип телеграмм бирәләрдер.

Шулай сәламәт Мәдинә якынлап калдык. Җәбәле гаир дигән бер биек тау юлымызда бар икән. Бу таудан башка кәрванлар үтә алмыйлардыр. Фәкать мәзкүр безнең ракиб дигән йиңел кәрван гына үтәдер. Чөнки бу тугры юлдыр. Тауның итәгендә төшләп, тауга юнәлдек. Үземез барымыз да җәяү, төяләр кыя, зур ташлар арасында акрын баралар иде. Тик бер сукмак кына иде. Әгәр дә төя еглып китсә, тәмам. Шул сәбәпле, безләрне төяләремезгә мендермәйләр. Шул рәвешдә 6 сәгать вакытда көн баюга тауның өстенә сәламәт чыгып, шадлык фәлән, шул кич шунда йокладык. Мондан ике көн соңра Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә керәчәкмез. Аллаһга шөкер, Мәдинәи Мөнәүвәрәгә йитеп, Зөл-хәлифә дигән йирдә туктап, кәрванларымызны калдырып, җәяү шәһәргә китдек. Бондан биш километр чама иде. Сәламәт мәдрәсәмезгә кайтып кереп, мунчага барып юынып, яхшы киемләремезне киеп, Раузаи-Мотаһһара зиярәт кылып, шул киемләремез илән кайтып, кәрванларымыз янына барып, төяләремезгә менеп, яшел флаклар күтәреп, касыйдә, ягъни шигырьләр укып, салават-сәлам белән хәрам эн-Нәбавинең баб әс-сәламенә туктап, мәдхе эн-нәби хакында булган касыйдәләрне укып, шундан хәзрәте Хәмзә вә Өхед шәһидләренә зиярәт кылып, мәсҗеде Коббәгә барып, тиешле урын зиярәтләремезе тәмамлап, төяләремезне хуҗаларына тапшырып, мәдрәсәмезгә кереп урнашдык. Әлхәмдүллиллаһ, Раббил-галәмин. Хода хаҗымызны кабул идеп, гөнаһларымызны мәгъфирәт кылсын, амин. Инде сәламәт булсам, 1326 һиҗридә, мәүлүд аены үткәреп, мәмләкәтемезгә кайту ниятендә идек. Бу остазларымызны зыяфәт кылып[1], бер ляихәләрен[2] алып китүем кирәк иде. Һәм дә Кәлямулланы хифез кылып[3],

[1] Зыяфәт кылып – хөрмәтләп.
[2] Ляихәләрен – язуларын.
[3] Хифез кылып – ятлап.

хәзрәт рәсүлемез мәсҗедендә тәравих белән хәтем кылуымызга һәм кыйраәт монын дөрест булуына бер шәһадәтнамә алу лязим иде. Бер көн аш кылып һәм мөдәррисләремезне һәм ибдәшләремезне зыяфәткә чакырдым, олуг остазларымызга мөрәҗәгать кылдым: "Сезләр рөхсәт бирсәңез, безләр мәүлүд аендан соң мәмләкәтемезгә кайтуга ният кылып идек" - дидем. Соңра мөхтәрәм остазымыз Мөхәммәдшакир әфәнде мәҗлестә булган мөдәррис вә башка карыйларга мөрәҗәгать кылып: "Бу Габделмәҗид әл-Кадыйри әфәнде безем хозурымызда Кәлямулланы хифез кылып һәм хәрәме нәбавидә тәравих белән хәтем үткәрде. Инде сезләр бу әфәнденең Кәлямулланы югарыда әйтелмеш рәвешчә иҗазатнамә[1] бирәсез" - икән дип. Болар да шул мәҗлесдә бер Кыйраәте Кәлямулланы миндән укытып, яхшы иҗазәт бирүеңезгә мөмкин диделәр. Соңра үзендән башлап әүвәл кемдән укыган, пәйгамбәр Ходага барып тоташканга кадәр язып, мөһерләп, иҗазәтнамә бирде. Башка иҗазәтнамәләрем авылга кайткач, 1923 нче елда мөфти әһле ислам Галимҗан әл-Баруди хәзрәтне мөфти әл-ислам сыйфаты белән Кәлямулланы һәм хәдис нәбәвине укырга иҗазәтнамә биреп иде. Кәндинең мөбарәк имзасы белән барлык иҗазәтнамәләрем 1930 нчы миладиядә хөкүмәт тарафыннан йортлар вә милекемезне җәбрән[2] мөсадәрә[3] иткән вакытда булган китапларны һәм чыгарып ташлап, шул вакытда гаиб улмышдыр[4]. Инде, хода насыйп итсә, кайту ягына юл хәрәкәте кылырга калды. Бу ел Хәмидия Хиҗаз тимер юлы исемендә Шам шәрифдән Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә юл эшләнмәгән иде. Мәдинәи-Мөнәүвәрәнең Бабел-ганбәр дигән урынына чыгып, безләрдән тәгътыйль көнләремездә тачка белән юл хезмәтенә иштиракь итәр[5] иде, чөнки бу юл бер мокаддәс юл хисап кылыныр иде. Безләр исә шул тимер юлы өчен Шам тарафыннан гаскәр химаясендә кәрван белән тиешле юл әсбаблары китерер иде. Шуларның килүене көтеп тормакда идек, чөнки Шамга барыш юлы да куркынычлы иде. Сәбәбе исә хөкүмәтнең юл салуына Англиянең игъвасы[6] белән бәдәви гарәпләр юлны эшләтмәү максатда улып, әсбаб китә торган кәрванларны үткәрмәсләр иде. Шуңа бинаән,[7] хөкүмәт корал куәте белән китерер. Англия бу бәдәвиләрне шулай котырта: әгәр дә Төркия хөкүмәте юл эшләтсә, сезләрнең төяләреңезгә эш булмай кала, андан сезләр ачка үләсезләр. Шуны әйтеп, боларга мылтык вә патрон кебек нәрсәләрен таратып ята. Шулай итеп, хөкүмәт кәрваны фәлән көн килә икән

[1] Иҗазәтнамә – рөхсәт кәгазе.
[2] Җәбрән- ирексезләп.
[3] Мөсадәрә – конфискацияләү.
[4] Гаиб улмышдыр – юкка чыкты.
[5] Иштиракь итәр – катнашыр.
[6] Игъвасы – котыртуы.
[7] Бинаән – таянып.

дигән хәбәр чыкды. Шулар килүгә дип, безләр дә хәзерләнеп, бөтен юл нәрсәләремезне җыелып куйдык. Моңа бу көн иртәгә китәмез дип торамыз. Шулай итеп, 70 данә кораллы гаскәр белән кәрван Мәдинәгә килде. Юлда да бәдәвиләр белән сугыш-килмешләр. Инде кайтуга шулардан куркып, бу кәрван бер ай китә алмый ятды. Безләргә дә хәзерләнгәч, бер ай торырга тугры килде. Хөкүмәт бәдәвиләр белән килешеп, кәрван китәргә булды. Шулай итеп, Раузаи Мотаһһарага барып, хәзрәте нәбәви әфәндемезгә салават-сәлам биреп, видагълашып, Мәдинәдән сәфәр итдек. Шәһәрдән кич чыгып, шәһәрнең читендә кундык да, иртәләп кояш чыгу белән йөреп китдек. Калган һәмширә ибдәшләремез килеп, видагълашып озатып калдылар. Хәерле сәфәр, амин. Безләр бер өч көн төя белән барып, эшләнеп ята торган юлына җитеп, шундан поезд белән Шам шәрифкә китәргә иде. Икенче көн кич улып, кәрван яланга кунарга булды. Минем рафикъларым Мирсәид Әсфәндияр мулла углы Мозаффаров, Алабуга өязе Чиркәс вулысыныкы, икенче рафикым Мөхәммәдхәлил Солтанбеков, Минзәлә өязе Чаллыга якын Бигәш авылыныкы иде.  Мәккәи Мөкәррәмә мөҗавирләрендән шәех Мөхәммәдморад үзе, Мәдинәи-Мөнәүвәрә мөҗавирләрендән Хөснулла Хәмидов – Чистай шәһәрендән, Гыйзззеддин Шафран станциясенә якын Василий авылындан, болардан башка  Мәдинәлек гарәпләрдән дә байтак кешеләр күп иде. Йитмешләп кораллы гаскәр шулай итеп кунарга төшеп, аш-чәй хәзерләп яткан вакытымызда биш-алты карт бәдәви гарәпләр килеп ултырдылар да, сәлам биреп исәнләшеп, ни өчен килүләрен сөйләделәр. Безләргә фәлән кадәрле акча бирмәсәңез, кәрванны юлымыздан үткәрмимез, дип. Әһле Мәдинәдән башка кешеләрдән аламыз диделәр. Боларның соравы буенча кеше башына 40 тиен икән. Хәзер җыеп алдык да, ничә йөз сумга йиткәндер, барын да бәдәви картларның кулына бирдек дә, болар разый булып, иртәләп үземез килеп озатып йибәрәмез, без килми китмәңез, диделәр. Исән-сәламәт йокладык. Иртәләп торып төяләремезне бәйләп, йөкләремезне салып көтеп торамыз теге карт бәдәвиләрнең килүне, кояш да байтак югарылап калды, юк халыклар, әйдә, йөримез дип кузгалып китдек. Берничә километр бардыкдан соң, уң тарафымыздан таудан безләргә ата башладылар, выж-выж итеп пулялар килә башлады. Кешеләре күренми, безләр дә һәммәбез дә төяләремездән төшеп, төягә ышыкланып, төяләремезне куалый башладык. Шулай да бер-ике төягә зарарсыз гына пуля тиде. Шундан бу тугрыдан кәрванымыз үтеп китде, яңадан атмый башладылар, чөнки бу бәдәви гарәпләрнең рәсми буенча аткан турыда кәрванны туктата алса, килеп һөҗүм итәләр, туктата алмаса, артдан кумыйлар. Безләрне туктата алмагач, безгә дә атмый башладылар. Ярый, сәламәт үтдек, куанышып китдек, янә бер 4-5 километр барган идек, янә сул тарафымыздан ата башладылар, бу вакыт

күп кенә атулар була башлады. Безнең йитмеш кораллы гаскәрләремез төяне чүкәреп, төя ышыкындан каршы ата башладылар. Янә күбрәк безнең һәм төяләр өстенә пулялар килә башлады. Төя хуҗалары төядән читкәрәк чыгып, ялан өст көйгә ата башладылар, чөнки үзләренә тисә дә, төяләр сәламәт калсын өчен безләр дә, каршы атмагыз дип, боларны атудан туктатып, ак флаг күрсәтдек тау ягына карап, шундан атыш туктады. Соңра, янә хуҗаларындан берничә гарәпне йибәрдек тауга: нә вар, нә теләкләре бар икән дия. Болар да барып күреп кайтып килделәр дә, һәр кеше башындан, җирләрендән үтәр өчен, бер мәҗидия (бер сум алтмыш тиен) акча сорыйлар. Без әйтдек, кич кунган йирдә безләр акча җыеп бирдек бит, дип. Алар әйткән: "Безләргә ул акчадан бүлеп бирмәделәр. Шуның өчен без үземез кәрванны туктап алырмыз дип килдек. Башка нәрсә юк, без сораганны биреңез дә, юлларыңызга китә биреңез", димешләр. Тиз генә һәммә кешене тезеп куйдык да, һәркемдән бер мәҗидиядән алып, булган акча янә шул гарәпләремезгә барып биреп килеңез дия. Алар да тапшырып кайтдылар да, юл ачык дип кузгалып да китдек. Юлда каршымызга йикермеләп төяле бәдәви гарәпләр килеп, сәлам биреп, бераз безнең белән бардылар да, борылып, тау арасына кереп китде. Аларны без күрмәгән, без аларны күрмәгән кебек булып калдык. Юлымызда бер тау бар икән, шунда барып йитдек. Шул көнне өйлә вакытларында тимер юл эше эшчеләр янга килеп йитдек. Поезд тавышлары ишетелә башлады. Эшчеләр бар да төрек гаскәрләре иде. Йөк вагоны белән рельсларны китереп юлга салалар иде. Су юк, көн эссе, бичара гаскәриләр тозлы [су] эчеп эшли иделәр. Шул йирдән буш ачык вагонларга ултырып, паровоз кире этдереп, станциягә кадәр алып китделәр. Һәдия исемле станциягә килеп туктадык, вагонлар ачык, көнләр эссе, вагон эчендә чәй кайнатып, аш пешереп ашап, берничә көн ятдык. Шундан соң (Кодәм шәрифкә) Шамга билет алып, яхшы вагонларга ултырып китдек. Юлымызда Мәдаин-Салих дигән стансага туктап, безләрне карантинга төшерделәр. Юлдан ярты километр урында чатырлар корылган иде. Һәрбер чатырга бүлеп, безләрне урнашдырдылар. Димәк, бу йирдә биш көн карантин саклап, андан безләрне Шамга йибәрәчәкләр икән. Бу йир тарихда һәм Коръәндә мәгълүм Салих пәйгамбәрнең халкы торган йир икән. Кибән кебек түгәрәк таулар бар иде. Бу тауларның югарыда ишек-тәрәзә тиешләре күренеп тора иде. Якын булса да, безгә барып йөрергә рөхсәт итмәделәр. Кәлямуллада [1] يَنْحِتُونَ مِنَ الْجِبَالِ بُيُوتًا дигән аять кәримәсе шушы таулар хакында булса кирәк. Биш көн карантинымызны сәламәт үткәреп, поездга ултырып, Шамга сәфәр кылдык. Бер-ике көн китдекемез соңында Тәбүк дигән станциягә килеп

[1] Коръәннең 15 сүрә 82 аяте.

йитдек. Бу урында пәйгамбәр заманында Тәбүк мөхарәбәсе[1] булмышдыр. Һәм яхшы мәсҗед дә бар. Шундан соң куйдылар да бер үземезне алып китделәр. Ни өчен икәнен белмәс. Кайсысының азыклары беткән иде. Сатып алырга юк. Шундан соң безләр мәҗбүр улдык Хайфада тора торган юл министры Назыйм пашага телеграмм бирергә. Күп дә вакыт үтмәде, стансадан начальниклар килеп, ни өчен безгә әйтмәсдән Назыйм пашага хәбәр бирмеш дия. “Безләр, - дидек, - сез үзеңез беләсез, без ничә йөз кеше монда кыйналып ятканны, нә өчен килеп хәлемезне белмәдеңез” - дидек. Тиздән паровоз да килеп йитде. Безләрне озатып йибәрделәр. Шундан Маган дигән стансаны үтеп, Шам шәрифкә барып сәламәт йитдек, әлхәмдүлиллаһ. Багажларымызны носильщикка күтәртеп, шәһәргә китдек. Шәһәрнең крепосте һәм керә торган капкасы бар икән. Җырларда җырлый торган иделәр:

Шәм шәриф дигән ай шәһәрдә
Ахшамсыз лай капка ябылмас

дип, шул хәтеремә килеп төшде дә, Хәмид дигән бер ибдәшемез бар иде, җырга оста гына иде. Ибдәш шушы капка төбендә җырлап да йибәрде. Ходага шөкер, бу җырны шәһәрнең капкасы төбендә җырладык дип, капкадан кереп китеп, бер яхшы гына отельгә төшдек. Кеше башына тәүлекгә 40 тиен түләп тордык. Шундан мунчага барып юындык. Чөнки 17 көн юлда килмеш идек, хәтта эсседән битләремезнең бер кат тиресе көеп төшкән иде. Мунчага бардык, гаять яхшы икән, эчендә – залында - йылы күлләре дә бар иде, мәрмәр ташыннан ясалган әтрафы. Кеше башына кырык тиен түләп кердек. Мунчадан юынып чыкганга кадәр биш төрле ак простынялар бирделәр. Күлендә йөзеп йөрдек. Шундай күңелле иде. Юынып кайтып, шәһәрне тамашага чыкдык. Шәһәр бик күңелле, бакчачылык, урамларда зур гына сулар агып тора, ике ягында трамвай йөреп тора, европейский формасында магазинлар күп. Сөт, ит, май күп, шәһәрнең әтрафы таулы-таулы, тирә-ягы мәйвә бакчасы, өрек, йөзем. Мисалы Ташкендка охшаган шәһәр икән. 1 нче җамигы Өммәвидә “Сәхихел-Бохари”ны укыта торган әш-шәйхе Бәдреддин үзе мәдрәсәдә тора икән. Яше сиксәндә иде. Җәмәгать алмаган, һәр җомга көн җомгадан соң бер сәгать кадәр Бохаридан дәрес бирә икән. Халык күп, безләр дә дәресендә булдык, андан Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә остазымыз шәех Габделкадыйр әт-Тыраблиси хәзрәтләре бу кешегә мәктүп безнең белән язган иде. Соңра (җамигы Өммәви Шам шәрифдә өммәви хәлифәләре заманында салынган мәсҗеддер). Бу мәсҗеднең бер манарасы да манараи байза[2] дип исем бирделәр. Ахыр заманда хәзрәте Гайсә шул

[1] Мөхарәбәсе – сугышы.
[2] Манараи байза – Ак манара.

манарага төшәр имеш дип иске китапларда бардыр. Шуны күрдек, янә шул манара төбендә мөҗаһид әл-ислам Сәлахеддин Әюбинең төрбәсенә кереп, зиярәт кылдык. Ишекендә бер гаскәри карт тора икән, рөхсәт сорап, кабернең эченә кердек, зур рәшәткә белән уратылган, өстенә яшел постау ябылган, баш очында зур яшел чалма уратып куелган иде. Астанасында бер ядкәр венок куелган, Алмания падишаһы Вильгельм тарафыннан хөрмәт ителеп куелмышдыр. Кайчанда Шам вә Коддес шәрифкә сәяхәте вакытында венок астына әйләндереп кәримә язылмышдыр. едия аят أَنَّ اللهَ لاَ يُضِيعُ أَجْرَ الْمُؤْمِنِينَ[1] Каравылчы картдан сорадык: “Баба фазыл, бу куелмыш венок алтынмы, юкмы, көмешме?” дия. “Кяфер сиңа алтындан куярмы?” дия җавап бирде. Соңра мәсҗеднең бер тарафында хәзрәт Хөсәен разый Аллаһы ганһенең башын кисеп, Шам башлыгы Язид мәльгунгә китергәнләр икән. Шул хәзрәт Хөсәен разый Аллаһы ганһенең башы шушында күмелгән икән. Ул заманда бу урын Язиднең хәзинә сарае улмышдыр. Мондан чыгып, мәлик әз-Заһир көтепханәсенә кердек. Шамда тугыз көтепханә булган икән. Яурупалылар көтепханә[дәге] кадерле китапларны угырлый башлый, калган китапларны бер шушы мәлик әз-Заһир көтепханәсенә җыеп, бер көтепханә кылмышлардыр.

***Шам шәһәрендә***

Көтепханәнең эченә керсәк, китап бик күп, рәсүлүллаһ заманыннан бер йөз илле ел соң язылган китапларны күрдек, мәгаттәәссеф[2], китап укучы ислам адәмләрен күрмәдек. Берничә кешеләр булса да, инглиз, французлар иде. Мондан соң Шам шәрифнең гомуми мәкъбәрәсенә барып, анда сәхабәләрдән хәзрәти Билал Хәбәши мөәзин рәсүлуллаһ дип язылмыш ташы бар иде. Андан Габдулла ибне Өмме Мәктүм разый Аллаһы ганһегә зиярәт итдек. Боның кабер ташына язылмыш кабре Габдулла ибне Өмме Мәктүм дия. Аның хакында Коръәндә أَن جَاءهُ الأَعْمَى аяте язылмышдыр, шәһәр عَبَسَ وَتَوَلَّى[3] эчендә Мөхеддин бине Гарәби рәхмәтуллаһы галәйһигә барып, коббәсенең эченә кереп зиярәт итдем. Бондан Памук баба дигән бер зиярәткә бардык. Бу Памук баба көрд милләтенннән бер әүлия улмыш. Кешеләр көрд милләтендән әүлия буламы дип, тагын әйткәнләр имеш. Соңра үлгәндән соң каберендән аягыны чыгарып күрсәткән имеш, әүлиялыгыны белдермәк өчен. Кабернең өсте ябулы, бер тарафындан икмәк пиче шикелле түрендә Памук эчендән бер карт гына аяк күтәрелеп тора иде. Хакыйкатьне бер Хода беләдер, адәмләр күп зиярәт кылалар имеш. Шамда бер тауга мендек. Монда, ягъни бу тауда адәмнең ике угылы Кабил Һабилне үлтергән имеш. Шунда

---

[1] Әли-Гыймран сүрәсе, 3 нче сүрә, 171 нче аять.
[2] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.
[3] Коръәннең 80 сүрәсе, 1,2 аять.

бер тау тишеге бар. Түбәсендән тамчы тамып торадыр. Шундагы хезмәт итеп хаҗилардан сәдака алып керүчеләр әйтәдер: “Тау әйткән, имеш, Кабил Һабилне үлтерүе өчен адәмләр аз вакыт кына еларлар. Мин исә кыяматкә кадәр еглыймын”, - дия. Телгә килеп таш сөйләгән имеш. Менеп күрсәк дә, без, дини хорафат дип уйлап, кайтдык, ышанмадык. Янә бер тауда без бара алмадык, тагын бу тауда мәхәл әрбәгыйн гаиб кырык ирләрнең михрабы дип, кырык михраб ясап корганлар. Тиешле урынларны күреп һәм зиярәт кылып, Коддес шәрифкә сәфәр кылдык. Шам-шәрифдә Дәмәшыкдә Бәйрәмкә исемле вокзалдан ултырып, поезд белән Бәйрут шәһәренә сәфәр кылдык. Бу йирдән Бәйрут тукыз сәгатьлек юл иде. Җәбәли Лөбнан[1] тагларны үтеп, Бәйрут шәһәренә барып төшдек. Җәбәли Лөбнан тагларында нәсари[2] гарәпләр яшиләр икән. Мәгыйшәтләре ефәкчелек һәм мивәлек[3] белән икән. Бәйрутда Һиҗаз отеле дигән номерга төшдек. Монда берничә көн күреп йөрдек. Американлылар тарафындан салынмыш мәктәп кәлимәне күрдек. Кино вә театрларны тамаша кылып, бондан биш посылка китап йибәрдем өебезгә. Бәйрут шәһәре – олуг шәһәрдер, әһалисе төрле, күбрәк насари гарәбләрдер, телләре гарәп, китап вә гәзитәләре һәм чиркәүләрендә дә гарәпчә укыйлар. Боларның галимләре дә күпдер, гарәпчә китаплар язганлар. Бер китап аятьләрне табу өчен йиңел рәвешдә язылган. Шушы Бәйрутда гарәп нәсара галимләре тарафындан язылмышдыр. Ак диңгез буенда (Средиземное море) һәртөрле милләт күп: инглиз, француз, американ, нимес, исраилләр. Һәр милләтдән күбдер. Һәр хөкүмәтнең сәфаратханәсе, ягъни консуллары бар. Безнең Русиянең бар иде. Мондан пароход белән Хива дигән шәһәргә китдек. Андан Яффа дигән шәһәргә барып төшеп, поезд белән алты сәгатьлек юл икән, Коддес шәрифкә китдек. Сәламәт килеп йитдек. Ходага шөкер. Монда беренче максадымыз мәсҗед Аксаны күрү, икенче Сахратулланы[4] күрү һәм башка зиярәт урынларыны күрү иде. Мәсҗеде Аксага барып, эченә кереп намаз кылдык. Соңра Сахратулла мәсҗеденә йөреп, намаз укыдык. Сахратулла мәсҗеденең эчендә йикерме метр, бәлки артык булыр, түгәрәк бер кара таш скаладыр. Бу ташка басып, пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәлам мигъраҗга килгән вакытында күтәрелгән имеш. Һәм бу ташда аяк эзе дия ташның бер йирен күрсәтәләр. Ташның асты подвал кебек, тышдан чыгып әйләнеп астына керәсең, буш бер бүлмә кебек, өч тарафында мәрмәр таш белән терәү куелгандыр. Әйтәләр, әүвәлдә Сахратулла буш һавада асылынып торган имеш диләр. Астына кергән вакытда, кешеләр курыкмасын

---

[1] Җәбәли Лөбнан – Лөбнан тауларын.

[2] Нәсари – христиан.

[3] Мивә – җимеш.

[4] Сахратулла – Куббат әс-Сахра мәчете.

дип, терәүләр куелган имеш. Пәйгамбәремез Мәдинәгә килгәч, шушы Сахратуллага карап намаз укыгандыр. Һиҗрәтдән икенче елда Ходадан әмер килгән. Шундан пәйгамбәремез өйләме, икендеме намазында Мәккәи Мөкәррәмәгә Кәгъбәтуллага карап, намазны тәмам кылган. Бу урында Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә шәһәрдән тышдарак мәсҗед әл-Кыйблатайн дигән мәсҗед бардыр. Кыйбласы ике якда, бер стенасы Кәгъбәтулла тарафында, берсе Сахратулла тарафындадыр. Мәсҗеде Акса ике катлыдыр. Асты зур сарай кебек, бер читдән кою капкачы кебек кенә төшә торган юлы бар. Астына төшеп күрдек: бу Сөләйман г-м. заманында булган бина, монда ат сарайлары булган имеш диләр. Төшкәч дә бер урында мәрмәр ташындан эшләнгән бишек кебек бер ядкәр бардыр. Бу бишекне Алмания императоры Вильгельм бонда сәяхәт вакытында Гайсә пәйгамбәрнең туган урыны дия бу ядкәрне куеп китмешдер. Мондан соң хәзрәте Мәрьям анамызның каберенә бардык. Йир астындагы бер подвал эченә берничә баскычдан төшеп кердек. Фәррашлары бар да нәсари милләтендән руханилар иде. Рөхсәт сорап кердек. Зур зал, бер тарафында бүлмә бар.

Бүлмәнең эчендә кабере өстенә өстәл кебек кылып капланган, аның өстенә яшел постау ябылган, башының өстендә кечкенә генә салиб[1] куелган һәм дә балавыз шәм янып торадыр иде. Безләр дә хәзрәтемезне гөнаһсыз бер хатын булуны Кәлямулланың күрсәтүе буенча зиярәт кылмак тиешлемез дип зиярәт итдек дә чыкдык, зал ягында берничә урында аякга торып укый торган мәрмәр өстәлләр бар иде. Нәсариларның һәрбер мәзһәбе үзләренчә шул өстәлгә басып укыйлар имеш. Мондан соң зур бер кәнисәгә[2] кердек. Бу кәнисәнең ачкычы гарәпләр кулында тора икән. Нәсарилар кереп гыйбадәт кылгач, бу гарәп каравылы бикләп ала икән. Эченә кердек. Эчендә ничә төрле мәзһәбдә булган нәсарилар гыйбадәт кылып яталар иде. Кайсы берәүләре тезләнеп ултырып, безнең кебек кул күтәреп, дога кылалар иде һәм амин дип әйтәләр иде. Мондан чыгып, Русия хөкүмәте тарафындан салынмыш монастыйрьгә бардык, кереп күрдек: монах вә монашкалар бик күп иде. Башлыкларындан сорадык: “Безләр Русияле Казан татарлары, рөхсәт итегез бер монастырьне кереп күрер идек”, - дип, мәмнүният белән ачкычларны күтәреп алып чыгып, ачып күрсәтде. Кәнисәләрнең башына салибләр бар да алтын иделәр. Шундаг бер тау башында бер манарага алып күрсәтде, бик биек иде. Бер йөз йитмеш баскычы бар тимердән, әйләнеп мендек, башына чыкдык, бер зур колокол бар иде. Башка нәрсә юк. Бу шундай манара икән. Бу таудан хәзрәт Гайса г-м күккә күтәрелгән имеш. Манарадан еракда бер бакчалары да бар. Бер мәсҗед күренә, шунда Муса г-м.-нең кабере дия

[1] Салиб – хач.

[2] Кәнисәгә – чиркәүгә.

күрсәтделәр. Коддес шәрифдән егерме километр ераклыкда Хәлилрахман диләр, Ибраһим г-м.-нең кабере шәрифе шунда икән. Мәгаттәәссеф, бара алмадык, юлы мәшәкать: ишәк, төя бик кыйбат алалар икән. Коддес шәрифнең әһалисе күпчелек яһүдләр икән, картлары ак кәләпүш киеп, чигә сакаллары бик озын була икән. Кулларына тәсбих тартып утыралар иде. Русча бу Коддес шәрифне Иерусалим диләр. Инде мондан Мисырга бару ниятемез иде. Карантин, Мисырга хәзергә хаждан килгән кешеләр өчен юл юк дип, йибәрмәделәр. Шундан кире Бәйрутка кайтып китдек. Инде мондан Истанбулга китәргә кирәк иде. Бер көн рафикъларыма әйтдем: “Әйдәңез, иртәгә Русия сәфаратханәсенә барамыз”, - дидем. Нигә анда барамыз, диешделәр. “Бер эш бар, Хода кушса, бәлки шул эш булмасмы”, - дидем. “Ул нәрсә?” - диделәр. “Сез бит сайдан йөзәсез, Русиянең кануны буенча үзенең тәбәгасыны,[1] юл хәраҗәте булмаса, консул ярдәм итеп, буш озатырга тиеш” - дидем. Акчамыз юк имәс, алтын хисабына биш йөз сум акчамызны алдан Истамбулга перевод кылганмыз. Шулай булса, хөкүмәтнең кануны булгач, безләр шәкердләрмез, укучылармыз, безгә ярдәм итәргә тиеш дип, хинзирдан[2] бер төк булгандай булыр. “Ярый, барыйк иртәгә”, - диделәр. Иртә булды, көн чыгышы белән сәфаратханәгә юнәлдек. Бик озак икән, барып тапдык. Ишегендә каравыл тора икән. Африкалык кара бер кеше формада киенгән зобани кебек, карарга котың калмас, шундай кара һәм олуг гәүдәле, төрекчә белә икән: “Ни кирәк?” - диде. Без әйтдек, консулга килдек, эшем бар иде, дидек. Кереп китде дә, бераздан соң кереңез, дип, безне кертеп йибәрде. Барып идарәсенә кердек, идарәдә сәркатибе генә ултыра икән. Йомышымызны әйтдек. Ул кереп консулга әйтде дә, шундук консул килеп чыкды да: “Нә хезмәтеңез бар”, - диде. Без әйтдек, “Ваше превосходительво, - ди сөйләдек, - безләр Мәдинәдән киләмез, Истанбулга барачакмыз, андан Россияга кайтамыз, безнең юл хәреҗемез[3] бетде. Мөмкин булса, без сезләрнең балаңыз булсак, сезләр безләрнең хөкем атамыз дип үтенәмез, безләргә Истанбулга кадәр буш пароходка билет бирсәңез икән, үтенечемез шул”, - дидек. “Кая паспортыңыз?” - дип сорады. Безләр дә паспортымызны бирдек, карады да: “Сезләрнең паспортларыңыз вәгъдәсе үткән, ни өчен вәгъдәсе тулгач, консулдан паспорт алмадыңыз?” - диде. Без әйтдек: “Мәдинәдә консул юк, башка йирдән алуны белмәдек”, - дидек. “Инде сезләрне мин тугры этап белән Русияга озатамын”, - диде. Моңа инде хафага калдык. Кулымызда акчамыз була торып, монда килергә ник кирәк иде. Үземез культурный яурупалылар кебек яхшы костюм-галстук, башда кызыл

---

[1] Тәбәгасыны – халкын.
[2] Хинзирдан – дуңгыздан.
[3] Хәреҗемез – чыгымыбыз.

фәс, мыек калын, сачләр йитү иде. Без консулдан үтендек: “Ваше превосходительство, сез үзеңез беләсезләр, без Мәдинәдә өч [ел] кадәр укып, Истанбулга барып, диплом аламыз кирәк, әгәр дә сезләр безләрне тугры Русиягә озата торган булсаңыз, безләрнең ничә ел укып йөрүемез юкга чыгачак. Әлбәттә, сезләр олуг кешесеңез, олугларның гадәте мондай эшләрне гафу итмидер. Әлбәттә, сезләр безләрнең бу әхвәлемезне-үтенечемезне йиргә салмассыз дия чын күңелемез илә сорыймыз, - дидем. - Безнең үтенечемезне кабул итәрсез дип ышанамыз”, - дидем. Паспортлар өстәле өстендә яталар иде. Инде дүрт күз белән карап торамыз паспортка бер нәрсә язмаса ярар иде, дия. Хәйрәт[1], бер нәрсә дә язмады. Соңра баш кятибенә бер нәрсә язарга кушды да, кабинетына кереп китде. Кятиб язды да, алып кереп, консулны кул куйдырып чыкды да, конвертка салып печатьләп, кулымызга бирде һәм паспортларымызны да бирде, алып барып өске общество пароходның канторына бирерсез диде. Рәхмәт укып чыгып китдек. Инде уйлыймыз: бу кәгазьгә нәрсә язды икән, бәлки безләрне этап юлы белән алып китеңез дип язгандыр. Әгәр дә болай булса, үземезне үземез барып тапшырган буламыз. Ни булса да конвертны ачып, бер белгән кешедән укытырга кирәк, болай тугры конторга илтеп бирмик дия. Кеше табып укытдык, дөрест, безнең үтенечемез буенча Истанбулга билет язган икән. Конвертны яңадан бозмасданябешдереп, илтеп тапшырдык. Бу да хинзирдән бер кыл булды. Мондан Истанбулга өченче кассада билет кырык сум тора иде. Димәк, безләр буш китдек. Бу пароходымыз сәүдә пароходы булу сәбәпле, озак йөри торган булды. Һәрбер пристаньгә туктап, юлда ала, я бушата иде. Диңгездә Родос утравына һәм Сакыз[2] утравына туктап, берничә көндән Төркиянең Измир шәһәренә йитдек. Моңа бер зур Германия пароходы туктап тора иде. Без сорадык бу кая бара дип, әйтделәр Истанбулга бара дия, нә вакыт Истанбулга йитә икән дигәч, иртән, көн чыгуга йитәдер, дияләр. Соңра мөмкинме Истанбулга билет алырга, дидек. Мөмкин, диделәр. Өченче класска бер сум алтмыш тора диделәр, я безнең пароход мондан Салоник шәһәренә барып, андан кайдадыр йөреп, өч көндән соң Истанбулга барачак иде. Шундан соң Салоникка баручы кем бар дия игълан кылып, үземезнең Бәйрутдан алган билетларымызны 10 сумга сатдык да, бу пароходка 1 сум 60 тиендән билет алып, Германия пароходына ултырып, иртәләп Истанбулга килеп йитдек. Истанбулда бер өч ай кадәр торырга тугры килде. Монда Баязид мәйданындан хәрбия нәзарына каршы фатир алып кердек. Бер-ике кадәр солтан Фатих мәхәлләсенә йөреп, Гыйсмәт әфәнде дигән хисап мөгаллимендән айга бер алтын түләп, хисап укыдым. Монда үземнең бала

[1] Хәйрәт – ни гаҗәп.
[2] Сакыз – Хиос утравы.

вакытында бергә укыган Габдулла Сатиев, юкарыда язылып үткән иде, дарелфөнүннең табигыять шөгъбәсендә укый иде. Минем белән Мәдинәдә бер ел торып, соңра Истанбулга килгән иде. Моның белән һәрвакыт бергә йөреп, Истанбулның һәр йирләрне күрдек.

***Истанбул шәһәрендә сәяхәт*.**

Бер көн моторный пароход белән, җомга көн иде, Бейкоз дигән урынга бардык. Бу көн ял көне булү сәбәпле, бөтен шәһәрнең кешеләре монда йөреп тамаша кылып кайтырлар иде. Шәһәрдән 2 километр Босфор буенда халык күп, яхшы тугайлык, тигез җир, сирәк кенә бик карт тупыл агачлары үсеп утыра иде. Һәркем үз милләтләре белән уйнап-көлеп йөрерләр иде. Монда – берничә километр булыр урман эче белән – Истанбулда мәшһүр Караколак чишмәсе бар икән. Шул чишмәнең чыкган урынына бардык. Бер мәрмәр ташындан улак ясап куйган, ултырып икмәк белән зәйтүн җимеше ашап, суны эчеп кайтдык. Бу су микробсыз су булып, мондан пароход белән Истанбулга китереп, Караколак суы дип, урамларда кычкырып сатып йөриләр. Андан Шөгаеб түбәсе дигән урында, тау башында икән, моны барып күрдек, әйтүләренә бинаән, бу урында Шөгаеб пәйгамбәрнең зияраты бар имеш. Андан Әбелхәят чишмәсе бар икән, анда барып, суын эчеп, кич белән шәһәргә кайтдык. Икенче җомга көн Әюп әл-Әнсари мәсҗеденә барып җомга укып, Әюп әл-Әнсари хәзрәтләренә, янә Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә торган мөдәррисләрнең хуҗасы Бәшир агага зиярәт кылдым. Хода кабул итсен. Монда Галат күпере яныннан моторга ултырып бардык. Өченче җомгада Хәйдәр паша дигән стансага барып, Искәндәр тарафындан андан поезд белән Мальта дигән стансага төшеп, янә мотор белән Мәрмәр диңгезенең утравында Бөек Ата дигән йиргә бардык. Утрау бер тау икән. Монда шәһәрнең бөек адәмләренең дачасы икән. Күзгә бер манзарадыр. Бөтен тауның әтрафы күл сачкәләре белән зиннәтләнгән. Җәй көненең матур-матур өйләре бар, нәкъ тауның башында зур ресторан бар икән, керергә дип барсак, полиция тора икән, монда госманлыларга гына керергә мөмкин диде. “Әфәндем, безләр Мәскәүле”, - дип, паспортларымызны күрсәтеп кереп, ашап чыкдык. Кичкә кадәр йөреп, Истанбулга кайтдык. Икенче вакытда буш чагымызда Истанбул эчендә төрле урынларны күреп йөредек. Солтан Фатих, Солтан Сөләйман җамигъларына һәм солтан Әхмәд җамигына барып, монда музаханә кереп күрдек. Болар исемендән [аңлашылганча], солтанның бәгъзе бер Яурупа канунларыны кабул итүенә карышып, хөкүмәткә каршы чыкган кешеләр икән. Сиксәнләп кеше барысы да борынгы үзләренең киемләрендә аякүрә басып торалар. Терек кеше кебек – катилләре, җәлладләре, башка бөек адәмләредер. Бонларга хөкүмәт тиешле җәзаларын биргәндер. Тик боларның музаханәдә сурәтләре генә торадыр. Җамигъ янында Алмания падишаһы

Вильгелм Истанбулга килгән вакытында бер чишмә ясатып киткән икән, шул сәбәпле Алмания чишмәсе дип йөртеләдер. Янә бу мәйданда Великий таш исемендә биек таш баганалар, дүртпочмаклы, һәр тарафына төрле борынгы хәрефләр белән язулары бар. Бер багананы Мисырдан китергәнләр икән... Кечек Мостафа паша мәхәлләсенә барып, югарыда язылмыш Габдулла әфәнденең йортына барып, һәмширә Сәгыйдә ханымны күреп, танышып сөйләшепултырдык. Бу бичара Эстәрлебашында булган заманларны онытып бетмешдер. Мин авылда вакытымда күршемездә үскән кыз иде. Гобәйдулла Шәрипов дигән кешенең кызы иде. Мәгаттәәссеф, Габдулла әфәндене күрә алмадык. Ул исә вакытча авылларга киткән иде. Мондан соң бер көн Әйа Суфия музаханәсенә барып, борынгы заманның күп асаре гатикаларын күрдек: фиргавенләр заманындан калмыш асарлар, чуен вә башкалар күп иде. Вакытлар Россиягә китүгә якынлап киләдер. Бераз мондан кирәкле китаплар алуга кирәк. Китап дигәндән, азлап-азлап китаплар ала башладым. Дини вә фәнни хәдис, тәфсир, җәгърафия, тарихи китаплардан һәр кайусыны алдым. “Фәтхел-Кадыйр”, “Бохари шәриф”, байтак китаплар алдым, күбесене матбагадан чыкмыш хәлендә кебек, ягъни төпләнмәгән иде, почтага салырга арзан була дип һәм таможня хакы булмый дип, кәгазь рәвешендә салдым, җәмгысе 12 кадакдан 13 посылка булды. Һәрбер посылкага өчәр бланка француз телендә яздырып, Австрия почтаханәсенә тапшырдым. Һәр посылкага 65 тиен түләдем. Вена, Париж аркылы Русиядә олуг тимер юлы Самара, Златоуст, Себер юлында Аксен станса, Никифарда киявемез улган Сәмигулла Габдуллин исемендә салдым. Барын да кайткач сәламәт алдым. Мондан соң өстәмә киемләр, ата вә анама азрак бүләкләр алдым. Омак дигән, Париж фабрикаларында эшләнгән кесә сәгате алдым, 12 сумга яхшы заграничный күн чемодан, яхшы җон одеал, костюм, аяк киемләре, атамызга бер җөббә,[1] үземә яхшы чалма, фәс, бер-ике мәрҗан, ахак кеби бүләк нәрсәләр алдым.

***Истанбулдан Севастопольгә сәфәр*.**

Бу – 1908 елларда август айларында иде. Мәдинәдән бергә чыкган ибдәшләремез бергә иде. Инде Истанбулдан Севастопольгә барырга кирәк. Без тагын да Бәйрутда консулдан буш билет алган кебек, монда да консулдан буш билет алырга кирәк иде. Истанбулда сукыр Хафиз дигән бер татар маклерны күреп сөйләшдек: “Безләргә Русия консулдан өч билет алып бир һәм Төркиянең таможнясындан безләрне үткәреп озатып йибәр”, - дидек. Ул әйтде: “Өчеңезгә бер алтындан өч алтын бирерсез (алтын 10 сум)”. Ярый, дидек. Чөнки бу Хафиз Русия консуллары белән таныш икән. Бу Хафиз ага

---

[1] Җөббә – җилән.

вәгъдәсендә торып, безләргә буш билет алып китерде дә: “Иртәләп пароходка төшәрмез, мин дә барып, таможнядан үткәреп йибәрермен”, - диде. Иртәләп төшеп, таможнядан үтеп, пароходка ултырдык. Безнең урынымыздан ук шәһәрдән газета керде: “Бу көн солтан Габделхәмид әһалигә хөррият игълан кылды” дия. Мәгаттәәссеф, безләргә кире пароходтан кайтырга булмады. Хуш Истанбул, яшәсен Төркиянең хөррияте! дип, видагълашып юнәлдек. Иртәсе көн Севастопольгә килеп йитдек. Пароходда бар анча Кырым татарлары белән танышып идек. Бергә пароходтан чыгып, таможня сараена кердек дә, чемоданларымызны тәфтиш кылып үтделәр. Шундан соң таможня начальнигы чыгып, сезләрнең паспортларыңызның вәгъдәсе үткән дип, өч ярымга бер йөз биш сум штраф түлисез, диде. Алайса, актга кул куеңыз, диде. Кул куйдык, безләрне чыгарып йибәрде. Шундан таныш Кырым татарлары белән бергә чыгып, безләрне бер яхшы гына номерага алып барыңыз дия үтендек, ярый дия бер номерга китереп куйдылар. Рәхмәт, дип, аерылышдык. Бер сәгать дә үтмәде, мәгълүм татарымыз извозчик белән килгән дә: “Безнең дә монда бер җәмгыятемез бар икән, сез шәкердләрне мәҗлескә алып килергә үтенделәр һәм мәүлүд шәриф укыячаксыз” - диде. Ибдәшләремез илән мәслихәт кылышып, барырга булдык. Китдек, бу мәҗлес йортка барып кердек. Бер-ике йөз кадәр кырымлы татарлар җыелмышдыр. Безләрне хуш сафа килдеңез дия каршылап алдылар, исәнләшеп беткәндән соң: “Шәкердләр, бер мәүлид шәриф укуыңызны үтенәмез”, - диделәр. Безләр дә, бик әгъла дип, укый башладык. Мәүлид тәмам булгандан соң, аш, пылау биреп, безләрне кунак итделәр. Безләр сорадык: “Бу мәҗлесеңез ниндәй мәҗлес?” - дип. Диделәр: “Менә безләр, Севастопольдә торгучы татарлар, бу урынны мәсҗед салырга сатып алдык, шуның бер киңәше янә җыелмыш идек, насыйп булса, якында гыймарәтенә башлаячакмыз”. Сез шәкердләр, бу мәҗлесемезгә килеп, безләрне мәмнүн кылдыңыз, безләр дә, мәсҗедеңезне тәмам кылып, эченә кереп, Хода гыйбадәтеңезне насыйп итсен дип, сәламәтләшеп кайтып китдек. Без ике көндән Мәскәү аркылы Самарга билет алдык, ибдәшләремез Уразаевка аркылы Казанга билет алдылар, Мәскәүгә сәфәр итдек. Харьков, Орел, Тула шәһәре аша Мәскәүгә йитеп, Харьковский вокзалга төшеп, андан извозчик белән багажларымызны алып, Казанский вокзалга барып, багажларымызны камерахранениягә тапшырып, үземез шәһәргә китдек. Липецкая площадька туктап, Ново-Варварское подворьега төшдек, суткасына дүрт сум илле тиен түләдек. Өченче катында иде. Монда бер казанлы, Мөхәммәдҗанов дигән кеше, шул номерларга килгән мосафирларга мөселманча ашлар пешереп, һәр номерларга заказ буенча аш тарата икән, чөнки Мәскәүдә мөселман суйган итләрне табу шикледер. Бу Мөхәммәдҗан ага, Аллаһның рәхмәтендә булсын, берничә көнләр безләрне

үз ашлары белән кунак итеп һәм дә Мәскәүнең төрле урынларны – Кремль вә бакчаларын, мәсҗедләрен үзе күрсәтеп йөрде. Фәкать номера хакын алды. Башка ашларына, хак бирсәк дә, алмады. Безләрне үзе килеп, Казанский вокзалга утыртып йибәрде. Аллаһ гөнаһысыны гафу итсен. Шундан соң юлдашымыз Мөхәммәдхәлил Солтанбәков, Мирсәид Мозаффаровлар белән Уразаевкадан аерылышып китдек. Сәламәт Самарга килеп төшеп, бер-ике көн торып, Аксен стансасына билет алып килеп төшдем. Мондан унике километр Никифар авылына төшеп, туган киявемез Сәмигулла Габдуллин йортына килдем. Килеп керүем белән мәрхүм атамыз һәм анамыз кунакга килмешләр икән. Әлхәмдүлиллаһ, мөхтәрәм атамызны һәм анамызны күреп, шад булып калдым. Атамызның әйтүенә бинаән, авылымызның хәзрәте Габдулла Мөхәммәдхарис углы Тукаев һәм борадәре Мөхәммәдшакир Мөхәммәдхарис углы Тукаевлар Уфага иртәсе көн барачаклар дип әйтделәр. Шундан уйладым, минем дә Уфада губернский управлениегә керәчәк эшем бар иде. Боларга очрап бергә барсам, бәлки минем эшем тугрысында берәр ярдәм кылырлар дип уйлап, Уфага барырга уйладым һәм Аксен стансасына барып, Уфага билет алдым. Шафран стансасына килеп йитсәм, мәзкүр хәзрәтләремезгә юлыгып күрешеп, бергә Уфага китдек. Уфага барып Сибирский гостиницага номерга төшдек. Мин дә әхвәлемне бәян кылдым: “Минем губернатор идарәсенә шундай эшем бар иде, ничек күреп сөйләшәмез”, дия. “Алайса, безнең танышымыз Әхмәдсолтан Терегулов анда хезмәт итә, мин күреп сөйләшермен”, - диделәр. Соңындан кайтып, миңа җавап бирделәр. Иртән губернатор белән күреп сөйләшермез дә, хәбәр итәрмен дип вәгъдә кылды. Икенче көн Терегулов номерымызга килде: “Менә, андагы вулыс паспортыңызны алып килдем. Бу заграничный паспортыңызны миңа бирәсез”, - диде. Паспортымны тапшырып, соңра әйтде: “Сезнең эшеңез хакында губернатор бойлә җавап бирде. Мәсәлән, таможняда паспорт өчен бер йөз биш сум штраф салдылар. Шуны губернатордан гафу итдерелде. Губернатор бу эш хакында, мин үзем гафу итә алмыйм, фәкать министерство гына гафу итәдер дип, урындагы начальниклар, дөрест, бу кеше фәкыйрь, түләрлек хәле юк дип кәгазь бирсә, шул вакытда мин бу кәгазьне министрга бирермен дип әйтде”, - ди. Ярар, бу эшемез хакында бер юл табып, янә шул Тукаевлар белән бергә Шафранга кайтдык. Анда тройка повозка арбалары көтеп тора икән. Болар белән бергә утырып, Эстәрлебашка сәфәр итдек. Кич ястү намазы вакытында сәламәт кайтып йитдек. Әлхәмдүлиллаһ, йортымызга кайтып, ата-ана белән күрешеп, Ходага шөкер әйтеп йокладым. Берәр атнадан соң урядник килеп, миңа извещение бирде: “Менә бездән Севастопольский таможня бер йөз биш [сум ] акча сорап йибәргән”, - диде. Тугры, дип кул куеп, извещение алып калдым.

Янә бер айдан становой пристав килеп, мине чакыртды да, менә сезләр границага барган икәнсез, таможня сезгә 105 сум штраф салган, шуны бирәсезме, диде. “Дөрест микән, мин яңа гына кайтдым, торырга йортым юк, хәзер һичбер нәрсә бирергә кулымдан килми, әгәр дә күчеп, берәр вакыт йитсә, түләрмен”, - дидем. Уйлап торды да: “Алайса, фәкыйрьлек өчен алты картны алып кил дә, алар бу кеше ул сумманы түләрлек [түгел] дип кул куйсалар, кәгазьне губернаторга кайтарырмын”, - диде. Шулай итеп, алты карт кул куеп бирделәр дә: “Миңа кирәк булсаң, икенче вакытда чакыртырмын”, - дип, чыгарып йибәрде. Вәссәлам, шуның белән бу мәсьәлә [хәл ителде].

***Эстәрлебашка кайтып тора башлавым, җәмәгать алуым.***

Мәскәүдән 1908 нче елда, рамазан ае, сентябрьнең 14ләрендә булса кирәк, “сәламәт Кәлямулланы хифыз кылып кайтсам, тәравих намазында өемездә ата-анамызны артыма куеп, Кәлямулланы хәтем кылып бирсәм икән” дигән вәгъдәм бар иде. Шул вәгъдәмне үтәү нияте белә 1 нче рамазандан башлап 15 нче рамазанга кадәрле укып тәмам кылдым. Өемезгә сыйган кадәрле күрше, ага-энеләр, һәркайусы килеп, намазда иштиракь итделәр[1]. Хода ризалыгы өчен булып, Хода ниятемезне кабул итсен, амин. Хәтем кичәсендә мәхәлләмезнең имамлары вә һәм карыйлары хәтем мәҗлесендә катышып, хәтем догаларыны кылып, тәмам кылдык. Инде кышлыкда мәдрәсәгә кереп, шәкердләр арасында үткәрергә кирәк булды. Безгә укыган мәдрәсәмезнең бер бүлмәсене рөхсәт итделәр. Шундан мәдрәсәгә кереп, шәкердләр белән бәгъзе дәресләрне үгрәтеп, башкача мәгариф юлында төрле мәгълүматлар биреп, һәртөрле гәзитә вә мәҗәлләләр[2] алдырып, шәкердләргә истикъбальнең барысына карап укуга тырышыңыз, дия төрле фикерләр сөйләп, кулымдан килгән [хәтле] иҗтиһад итдем. Мәхәлләле мәдрәсә мөдирләренә бу эшләрем охшамас булды. Җәдид дәһри булып кайткан икән, шәкердләргә сәяси фикерләр сала, Төркиядән гәзитәләр алдыра дип, бер бәһанәләр[3] кылып, урыска донос һәм йибәрделәр. Ләкин бер зарар кыла алмадылар. Шулай итеп, кыш үткәреп, язга якынлашып калганда ата-аналарымыз безләрне өйләндерергә уйлый башласалар кирәк. Тизрәк моның башыны бәйләмәсәк, китеп калыр дип уйлап, Эстәрлебашында мәшһүр хәлфәләрдән Әстерхан губернасында Бүкәй хан илендә Чәркәс ыругы Нарын кыйсеме Гали хәлфә Айдабуловның кәримәсе Фатыймага вәгъдә кылышканлар. Бу Гали хәлфә казакъ таифәсендән булып, йикерме

---

[1] Иштиракь итделәр – катнаштылар.
[2] Мәҗәлләләр – журналлар.
[3] Бәһанәләр – ялган сәбәпләр.

яшьләрендә Эстәрлебашына укуга килеп, шунда хәтме көтеб кылып[1], соңра олуг мөдәррисләрдән булып киткән Хәлилулла хәлфәнең Рабига исемле кызны толлата никахланып, шуңардан рафикамыз Фатыйма тугмышдыр. Анамызның атасы Вәлиулла Хәлилулла берлән бертугмадыр, димәк рафикамыз Фатыйманың анасы Рабига белән минем анамның атасы бертугмадыр. Шундан соң 1909 елда апрельнең 29ында Фатыйма белән зөфафымыз булды. Бу зөфафымыздан берәр ай үтеп, мин үземне укуга ярдәм кылып йибәргән Ялпакталда – Гобәйдулла Галикәев хәзрәтләренә – барып күрешүемез тиешле иде. Шундан мин июнь айларында анда бардым. Уразайга, андан Казанга, андан Саратовка, андан поезд белән Александр Гайга барып, мондан ат белән туксан чакрым Ялпакталга барып йитдем. Бу вакытда минем ниятем Макария ярминкәсенә барып әйләнеп кайтмак иде. Хәзрәт белән күрешеп, тиешле әманәтләрне бирдем. Берничә көнләрдән соң китү иде. Рамазан ае якын булу мөнәсәбәте белән хәзрәт миңа әйтде: “Рамазанны монда үткәреп, хәтем кылып китсәңез, яхшы булыр иде”, - диде. Мин әйтдем: “Мин монда сезләргә хәтем итү нияте белән килмәгән идем. Фәкать сезләрне вәли нигъмәтемез булу сәбәпле, зиярәткә килеп идем”, - дидем. Мөмкин булса, бер хәтем әйтүеңезне үтенәм, дип әйткәндән соң, мин дә чындан максудың булса, яхшы сүзеңезне йиргә салуга вә Ходага кабул итеп хәтем кылырга карар бирдем дә, дидем: “Ул вакытда бу көндән башлап миңа тәкрар кылырга керешергә кирәк”, дия тәкрарга тотындым. Рузагә берничә генә калганда мин үземә хаҗ кылырга кушып, юл хәраҗларымызны биреп йибәргән казакъларның авылына барып, тиешле шәһадәтнамәне хаҗ кылуым өчен янә азрак зәмзәм, хөрмә, тәсбих кебек бүләкләрне тапшырырга китдем. Берничә көндән соң әйләнеп кайтдым. Кайтсам, хәзрәт бер мәсьәлә куйды: “Синнән соң безгә Уральский шәһәренә якын Урал суы буендагы шәһәрдән Мөхәммәдҗан Манжуков дигән бер сәүдәгәр адәм килде. Ул димеш: “Безнең Илбишин каласына бер адәм кирәк иде, имамлык да кылсын һәм, мәктәпләргә кереп, мөселман балаларын заманча муафикърак укытырлык да булсын”, димеш. Хәзрәт әйткән: “Миндә бер адәм бар, хәзердә өйдә юк, кайткач сөйләшеп, җавап телеграммын бирермен, дигән. - Ни мәслихәт күрәсең, барасыңмы, юкмы, безгә җавап бирергә кирәк”, - диде. Мин әйтдем: “Хәзрәт, минем мулла булуга фикерем юкдыр, булдыра алмыйм”, дия җавап бирдем. Хәзрәт дә бу кеше кабул кылмады дия җавап бирде. Янә каршы телеграмм килде: 1 нче рамазанга безгә хәтемгә килсен, дия. Килү мәсарифе[2] үземдән димеш. Шундан хәзрәт әйтә: “Сезләр үзеңез беләсез”. “Сезләр ничек мәслихәт кыласыз”, - дидем. Хәзрәт әйтде:

---

[1] Хәтме көтеб кылып – укуны тәмамлап.

[2] Мәсарифе – чыгымы.

“Минемчә, баруын мәслихәт, бердән, шәһәрне һәм кешеләрен күреп сөйләшерсең. Мәслихәт урын булса, мулла булып да калырсың”, - диде. Янә анда барып, 11-12 көндә хәтем әйтерсең дә, 15 нче рамазанга монда кайтып килерсең. Андан соң бездә хәтем кылырсың. Бердән, тәкрар әйтүгә дә яхшы булыр. Икенчедән, монда ярминкә вакыты болай бик килем-китем күп була, синең тәкрар әйтүең тәшвиш булыр дип уйлыйм”, - диде. “Яхшы, алайса, бер барып кайтыйм” дип, ул вакытда бу көндән юлга чыгуым кирәк иде. Шундук ике ат яллап, 150 километр йиргә 11 сум түләп сәфәр итдем. Бу 1909 нчы ел сентябрьнең икенче көнендә рузә башлады. Юлда бер рус байларының хуторына кереп кундык. Шул кичдә сәхәр ашадык. Хутор хуҗасы бай муллаларга сәхәр ашарга ит пешереңез дип, казан хидмәтчеләренә әйтеп чыкды. Иртәләп торып рузә булып, атка утырып, берәүгә ифтарга барырга дип чыгып килә икән. Безләр каршы булдык. Безләр ки тиз-тиз генә юындык да, безләрне дә ифтарга алып китде. Шунда булган кешеләргә әйтде: “Бу көн насыйп булса, хәтем башлыймыз. Бу кеше кунак карый буладыр”, - диде. Ифтардан кайтдык да, мин бер юынып, өст-баш алышырга тугры килде, чөнки юлда бик тузан көчле булу сәбәпле, бөтен өст-башымыз тузан булып калды. Безгә су һәм кирәкле күлмәк-ыштанларымызны китереп, мунчасына илтде дә: “Сез юынганчы мин барып, мәсҗедкә халыкларга игълан кылып кайтыйм”, чөнки күп халыкның бондан хәбәрләре юк иде. Ул да кайтды, мин хәзерләнеп мәсҗедкә китдем. Ходага тапшырып, һәр көн өч парә укып, ун көндә хәтемне тәмамларга булды. Хәтемемез тәмам булгандан соң, Мөхәммәдшәриф Манжуков мине тройка ат җигеп, үзе Ялпакталга китде. Монда 15 нче рамазанда хәтем башлап, кадер кичәсе көнендә тәмам кылырга дип, Ходага тапшырып, башлап, шул рәвешдә хәтемезне тәмам кылдык. Хәзрәт дә: “Рәхмәт, балам, гомереңезне бушка үткәрмәгәнсез икән”, хәтемдән соң бер яхшы ефәк чапан кидерде. Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин. Инде авылга калды. Хәзрәт әйтде: “Мөмкин булса, бу кыш безгә мөгаллим булып килеңез, шәкердләр дә яхшы гына җыелыр,  углымны, Габделгазиз исемле, сездән Коръәнхафиз кылдырырга идем, - дия. - Кайтып, яңадан килерсез”, - диде. “Ярый, авылга кайтып, мәслихәт кылышырмыз. Андан җавап бирермен”, дим. Китдем, сәламәт кайтып киңәш кылдыкым соңра, баруга уйладым да, җавап бирдем. Эстәрлебашында Гобәйдулла ишан Тукаев мәдрәсә мөдире булу сыфаты белән миңа шәкерд укытырга юл бирмәде. Бондай надан ахмакларга, файдасыз мәдрәсәгә шәкердләр җыеп, хәлфәләр исемендән файдаланып, мөридләрдән каз-күркә җыеп, кәефләнеп ятучыларга исем китмәде һәм бер җөмлә хәдискә яхшы мәгънә бирә алмый торган җаһилләргә дәрескә ултырмадым, шуңа да кәеф китде булса кирәк. Шундан янәдән Ялпакталга китдем дә, барып, мәдрәсәдә мөгаллимлек кыла

башладым. Һәм хәзрәтнең мәхзүмене дә хифыз кылдыра башладым. Байтак кына казакъ шәкердләре дә бар иде. Кышны монда ялгызым үткәреп, язында Эстәрлебашына кайтып китдем. Бу сәнә хат язып, Дим буе Никифар авылында хәтем итәргә дип, киявемез Сәмигулла Габдуллин чакырды. Әүвәл монда, андан Ялпакталга барырмын дип, ниятләп чыкдым. Никифарда хәтем вакытында сәламәтлегем китеп калды. Ходаның ярдәме белән хәтememне тәмамладым да, сезгә бара алмыймын дип хәзрәткә телеграмм йибәреп, Эстәрлебашына кайтып китдем. Янә анда хәзрәтдән хат алдым: “Хәтемгә килмәдеңез инде, бу кышда мөгаллим булып килеңез”, дия. Янә кышында анда барып мөгаллимлек итдем һәм мәхзүмне дә, хифызны тәмамлатып, язында кайтып китдем. Миндән соң бу мәхзүм борадәрләре Каргалыда мәшһүр Габдулла  Галикәев хәзрәтләренә барып, анда яхшы тәкрар кылып, хафизе кәлямулла булып чыкды. Бу 1911 нче елда иде. 1912 дә Эстәрлебашка кайтып, мәдрәсәгә  кермәй, йортымызда тордым. 1910 нчы елда җәмәгатемез Фатыйманы 30 нчы майда йортымызга күчереп алдым. Бабамыз  мәрхүм бик күп бүләкләр белән озатды. Хаҗәте асылиямезне тәмамы белә тигезләп озатды. Аллаһның рәхмәтендә булсын. 1914 нче елда Германия мөхарәбәсе башланып, сугыш 17 нче елга кадәр дәвам итде. Миңа да 16 нчы елда сугышка алынырга дип, ягъни безнең туган елларга, 1881 нче елгыларга, хәбәр булды. Ничек дә бер чарасына керергә кирәк иде. Мин Оренбург шәһәренә – армиягә тун тегә торган Оренбурглык сәүдәгәрләрендән Мөхәммәд хаҗи Әюпов дигән кешенең заводына, гаскәри эшкә кердем. 1916 нчы елның август аенда Оренбургда Борисов тегермәне дигән заводка тире эшенә кердем. Монда тун өчен эшләнгән тиреләрне бушатып бирер идек, һәр тире эшенә 10 тиен түләделәр. Һәр өч айга срок бирделәр (отсрочка), бишләп кеше эшләр идек. 1917 нче елда Русиянең олуг инкыйлабы башланып, заводда эшли торган кешеләр китә башладылар, чөнки вулыс байлар кулындан чыгып, эшчеләр кулына күчде. Бу елда авылда йортымызда ут чыгып, өйдән башка каралтылар, утын-печән кебек нәрсәләремез янып, ялгыз өемез калып, мал-туарларымыз кар өстендә калмышлар дип, атамыздан хат килде.

***Инкыйлабдан Оренбургдан авылга кайтуым..***

Ничек дә булса авылга кайтып, йортымызның хәлен белергә кирәк. Завод хуҗасы Әюповның алдына барып: “Миңа отпуска бирсәңез, кайтып килер идем”, дидем. Ул әйтде: “Хәзер хуҗалык бездә юк, эшчеләр кулында, аларның мәҗлесләрендән сора”, - ди. Мин эшчеләр җыелышыны көтеп, җыелыш көнне мәҗлесдән сорадым, безгә отпуск бирсәңез, кайтып килер идем дия. Болар да, бертавышдан, бер айга рөхсәт бирделәр. Мартның 15 нче көнләрендә поезд белән өйгә китдем. Никифар авылында туган кардәшемнең

йортына төшеп, Никифар киявемез Сәмигулла Габдуллин үлем өстендә ята иде. Азрак сөйләшә иде. Ни хәбәрләр дөньяда, дип сорады. Мин әйтдем: “Николай патшаны урындан төшереп, урынына Керенский дигән кеше ултырды”, - дидем. Падишаның төшүенә куанып булса кирәк, көлде. Берәр көн торып, Эстәрлебашка китәргә кирәк иде, чөнки кар бетеп, юл булмый калу ихтималы бар иде. Эстәрлебашка кайтып, бер-ике көндән соң хәбәр килде “киявемез вафат” дия. Күмү көненә барып йитәргә юл булмады. Бердән, су вә ягмурлар булып китде, шул сәбәпле җеназасына бара алмадым, кайтып, берничә көнләрдән соң, заводта калган ибдәшемез Габдерәүф Билаловдан хат алдым. Яза: “Заводга рабочий солдат-крестьянлар тарафындан комиссия килеп тәфтиш кылды, дип. - Безне һәм сезне армиягә алырга дип язып китделәр, ди. Озак торма, тизрәк килергә тырыш. Бонда эшчеләр таралып бетде. Каравыл белән мин генә хәзергә калып торам, ди. Мөмкин булса, армиягә барырга ярамый, дип, ничек дә бер сәбәп кылып кил, ди. Безләрне болар тиречеләр түгел, болар мөгаллимләр, чөнки документларда учитель дип язылган дип, безләрне утга алырга карар кылып киткәнләр”, дия язды. Мин дә бер чара кылырга тиешле булып, берничә авылның картларны күреп үтендем, әхвәлемне сөйләдем. Миңа “бу кеше тире иләү эшене белә, соңгы вакытларга мөгаллимлек кылды” дип, бер справка биреңез, дидем. Үтенүемә бинаән, картлар да яхшы, дия сельсоветдан тәсдыйклап справка бирделәр. Соңра түгел дип, янә Оренбургка китдем, поезд белән барып йитдем дә, вокзалга камерахранениегә багажларымны биреп, кич сәгать 9лар иде, тугры эшләгән заводка юнәлдем. Капкасына барып җитсәм, каравылчы карт тора иде. Бу таныш кеше Эстәрлетамак [ныкы] иде. “Исәнме, земляк”, дип исәнләшдем дә, ни хәлләр бар, дидем. “Монда кешеләр бар да таралып бетде, завод эшләми”, ди. “Хәзер дә берәү дә юкмыни?” - дидем. Тик ялгыз Батталов кына конторда ята иде. “Мөмкинме?” “Кереңез”, - диде. Исәнләшдем, әхвәл сорашдым, хәзергә һичбер хәбәр юк, шулай язып киткән иделәр дә, бер нәрсә дә юк әле, диде. Шунда йоклап, иртәләп шәһәргә китдем. Шәһәрдә байтак безнең белән эшләгән таныш-белешләр очрап калды. Ни хәбәрләр бар, дип сорашдым. Алар әйтделәр: “Сак бул, шәһәрдә аулама бара, яшьрәк һәркемнең военный документларын тикшерәләр, вирмиләр”. Берәүләре: Керенский хөкүмәте мөгаллимләрне мобилизациядән гафу итә, дигән хәбәрне сөйләделәр. Сорашып белде, дөрест икән. Инде үземнең мөгаллим булуыма справка кирәк булды, йитез генә авылга китдем, кайтып справка алып килдем дә, военный начальникка кердем, документларымны алды да, секретарьга кәгазь язып бирергә кушды, машинада баса башлаган иде. Шул вакытда солдат крестьянский идарәсендән комиссия булып, бер-ике кереп, секретарь янына

ултыртдылар. Үзләре ни өчен килүләрен белдерделәр. Секретарь минем кәгаземне басып ята иде, туктады: "Разве Уфимская губерна чтоли?", - дип сорады да, шулай, дидем. Юк, безләр чит губерна кешесенә кәгазь бирә алмыймыз дия машинадан кәгазьне алып ертып ташлады да, башка документларымны кайтарып бирде. Хуш, чыгып да китдем. Урамда йөрүләр куркыныч иде. Ничек дә булса, тиз генә авылга ычкынырга кирәк. Бәхеткә каршы, авылдашлардан Фазыл Әхмәров дигән кеше килгән икән. "Мине ултыртып алып кайтасыңмы?"- дидем. "Без бүген китәмез, өлгерсәк, әйдә", - диделәр. Шул көндүк Оренбургдан чыгып китеп, сәламәт Эстәрлебашка кайтып йитдем дә, тиздән Эстәрлетамакга барып, военный начальникдан, мөгаллим булуым сәбәпле, военный штабның шундай приказына бинаән, "бу кеше гаскәрлек хезмәтендән котылмышдыр" дия кулыма кәгазь биреп чыгарды. Унйиденче ел, август айларында булса кирәк, шул ук елда Эстәрлетамак мәгариф бүлегендән Хәлекәй авылы мәктәбенә мөгаллим булып билгеләндем. Екерменче елга кадәрле Хәлекәй авылында укытып, Эстәрлебаш мәктәбенә күчдем. 22 нче елга кадәр Эстәрлебашында укытып, үземнең гаризам сәбәпле, мөгаллимлекдән азат ителдем. Бу елларда каты ачлыклар: адәмләр балаларны-хатынларны суеп ашадылар, хәтта үлгән кешеләрнең үлекләрен ашаучылар да күп булды. Адәмләр ачлыкдан бик күп үлеп, хәтта кабер казырга кеше булмай калды. Үзем күзем белән күрдем һәм кулымдан килгән кадәрле шул бичараларның җеназасына катышып, җыелган алтмыш кадәр үлекне өч чанага төяп, аркан белән бәйләп, зиратка алып бардык, чөнки алып барырга кеше табылмый калды. Хода ризалыгы нияте белән дуст-ишләргә әйтеп, иганә җыеп, бер зур ям казытып куйдык, өстен салам белән ябып, бер урыннан гына ачык калдырып куйдык. Шул базга югарыда язылган үлекләрне – бер якга ирләр, бер ягында хатынларны куеп, дәфен кылдык[1]. Ходаның язмышына разый булып, сабырлык кылып, әманәт җанларны тапшырмышлардыр. Аллаһ барчасын мәгъфирәт кылсын, амин. Бу зиярат Эстәрлебашның олуг мәкъбәрәсендә көнчыгыш тарафында тау ягында таш стена буендадыр. Янә дә икенче бер олуг баз казытып, анда да бер йөзләп адәм куелса кирәк. Бу олуг мәкъбәрәнең урталыгында су юлы булган чокыр буендадыр.

Бу елда кызым Асия дөньяга килде. Илле кадәр кеше чакырып, исем туены кылдым. Ходаның биргәненә шөкер, өч балам, ике кардәшем тәрбиямдә иде. Ачлык, агырлыкны күрмәдек. Азрак булса да икмәкдән өзелмәдек. Алданрак елның авыр булачагын уйлап, бераз саклык игенемез бар иде. Хөкүмәт дә, укытучы булуым сәбәпле, азрак ярдәм кылды. Янә

[1] Дәфен кылдык – җирләдек.

Америка җәмгыяте тарафыннан гомуми Россиянең ачлыкда калуын хисапка алып, балаларга, мохтаҗ карт вә карчыкларга да ашханә ачып, зур гына адәмләрнең сәламәт калуына ярдәм итде. Бу ашханә АРА исемендә иде. Олуг кешеләргә аена бер потдан кукуруз бирде. Балаларны ашханәгә җыеп, көненә ике мәртәбә аш бирделәр. Биргән ашлары ак күмәч, шикәр, какао, сөт, эссе аш иде һәм азлап өст-аяк киемләре дә бирделәр. Шул ач балаларның ризыгына золым кылып, ашханә мөдирләре күп ризыкларын сатып файдаландылар. Бу ниндәй вөҗдансызлык, укучылар, үзеңез уйлап күреңез. Балалар сәламәт калды. Аларның ризыкларын ашаучылар күбдән йир куенына керделәр. Ходага нә җавап бирерләр. Бу ачлык егерменче елның көзендән башланды. Бу егерменче елда тиф авыруы, андан ваба авыруы башланып, Эстәрлебашда көненә егерме адәм үлгән көнләре булды. Егерме икенче елның язына кадәр дәвам итде. Шул дәрәҗәдә куркынычлы булды ки, авылда ат, песи, карга, чәүкә кебек кошлар калмады. Хәтта адәмләр агач кайрысыны он кылып һәм сөякләрне он кылып ашадылар. Тегермәнгә барсаң, күрәсен: тартырга барган кайры, сөяк булыр иде. Башка орлыкның исеме дә булмады. Хәтта бәгъзе адәмләр сыерның бозау соңында төшә торган, чүп диләр, шуны ашадылар. Кешенең сыерлары бозауламасдан борын алдан: “Берүк чүпне ташлый күрмәңез”, дип әйтеп куярлар иде. 1922 нче елның язында ифрат дәрәҗә еллар яхшы булды. Язга чыгу белән халык үлән тамырлары – этлек, диләр, шуның тамырын, кымызлык, кузгалак дигән үләнләрне ашап булса да, сәламәт калдылар. Адәм баласы үләнгә чыкса, ачка үлмәс икән. Яз-җәй көнләре шул дәрәҗәдә фәрәванчылык[1] булды, бәлки мондай язны кеше күрмәгәндер дип уйларлык – һич күренмәгән чәчәкләр күренде. Тау буйларында печәнләр чабдылар, гомердә булмаган – сыерларны авылга кайтарып, көненә өч мәртәбә саудылар, безнең мәхәлләнең көтүне зиярат каршына ындырга ябарлар иде. Хатынлар шунда барып саварлар иде. Үземнең җәмәгатем Фатыйма да, көн дә барып савып, бер чиләк алып кайтыр иде. Җәмәгатем белән сөйләшеп, ничек дә булса, көздә аз гына булса да арыш сачеп калырга кирәк иде дия. Рафикам: “Бик яхшы булыр иде дә бит, орлык кайдан табамыз соң”, - диде. “Тырышсак, табармыз, дидем дә, Ходa насыйп итсә, иртәгә балалар белән йөреп, киң арыш башаклары булыр, табылса, аз-маз җыеп кайтыңыз,” - дидем. Шулай итеп, болар берничә көн йөреп, бер пот арыш тапдылар. Мин тагын бер хәрәкәт кылып, аз-маз табармын дия, берәүдән ярты пот табылды, авылында Күндерәк суында Гобәйдулла хәзрәт Тукаевның тегермәне бар иде. Углы Шәриф Тукаев шунда торыр иде. Барып, аңардан фарыз кылып, бер пот арыш алып кайтдым.

[1] Фәрәванчылык – муллык.

Димәк, ике пот ярым арышны егерме беренче елның көзендә буе сиксән, аркылысы 40 сажин йиргә сачдем. Ходага тапшырып, шул йирдән 22 нче ел җәендә ат тартмый ун йөк арба көлтә китереп бастырып, шул ел җәендә саф бер йөз ун пот арышны келәтемә сугып салдым. Хода бирсә, шулай бирә икән.

1923 елдан башлап игенчелек эшенә керешдем. Инкыйлабка кадәр безләргә авылда җир булмас иде. Унсикезенче елдан башлап, гомуми халык белән бәрабәр җир бирделәр. Җиремез булгач, иген сачәргә кирәк. 4-5 дисәтинә ашлык сачеп, терекчелек кыла башладым. Башка кәсебем булмады. Бәрәңге вә башка яшелчә үстерә башладым. Үземнең диһканчылыгым[1] үземә йитә торган булды. Бер ат, ике сыер, 5-6 сарык, каз, кош, дүрт-биш умарта, шулай итеп бер мең тукыз йөз йикерме сикезгә кадәрле килдем. 26 нчы ел Ак Идел буенда Җиргән авылында яңа мөселманлар мәхәлләсендә, имамлары Фатих Кәримовның чакыруы буенча, рамазанда хәтемгә бардым. Бу мәхәллә әһалисе чуаш милләте булып, 1905 дә рәсми мөселманлык кабул кылып, мәсҗед салып, җәмәгать булып намаз укуларына йикерме ел булу мөнәсәбәте белән бер хәтме Коръән кылдыруны мәслихәт кылганлар икән. Шуңа безне чакырдылар. Янә шул ук рамазанда Пермь шәһәрендә имам Кәраматулла Айдаров да хәтемгә чакырып телеграмм йибәргән иде. Бәгъзе бер сәбәпләргә бинаән, бара алмыйм, дип җавап кайтардым. Янә тукыз йөз егерме йиденче елда Орнбург шәһәрендә имам Габделгалим Дәүләтшин җәнабләре рамазан шәрифдә хәтме Коръәнгә чакырып телеграмм йибәрде. Әүвәлге елда да чакырып иде. Җиргәндә хәтем кылуга сүз бирелү сәбәпле, баралмыйм дигән җавапны биргән идем. Бу ел янә чакырды, бу ел барып, мәшһүр Оренбург шәһәрендә Әхмәдбай Хөсәенов мәсҗедендә хәтем башладым. Самигъ булып торыр өчен Оренбургда мәдрәсәи Хөсәения мөгаллимләрендән Габдеррәхим карыйны тәгаенләп, ундүрт тәравихдә хәтем кылдым. Соңра Оренбургда Кәрвансарай мәсҗедендән мөтәвәллиләре[2] имамы Габделкави хәзрәт, яткан номерыма килеп, инде безнең мәсҗеддә дә хәтем кылыңыз дип, янә икенче хәтемне Кәрвансарайда кылдым, олуг имамы Нигъмәтулла Тимушев иде. Бик галим, фазыл, хуш вәгазьле, халык дини хорафатларга ышанып йөрмәгән хәлдә тәрәкъкыйлек тарафында иде. Аллаһ рәхмәтендә гарык улсын. Амин. Бу мәсҗедләрнең хәзерге көндә дә биналары сәламәт. Хәтем вакытында мәсҗеднең мөәзинендә тәрбияләнеп тордым, рамазан аеның кадер кичәсендә күпчелек белә һәм хатын-кызлар да күп иде, хәтемезне тәмамлап, тиешле догаларны кылып, имамлар тарафындан бәгъзе бер дини нотыклар да сөйләнеп тәмам итдем. Әлхәмдүлилләһи Раббил галәмин.

---

[1] Диһканчылык – игенчелек.

[2] Мөтәвәлли – мәчет, мәдрәсә эшен башкаручы.

Югарыда язылуга тиеш иде, бу урында язарга тугры килде. Инде уникенче елдан 16 нчы елга кадәрле йортда торсам да, эшсез ятмадым, халык эшләренә катышып эшләдем. Беренче уникенче елда авылның аңлы адәмләре белән сөйләшеп, моңа кадәрле сирәк йирләрдә булмыш бер потребитель кибете ачуга уйладык. Бер дүрт кеше бу оешманы барлыкга чыгарыр өчен, Уфаның губернский идарәсенә рөхсәт сорап гариза бирдек. Безләр бу эшнең организаторлары булдык. Соңра рөхсәт җавабы килде. Андан соң халыкны җыеп, мәҗлес ясап сөйләдек: потребитель халыкга файдасы хакында һәм килгән файда шушы оешманың үз кассасына җыела һәм башкаларны; инде мәслихәт күрсәңез, шушы оешмага әгъза булып язылуыңызны сорыймыз һәм дә әгъзалык салымы ниндәй кадәрле булырга, янә шушы әгъзалар эчендән бер өч кеше сайларга, янә бу ширкәтнең исемне ничек куямыз дип аңлашканның соңында ширкәтнең исеме “Нур” булуга карар булды. Әгъзалык салымы илле сум. Бер рәис, бер хисапчы, бер өч кешелек тәфтиш комиссиясе, рәискә ярдәмче сайларга карар булып, тәфтиш комиссиясенә мине сайладылар һәм башкаларны. Шулай итеп, бу эшне барлыкга чыгарып, эшләремез йөреп китде. Халыклар да бик булышып, боны кайдан уйлап табдыңыз дип, монда биргән файдамыз үземезгә була икән дип рәхмәтләр әйтделәр.

15 нче елларда янәдән бу ширкәтне зурайтырга кирәк дип мәслихәт кылышып, яңадан икенче кибет ачуга сорап, Уфага гариза йибәрдек. Башда бу эшкә организатор булып мәхәлләмезнең имамы Габдулла хәзрәт Тукаев, Шәриф Тукаев һәм үзем кул куеп йибәрдек, тиздән рөхсәт җавабы килеп, йөз сум салым белән “Шәфкать” исемендә бер кибет ачдык. Авылымызның сәүдәгәрләрендән Габделкәрим Искәндәревнең таш кибетен иҗарәгә[1] алып, үземне сатучы кылып, ширкәтемезне ачдык. Хөкүмәт төрле крестьянларга кирәкле нәрсә биреп торды. Кибетемездә һәртөрле ашамлык, конфет кебек нәрсәләр булып, арзан бәһа белән сатыла башлады. Частный сәүдәгәрләр төрлечә халыкга агитацияләр таратсалар да, номерлары үтмәде. Эшемез яхшы йөреп китде. Әгъзалар да көндән көн артып, кассамыз да көчәйде, чөнки халык потребительнең файдасыны аңлый башладылар.

21-22 нче елларда авылымыз Эстәрлебаш сельсоветында әгъза булып эшләдем. 22 нче елда Калкаш вулысы идарәсендә Идел буе Менәвезенә контон сайлауга вәкил булып сайландым, барысы тукыз вәкил, янә бу елда Эстәрлебашына бурыч ширкәте ачылды (кредитное товарищество), бу ширкәтдә тәфтиш комиссиясенә әгъза булып сайландым.

***Эстәрлебаш фонталы[2]***

[1] Иҗарәгә – арендага.

[2] Фонтал – фонтан.

1926 нчы елда Эстәрлебаш борынгы су юлын юлга салу фикере килеп төшде. Бу фонтал исә мондан туксан ел элек Эстәрлетамак сәүдәгәрләрендән мәрхүм Габделхаликъ Мәҗидов иганәсе белән эшләнгән. Шушы 17 нче ел олуг инкыйлабка кадәр эшләп килсә дә, төзәтүчеләр булмау сәбәпле, эшләми калды. Бу суның килүе Эстәрлебашның зиярат ягындагы таудан чыгадыр. Шул чишмәне мәсҗед-мәдрәсәләрнең алдында булсын дип, йир астына казып, озын карагай бүрәнәләрнең уртасыннан бораy белән тишеп салып китерткән. Безнең вакытымызда суханә исеме белән йөрер иде. Су көч белән, ягъни напор белән килеп, суханә эченә баганадан 3 аршин юкары мендереп, андан түбәнгә төшәр иде. Артык суы зур урам чыгып, улакдан агып тора иде. Мондан да халыклар файдалана иделәр. Бонысы бәләкәй чишмә дип йөртерләр иде. Тукаевларның һәркайусының йортында, Гаид хәлфә Фәйзуллин йортында да бар иде. Шулай булып, асыл әсасы тәгаен кылынган суханәгә су килү азаеп калды, инкыйлаб вакытында бу су юлыны гыймарәт кылдыра[1] торган Тукаевлар кайсысы вафат, кайулары авылдан китеп калдылар. Шул сәбәпле, халык суга мохтаҗ булып калды.

Инде мин бу хакда авылымызның мәэмүрләре[2] белән сөхбәт кылып, фикерләрен алышдым. Һәм диделәр: "Халык ярдәм бирсә, безләр дә һәртөрле хөкүмәт тарафыннан тиешле ярдәмдән кире тормасмыз", - дип, хөкүмәтдән бурычка ссуда алышып бирү кебек һәм дә технический ярдәмләр кебек хаҗәтләреңезне үтәрмез дип, мәслихәт бирделәр. Бу ел хөкүмәт тарафыннан халыкга үзара салым салыначак. Шул салым акчасыны халык үзләренең гам[3] файдасына тотарга хаклы диделәр. Ярый, бу эшне бәлки эшләргә мөмкин булса икән. Бу хакда бер зуррак җыелышда халыкга аңлатырга карар бирдем. Агроном ибдәш дә, мин дә үз тарафымдан тиешле ярдәм бирүне халыкга русча сөйләп төшендерермен дип, миңа боның сүзе зур ярдәм бирер дип уйлап, Ходага тапшырып, бу эшнең юлга салынуына күңелем ышанды. Апрель ахырларында иде, бөтен авылның халкы урман бүлү өчен урманга җыелырга булды. Урман, йир бүлү мәҗлесендә бер дә адәм калмыйдыр. Шул җыелышка авылымызның умарталык дигән бер аерым урман эченә җыелдылар. Бу умарталыкны. Тукаевлар үзләренә тиешле урманларны аерып, үзләренә милек кылып, әтрафны канау белән казып куйганлар икән. Мәҗлес башланды. Уртага чыгып: "Мөхтәрәм кардәшләр, рөхсәт итсәңез, минем күпчелеккә бер киңәшем бар иде, - дип сорадым да, рәхим итеңез дидекләрендән соң, сөйли башладым: "Менә, җәмәгать, үзеңезгә мәгълүм, мондан туксан ел борын Эстәрлетамак сәүдәгәрләрендән Габделхаликъ

[1] Гыймарәт кылдыра – төзи, кора.
[2] Мәэмүр – билгеле бер эшне эшләүче, билгеле бер эш йөкләтелгән кеше.
[3] Гам – күмәк.

Мәҗидов дигән авылымызга бер гомерлек сәдакамыз булсын нияте белән су, ягъни фонтал китерткәндер. Шул су юлымыз бу көндә бозылып ятмакдыр. Авылымыз яхшы суга мохтаҗлыгын һәркайсыңыз беләсез. Бик дә ут-янгын вакытларында авылның уртасында су юк, булса да бик аз, алу кыендыр. Моңа мөхтәрәм ага вә энеләр, тәвәккәле Ходa, шушыны эшләтеп юлга салыйк дип, мин сезләргә мәслихәт кылам. Сезләр кулыгыздан килгән кадәрле ярдәмдә булсаңыз, бондай халык файдасына эшләнә торган эшләргә, шиксез, ярдәм бирәчәкдер. Мондан тыныч булыңыз, - дидем. – Икенче, безләр хәзерге көндә иркенлек хөкүмәтенә чыкдык, элекке хөкүмәт вакытында үз ихтыяры белән бондай эшләр эшләтү агыррак иде. Тукаевлар булса, су үзләренең йортларында булу сәбәпле, күпчелек суга мохтаҗ булсалар да, күп игътибар кылмаслар иде. Инде безләр шушы тәрәкъкыйлек заманында торып да, берәүнең китергән суыны юк кылып калдырсак, тарихда бер кара булачак. Моны һәркайсыгыз аңласа кирәк. Бу Эстәрлебаш тарихында мондай тарих калдыру гафу ителмәслек бер ят булачак. Әгәр дә безләр бу эшкә чын күңелемез белән көчемезне салсак, соңгы гасырларда булачак бәндәләргә бер истәлек булачак, кыяматкә кадәр үземезгә бер сәдакаи җария булачакдыр. Коръәннең һәр аяте кәримәсенә وَنَكْتُبُ مَا قَدَّمُوا وَآثَارَهُمْ[1] мосаддакнәсе будыр: Без язармыз үлмәсдән элек ънең мәгъбулачакдыр. Аят [2] артларына эшләп калдырган яхшылыкларны димәкдер. Әлбәттә, беләсезләр, кыяматкә кадәрле бу суымыздан ничә миллион адәмләр һәм булган хайванлар эчәчәк, һәркайусы сусауларындан рәхәт булып китәчәкдер. Шулар мохтаҗ булган сулардан рәхәтләнеп куанып китәчәкләрдер. Мисал өчен, эссе көнләрдә бик сусап, су табалмый йөргән вакытыңызда алдыңызда бер коены очратып калсаңыз, рәхмәт бу коены ясаган кешегә дип китәсез. Бу вакытда син бер генә кешесең, безнең ясаган фонтанымыздан миллионлар эчәчәкдер. Адәм балалары ижтиһад кылса, булачакдыр. Коръән әйтә: وَأَنْ لَيْسَ لِلْإِنْسَانِ إِلَّا مَا سَعَىٰ[3] дия. Адәмләргә юк болар, үзләре хәрәкәт кылсалар гына. Безнең Коръәнемезгә муафикъ олуг инкыйлабның башлыгы Владимир Ильич Ленин әйтәдер: “Кем эшли, шул тешли”, дия. Боны Коръән дә шулай ди”. Бу турыда байтак сөйләп төшендергән соң, бәгъзе агайлар мондай зур эшләр кулымыздан килер микән диючеләр дә булды. “Ихлас белән эшләнсә, ирләрнең көче тауларны күчерәдер”, - дидем. Бәгъзе берәүләр әле сусыз торганбыз бит, безгә ул фонтал ник кирәк. Берәве әйтә - минем коем бар, берәве - минем ягдан су агып ята, диючеләр дә булды. Адәм баласы үзе өчен

---

[1] Коръәннең Ясин сүрәсе 12 аятеннән: “уа нәктубу ма каддаму уа асарахум” (Алар элек эшләгән эшләрне һәм аларның хатирәләрен язып барабыз).

[2] Мосаддак – дөреслеген ныгытучы.

[3] Коръәннең 53 сүрәсе 39 аяте: уа әл-ләйсә лил инсани илля ма сәга (кешегә үзе кылган гамәлләреннән башка нәрсә йөкләнмәс).

генә уйлап карарга ярамый - Эстәрлетамак Мәҗидовнең дә өендә суы, я коесы булса кирәк. Ни өчен минем коем бар дия Эстәрлебашка фонтал эшләткән, бер уйлап караңыз, монда һичбер шәхси файда булмаса кирәк.

Сез әйтәсез - боңа безләр яхшы төшендек. Моны эшләргә акча ничек табармыз. Бу хакда ибдәш агроном сөйләп бирер, андан сораңыз. Бу хакда агроном сүзгә керешеп әйтә башлады: "Ибдәшләр, бу фонтал хакында мин аз гына сөйләп үтәм. Мин бу көн ибдәш Кадыйровның сөйләгән сүзене бик дөрест дип белдекем соңында үз тарафымдан шуларны гына әйтәчәкмен. Сезләр боны эшләтергә акча кайдан табамыз дия. Ибдәшләр, тиздән хөкүмәт тарафындан халыкга үзара салым салыначак (самовложение), менә шул салымдан җыелган акчаны халык үзләренең гомуми кирәк урынларына: күпер, кое казыту кеби вә башкалар – тотарга рөхсәт итәчәк. Бу - бер. Икенче, бу гына йитмәсә, хөкүмәтдән карз (ссуда) алырмыз. Һәм күрсәтеп эшләтергә техника сорармыз. Бу эшләргә үзем юллап алып, сезгә ярдәм кылырга вәгъдә кылам. Фәкать сезләрдән сорыйм, бу бер файдалы булган эшне эшләргә бер-ике, өч көн үзеңезнең, атларыгызның көчләрен җәберләнми генә салып, бер тән, бер кул булып ярдәм итүеңезне сорыйм. Минем сүзем тәмам. Инде бу хакда беренче бу фонталны эшләтүгәме-юкмы – тавышка куярга кирәк. Икенче, эшләргә карар булганнан соң биш кешелек бер комиссия сайларга кирәк. Шул комиссиямез, тиешле тәдбирләрне күреп, карап эшләтер. Өченче, җир казу, урмандан һәм башка урынлардан материал китертүемезне үземез өстемезгә аламыз дия тавышка куеп карар чыкарырга кирәк. Шундан мин сүз алып: "Мөхтәрәм җәмәгать, бу эш хакында бер дә авырсынмый гына үзеңезнең балаларыңызны ризыкландыру өчен җәй буе җирләр сөреп, урып, басдырып һәм башкалар, ничек тырышып эшлимез, бу фәкать үземез өчен генә, әмма бу фонтал гомеремезгә кадәрле файдаланып һәм Хода кашында меңлек саваплы. Ахирәтдә Хода кашында дөньяда кылган яхшы гамәлләремезгә хисап кылыначагында шөбһә юкдыр, намаз, рузә кебидер. Меңә, уйлап караңыз, арамызда берәүләр ничә айлар һәм еллар буенча түшәкдә авырып ята. Берәүләр ничә еллар төрмәләрдә яталар, әй сәламәтләнсәм, төрмәдән чыксам иде, әллә ниндәй яхшылыклар кылыр идем, дия. Менә боларны искә алып, сәламәтлегенең кадерене белеп, бер-ике, өч көн сәламәтлеңеңезнең сәдакасы булыр дип уйлап, бу хезмәтеңездән шадланып ярдәм бирерсез дип чын күңелемдән шадланамын. Янә берәүнең бер бер аты үлеп кала. Ай, атым булса, фәлән эшләрне эшләр идем, ди. Фәкыйрьләргә булса, Хода өчен булган эшләргә ярдәм кылыр идем, ди. Эш үтде, хәзер үкенеп сөйләүдә файда юк, әүвәлдәрәк иде. Шуларны хисаплап, бер-ике көн атларыңызның сәламәтлекене теләп, атларыңызның көчен дә ярдәмгә түшәрмез дип әйтәм. Болар бар да авыр эшләр имәсдер". Инде

тавышка куярга калды, беренче, фонталны эшләтергәме-юкмы дия, күпчелек белән эшләргә булды, икенче – комиссия сайларга, биш кеше кандидатлар күрсәтеңез, дия. Мәҗид Кадыйров, Басыйр Дәминев, Мөхәммәдхәсән Сәйфелмөлеков, Мәҗид Хөсәенов, Мәҗид Монасыйпов, Хәлилулла Һибәтуллин – шуларны тавышка куеп, күпчелек белән карар булды, алтыдан берсене могавин[1] кылып, берәрсе авырып калса, аның урынына эшләр дип торырга карар булды. Өченче – җир казу эшләрен, фонтал өчен кирәкле нәрсәләрне ташырга үз өстемезгә аламыз дия тавышка куелып, бу да үтде. Инде калды эш башларга.

1926 нчы ел майның 20сендә техник комисия белән танышып, эш башлау хакында сөйләшдек. “Нишләргә кирәк, - диде. Беренче, авылда булган ир җанын, эшләрлек кешеләрнең һәм рабочий атларның спискасын алыңыз, - диде. Андан хуҗалык эшләре береңезне сайлаңыз, кирәкле материалларны табып алырсызлар. Калганыңыз монда эшләүчеләрне карап торыр”. Хуҗалык нәрсәләрне башкарырга Хәсән Сәйфелмөлеков, урмандан яраралык агачларны табып, шуларны тиешле урынына китерү өчен Басыйр Дәминовны тәгаенләдек. Калганларымыз һәр эшдә күрсәтеп эшләрләр иде. Рабочийлар һәм атларның хисабын, тиешле рәвешдә нарат эшенә һәм атка Хәлиулла Һибәтуллин тәгаен кылынды. Спискалар тәмам булды. Инде суны кайдан китерәмез, ни рәвешле, борынгы юлынданмы, юкса, яңа ясаргамы? Бу хакда мөзакәрәләремез[2] булып, иске юлны ташлап, яңа юл белән китерергә булды: борынгыдай, яңа бүрәнәдән салынып, суның килеше нормальный рәвешдә булырга. Борын көч белән килер иде. Эстәрлебашның олуг урамына өч урынга зур шәк эшләтеп, эчендә ничә мең чиләк су торырга тиеш. Бу шәкләрне өстен тимер белән яптырып, һәрвакыт ат-арба мичкәсе белән бүтән алучылар шул шәкдән качать итеп алырлык булсын. Чишмәнең чыкган йирен казытып, урынына бура төшереп, түбәсен тимер белән ябып, буятып куярга. Борын ага торган улакны һәм кер юу өчен урынлар кылдырырга. 1 нче шәк – мөәзин йортына каршы базар янында, икенчесе – борынгы бәләкәй чишмә аталган урынга, өченче – ташкүперне үткәреп, Эстәрлетамакга китә торган урам чатына билгеләнде. Юлы борынгы Тукаевлар бакчасы аркылы олуг мәсҗед яныннан үтеп, мөәзин йортына тиеп, шундан борылып, беренче шәккә, андан икенчегә, андан, күпер аша чыгып, өченчегә, андан кайтып кире таш күпер төбенә – Эстәрле суына төшәчәкдер. Беренче нәүбәтдә, су башын казып, тирәсене мәте балчык[3], глин белән утрамбовать итәргә булып, кызыл яр чокырындан һәр ат башына 18 йөк балчык китерергә һәм үзем дә

---

[1] Могавин – ярдәмче.

[2] Мөзакәрәләремез – фикер алышуларыбыз.

[3] Мәте балчык – үзле балчык.

ташыдым. Шулай итеп, беренче эшемез башланды. Аллаһ тәмамларга насыйп итсен. Амин. Бүрәнә юлыны казырга булдык, димәк, суның башыннан өченче шәккә кадәр бер километр озынлыгында тиешле булды. Моның өчен метр хисабы белә һәрбер рабочийга күпме метр казырга, тирәнлегене карап, берәүгә өч метр, берәүгә бер метр төшде. Үзем дә су башына якын урында тиешле вазыйфамны эшләдем. Инде монда салу өчен күпме бүрәнә кирәк. 130 данә кирәк табылды. Бу бүрәнәләрне алып килер өчен Хәсән Сәйфелмөлековны йибәрдек. Ак Идел баш тарафына тауга барып, шул бүрәнәләрне сал белән Эстәрлетамакга китерергә. Эстәрлетамакдан үземез барып алып, Эстәрлебашка китердек. Үзем дә барып, кирәкле ябу тимере һәм төпкә кыршау өчен булган тимерләрне алып кайтдым. Инде бу бүрәнәләрнең озынлыгы 9-10 аршин чамасында, шуны үзәгендән генә борып тишәргә кирәк иде. Борындан моны бора торган борау үземездә бар иде. Шуның белән борырга Эстәрлетамакдан осталар китертеп, һәр бүрәнә башына бер сум илле тиен биреп тишдердек. Инде йирләрне казырга булды. Бу июнь айлары иде. Базарларда ризыклар кыйбат булып, халыклар казырга авырсына башладылар. Бу эшкә "Мәҗид карый дин белән безләрне агулап төшерде" дия, миңа бик күп каргышлар ишетергә дә тугры килде. Мин дә салкын кан белән генә сабырлык кылып йөрдем. Күпчелек арасында була торган. Берәүләрнең ризыклары да ким булды, казып бетерделәр. Аллаһ боларга савапларын насыйп итсен, амин. Инде бүрәнәләрне салганда һәр бүрәнәнең ике башына тимер кыршавына ике бүрәнәне тоташдыру өчен втулка кагарга кирәк булды. Йитәрлек втулка-кыршауларны Шаһиәхмәд дигән тимерчедән эшләтдек. Базарга чыгам – он кыйбат, бәгъзе ага-энеләр һәрвакыт миңа: "Күрәсең базар хакларны, давай, он табып бир" – шундай сүзләр белән күп башымны ватдылар, хәтта халык арасына чыгуга курка башладым. Мәҗбүр булдым атымны җигеп, бер биш-ун көнгә Оренбургка барып кайтыйм дип чыгып китәргә. Шулай да, эшләр авырлык белән булса да, бара иде. Ибдәшләргә дә әйтдем: "Мин азрак йөреп кайтыйм әле, һәр ничек дә эшне алып барырга тырышыңыз", - дия киттем, Ходага шөкер, бераз тын алып, сәламәт кайтдым. Эшләр эшләнеп бару өстендә иде. Булган бүрәнәләрне тиешле рәвешдә салып тәмамладык. Шәкләр дә эшләнеп тәмам булды. Чишмә башында эшләнгән бурамызга да су тулды. Артык суны шундагы улакга йибәреп торамыз. Инде бүрәнә буенча суны йибәреп күрергә булды. Я Аллаһ, монда йитде Мәҗид карыйга я терек, я үлем вакыты, әгәр дә су йөрми калса, шул вакытда мине халык үземез казыткан чокырга салачаклар иде. Бисмилла дип, суны ачып йибәрдек. Үзем йөгереп барып, беренче шәкнең эченә төшеп, тишекгә колагым куеп, бар белгәнем дога укып ятдым. Тыңлап ятам-ятам, бер вакыт чың иткән тавышлар колагыма ишетелә

башлады. Күп дә вакыт үтмәде, су килеп төшде, башыма коеп йибәрде дә мин дә “әлхәмдүлилләһ” дип шөкерана кылып, инде үкенечем бетде, үлсәм дә үкенечем юк дия куандым. Хода дөньяда халык өчен ниндәй яхшылык кылдың дип сорау булса, шушы эшләрне куячакмын дип, җәнабе Раббилгаләмин, мине дә бу эшемне сәдакаи җариядән хисап кылып, кыямәтгә кадәр бу эшемнең әҗерене насыйп итсә иде дип, күңелемдән дога кылдым. Ошбу көнгә кадәрле бу су дәвам итмәкдәдер. Соңра бөтен әтраф халкымыз да моңа: “Карый, сезләрнең хезмәтеңез бушка китмәде. Авыл рәхәтләнеп су эчә, килгән адәмләр дә су эчеп, һәркайулары, рәхмәт боны эшләтүчеләргә”, - дип китәрләр иде. Хода өчен булсын, бәнем Эстәрлебашына кылган яхшылыгым шушы булса кирәкдер. Бәлки укып бу тарихны беләләр һәм укучылардан үтенечем шулдыр – безгә дә бер дога кылуларыны.

1953-1954 елда бу фонталны хөкүмәт үзе янәдән яхшырак кылып, без китергән юлдан аз гына югарырак казып, чуен торба салдырды. Без куйган шәкләр янына янә берничә урынга гранит куеп эшләтде. Бу инде башындан бирле Эстәрлебаш фонталының өченче эшләнүедер. Беренче Габделхаликъ Мәҗидов китергән фонтал, астарак, Эстәрле суы якынрак килеп, югарыда күрсәтелгән суларга килеп кермешдер. Икенче, безләр эшләткән юлы, тауга табарак эшләтелде. Өченчесе – безнең юлдан бәгъзе йирләрендә янә дә тауга табарак казылып, без торган йортымыз алдындан үтеп, авылның югары ягынарак үтеп, андан борылып, олуг урамга чыкмышдыр. Мөхтәрәм укучылар, менә минем бу Эстәрлебаш фонталы хакында аз гына булган белүемне тарих булып калсын нияте белән яздым. Кыска гына булса да, мондан соң калган Эстәрлебаш фонталы хакында тарих язучылар булса, боңа кушылып бәлки язарлар.

Язу калыр кәгазьләрдә заманлар буенча, язучысы туфракда черегән булыр. Бу фонтал хакында кыска гына белүләремне язып, сүземне тәмам кылдым. Эстәрлебашда Габделмәҗид бине Шәйхелислам Кадыйров әлмәшһүр Мәҗид карый, 1955 елда.

***Мәхбүслекдә йөрүем хакында***

Нахак белән гөнаһсыз мәзлум булып мәхбүслекдә йөрүем хакында аз гына язып, киләчәк балаларыма ядкәр һәм гыйбрәт булу өчен бу вакыйганы язып калдыруны уйладым. Бу – 1928 нче елның 11 нче декабрь вакыйгасыдыр. Эстәрлебашына прокурор могавине Гыйзззеддин Галиев кемсәнә хаталык белән караңгы төндә олуг урамда кулында үзенең коралы белән, ягъни наганы белән аягы ташка бәрелеп, үз-үзен һәлак кылмышдыр.

Югарыда сөйләнмеш Галиев беренче мәртәбәдә прокурор булу сыйфаты илә Эстәрлебашына килмешдер. Үзенә тиешле эшләр хакында. Бу

Галиев Дим буе Кырган авылындандыр. Әүвәлдә минем заманымда Эстәрлебаш дини мәдрәсәсендә дә укымыш иде. Шул сәбәпле, миңа таныш ибдәш иде. Инкыйлабдан соң укып, юридический эшләрдә эшли башламышдыр. Беренче Дим буе Никифар авылында судья Хөсәен Терегулов белән суд эшләрендә эшләр иде. Никифарда туган карендәшемнең фатирында тору сәбәпле, һәр барган вакытымда сөйләшеп ултырыр идек. Андан соң Кыргыз Миякә авылында эшләмешдер. Соңра Эстәрлетамак килеп, прокурор ярдәмчесе булып эшли башлаган. Хатыны Никифар авылының Исмәгыйль мулла Исламкулов кызы Гайшә иде. Бу Гайшә дә бала вакытындан минем кардәшем Фәрхисорур йортында һәрвакыт уйнап йөрер иде. Шул сәбәпле, мин аны, ул мине бик яхшы белер иде. Һәрвакытда Галиев белән башкорт авылларында сабан туйларында очраша идек. Дим буе Нарыс-тау (Чебенле) авылында Сабан туена килгән вакытымда шул авылның Дәүләтша ага йортында бер кунып, кунак булып идем. Эстәрлебашына килүне белеп, моны күрергә теләдем. Очратдым: “Исәнме, Мәҗид абзый” - дия исәнләшеп, Гайшә дә әйтеп иде, анда Мәҗид абзый да бар, күрсәң, сәлам әйтерсең диде. Рәхим итегез, безнең өйгә, кунак булыңыз” диюемә каршы: “Гафу идәрсез, Мәҗид абзый, бу сәфәрдә бер дә барырга вакытым юк, дип, насыйп булса, икенче сәфәрдә килермен”, - диде. “Ярый, рәхим итүеңезне үтенеп калам” - дип, аерылышып китде. Бу кичәдә Галиев спектакльгә, анда борын Кыргыз-Миякәдә эшләгәндә лесник таныш хатынны очрашып спектакльдә бергә ултырганлар. Бу хатын Эстәрлебашында почта начальнигы Самарин дигән рус белән тора икән. Бәлки спектакльдән соң фатирыңызга барырмын дисә кирәк. Шундан соң Галиев вулыс йортына барып, совещание корган. Соңра, сәгать тугыз-ун чамаларында чыгып, вулысның сторожына барып, минем наганым дип, алып кил, дип әйткән. Мин хәзер кредитный обществога барам дип, вулыс председателе әйткән: “Алайса, мин сезгә озатып барырга кеше бирим”, - дип, наганын күрсәтеп, бу булгач, кеше кирәкми, димеш. Төнләр караңгы, урамлар каткан, пычрак. Шул вакытда бу чыгып, почта йортына барып кереп, тышындан тәрәзәдән караса кирәк. Йортның икенче ягында бер аулак өйдә малайлар-кызлар җыелышып, уен коралар имеш. Бердән, йортда малайлар чыга башлаганлар һәм өйдән Самарин да чыга башласа кирәк. Бу, шундан куркып, ашыгып, урамга чыгып китә, капкага каршыга фонтал бар, аның әтрафында зур ташлар, бүрәнәләр ятып калган. Бу – караңгыда ашыгып барган кеше, бердән, ташка абынып китә дә, белмәсдән, кулындагы наганындан яңлыш атылып егыла да, башы ташка бәрелә. Шул ук минутда икенче мәртәбә ату була, монысы халыкга хәбәр бирү өчен булса кирәк, чөнки наганның ул атылуы да, икенче мәртәбә дә ачык тавыш була. Кешеләр килеп йитеп, “харап булдым, йортка кертеңез”

димешдә, шунда ук алып кереп, почта өенә салганлар. Су сорап, фонталдан алып килеп, суык су эчергәнләр дә, шул сәгатьдә җан бирмешдер. Егылган урынында наганы ятып калган, ике пуля атылган, эчендә ике гильзасы юк. Бер пуля үзенең пимасының эчендән чыкган. Шул вакытда свисток һәм биргән, бу свисток да янында ятып калган. Пуля, пальтосының сул як чабуын һәм брюкасын тидереп, сул як ботына тиеп, йөрәк тамыры аша чыгып, пимасында торып калган. Кансыраган адәмгә, бердән, суык [су] эчереп, йылы су эчердек, дип әйткәнләр. Бу бер, икенче, "харап булдым" дигән сүзне харап итделәр дип, урындагы түрәләр алдап әйткәнләр, үзләрен хезмәт күрсәткән кеше күрсәтеп атканлар дип, төн буенча авылдан ниндәй арурак кешеләр булса, шуларны кулга ала башладылар. Сәгать унберләрдә өемдә ибдәш Хәсәнов белән бер гариза язып ултыра идем. Капка ачык, өстәлдә кара-каршы ултырамыз. Тәрәзә-капкачлар да ачык. Бердән, ишекне кага башладылар, чыкдым кем бар дия, без, ач, диде. Ачдым, күрсәм, милиция, следователь, судья һәм башкалар керделәр дә: "Кулыңызны күтәреңез" дип команда бирделәр дә, обыск башладылар, "сезләр арестованный" диделәр. Җәмәгатем һәм балалар йоклый иде. Үземезне, бөтен сандыкларны, өй түбәләрен – барын карагандан соң, безләрне алып чыгып китделәр. Без исә, бу ни хәл, ни эш булганын белмимез, алып барып бикләп куйдылар. Өч мәсҗеднең муллаларны, мөәзинләрне, башка авылда булган хәллерәк крестьян вә сәүдәгәрләр, хәтта шул көнне Эстәрлетамакда булган кешеләрне җәбер биреп, барын да кулга алдылар. Җәмгысы 36 кеше иде. Шундан соң вулыс председателе Карагыш авылының Сабир Максудов, народный следователь Гыйният Төхфәтуллинлар Уфага  телеграмм бирмешләр. Мәсьәлә шундай, аткан кешеләр бар да арестованный дип. Мин ятам ни эш булды икән дип исем китеп, һичбер нәрсә белмим һәм башкалар да шулай булса кирәк. Бөтен авыл читләренә каравыллар куеп, ничә көнләргә кадәрле һичбер адәмне кертмәделәр вә чыгармадылар. Иртәләп Уфадан начальник, военный прокурорлар килә башлады, бөтен Эстәрлебаш бер кыямәт хәленә килде. Чыж да пыж халык сөйли һәртөрле сүз, ниндәй эш булды икән, төнлә каравылга смена булды. Икенче каравыл килгәч, сорадым ни бар дия. Ул "прокурорны атканнар" дия әйтде. Исем китеп калдым, күңелгә килмәгән бер эш, сабырлык кылдым, Ходага тапшырдым. Бер көн хаклык мәгълүм булыр дия өмид итеп ятдым. Инде тикшерү башланды, допрос ала башладылар. Беренче ибдәшләрне чакырып җавап алгач һәм чакырдылар. Мин илле яшем кадәрле мондай әхвәлне күрмәвем сәбәпле, бераз куркып-каушап калдым. Чөнки мин үз гомеремдә хаким алдына килеп, гүаһ[1]  сыйфаты белән дә җавап

[1] Гүаһ – шаһит.

биргәнем юк иде. Шул көнне иртәдән кичкә кадәр кайда булдың,ниләр эшләдең, кемләр белән сөйләшеп йөрдең, Галиев сиңа таныш идеме, бу-башкалар, күп нәрсәләрне сорап, барысына да җавап бирдем.

***Галиев хакында.***

"Бу эш хакында үзеңне гаепле дип беләсеңме?" Юк. "Бу көндә кемләр белән сөйләшдең, кайларда булдың?" Җавап шунда: "Шунда, шуның белән сөйләшеп тордым. Көндезендә каенагамыз, җәмәгатем белән бергә һәм башка ага-энеләр, мине дә, күршеләрне кунакга чакырып иде, шунда булдым". "Кемләр бар иде, барын да әйтеп бир". "Фәлән-фәләнләр, үземнең һәрвакыт эшләшеп йөргән бер фәкыйрь адәм дә бар иде". "Ул кем?" "Хәбир Исхаков" - дидем. Андан соң әйтдем: "Мине шул көнләрдә генә хокук тикшерү комиссиясе, хаксыз уларак, хокукдан мәхрүм кылган өчен гариза биреп юлламак иде. Комиссиядә Зәйнуллин Лотфулла, Мөхеддин Һибәтуллин, янә кемдер, исеме хәтеремдә юк, комиссия рәисе, үзем кандидатураны күрсәтеп, 21 нче елда мөгаллимлеккә куйдырган идем. Мәҗид Хәсәнов борындан безләрне җәдид дәһри дип көлеп йөргән бер хәлфә иде. Комиссиядә минем тарафда бер тавыш ким булган рәис сыйфаты илә Хәсәнов хәрәм тавыш биреп, мине хокукдан мәхрүм кылганлар". Берәүгә яхшылык кылсаң, яманлык көт димешләр, бу шундан булды. Көн-төн үземне акларга, һәрбер урындан справка алып материал җыю иде. Бу хакда Галиевкә кереп, эшемне сөйләмеш идем. Ул әйтде: "Мәҗид абзый, мин сине инкыйлабка кадәр кем икәнеңне беләм. Инкыйлабдан соң ниндәй эшләр эшләдең, шул хакда справкалар алып, миңа гариза бирерсең, мин тикшерермен, - диде. - Ләкин тизрәк эшлә, мин бер көндән китәм" - диде. Шул хакда Галиев янында булдым. Ул сиңа танышмы, ул коммунист, нишләп аның белән сөйләшәсең, дия. "Ул минем яшь вакытында бергә укыган, һәрвакыт күрешеп йөргән ибдәшем иде, - дидем. 11 нче декабрь көнне көн буенча эшем белән сәгать кич тукызга кадәр йөрдем. Хәтта сикез, ун яшьле балаларымны йибәреп, фәлән кешегә барып, мин сораган кәгазьне сорап алып кайтыңыз дия йибәрдем. Көндезендә Хәсәнов белән сөйләшеп, гариза язармын дия чакырып идем: "Сәгать сикездә кич кил әле, бергәләп инструкция карап, гариза язармыз" дия. "Ярар, барырмын" дип вәгъдә, шуны өемдә көтеп ултыра идем. Бер мылтык тавышы ишетелде ачык тавыш белән, соңра икенче мәртәбә янә мылтык тавышы томанлы иде. Шундук свисток тавышы, ай-вай дигән тавышлар ишетелә башлады. Минем йортым югарыда иде. Колидорга[1] чыгып, баскычдан тыңлап тора идем. Шул углым белән кызым йөгереп, куркышып кайтып килделәр: "Әти, әллә ниндәй мылтык тавышлары, урамда

[1] Колидорга – коридорга.

кешеләр фонарьлар белән йөриләр”. Мин, берәр исерекне урамда милицияләр алып киткәндер, диям. Шундан өемә кереп, эшләрем карап ултырыр идем. Күп дә үтмәде – Хәсәнов килеп керде. Әллә ниндәй урамда шау-шулар ишетелә, мин дә монда колидорга чыгып ишетеп тордым. Нә булгандыр, белмәдем. Соңра гаризларамызны язып ултыра идек. Бердән, ишекне кагып чакырып чыгардылар. Ачдым, милицияләр керделәр дә, икемезне дә арестовать итде, җәмәгатем, балалар йоклый иделәр, дидем. Янә ничә мәртәбәләр чакырып, допрос кылдылар. Ничә мәртәбә йортларны обыска кылганлар. Бер-ике, өч көндән соң Уфадан килгән прокурорлар кайтып китә башладылар. Халык алдында атамыз дип килгәнләр икән. Хода кушмаган эш булмай, хаклык чыгар әле дип ятамыз. Шул дәрәҗәдә бер дәһшәт ки, каравылга авылдан кеше йитешмәде. Күрше авыллардан каравыл китерделәр. Шундан соң фәкыйрьләр собраниесе җыеп, безләрне сораганлар, халык әйткән, фактический растланса, без бу көндән атуыңызны сорыймыз, ләкин растламый торып, бу эш болай булыр дип ышанмыймыз, бәлки башка авылдан килеп, берәр дошманы аткандыр. Безгә һичберсе мәгълүм имәс. Сезләрдә сыскной этләр бар, һәр халыкны һәм мәхбүсләрне дә чыгарыңыз да, әгәр дә эт берәүне тотса, шулар гаепле булыр дип әйткәнләр. Икенче көн халыкны җыеп һәм этне үлгән урынына алып килеп караганлар икән, почта начальнигы белән Заһреддинов дигән милицияне тоткан, болар егылган урыныннан күтәреп, өйгә алып кергәнләр икән. Шундан этне йибәрмәгәнләр, туктатганлар. Халык: “Йибәреңез этне!” дия сораса да, йибәрмәсдән, этне алып киткәнләр. Шундан соң безләрне барымызны да Эстәрлетамакга төрмәгә озатдылар, авылда ун көн ятдык, Ходага шөкер, төрмәне ишетеп белсәк дә, гөнаһсыз булып, керергә дә насыйп итде.

Бер хафаланмай, нахак, вулысның рәисләре вә башка кешеләрнең ялган күрсәтүләре белән җәмәгатем, алты балам, ике ятим кардәшем – шуларны калдырып китдем, гөнаһсыз булуым сәбәпле, бер дә кайгырмадым, хөкүмәт хаклыкны тикшереп белмәсдән гөнаһсыз бәндәләрне җәза кылмас дип өмид зур иде. Галиевнең акт язган вакытда пәлтәсе белән брюкасының янганын язмаганлар. Шул вакытда сельсовет председателе Хәйреддин Фәррехшатов әйткән: “Ни өчен пальто белән брюканың көйгәнен язмыйсыз, минемчә, мин боны язарга сорыйм, - димеш. - Без сугышда вакытда, якындан килгән пул[1] яндыра, еракдан килсә, яндырмый дип әйтерләр иде дип, шундан язмышлар. Үлекне караган дохтор башда әйткән: “Әйтү кыен, мөмкин янәшә килеп атуга, урынлы начальникларның сүзенә буйсынып атканлар”, - дия үзенең фикерене язмышдыр. Шундан соң үлекне Эстәрлетамакга озатканлар. Анда

---

[1] Пул- пуля.

заводлар гудоклар кычкыртып каршы алганлар. Язып үтмеш идем безнең белә Хәбир Исхаков да ашда булды дия. Бу бичараның бәхетсезлегенә каршы, барып тикшерсәләр, канлы тун, канлы пычак мич башында ята икән. Милицияләр табдык үлтергән кешене дип, шадлык белән прокурордан сөенче алганлар. Дөрест, үтергән кешене тапмаганлар, тик канлы тун белән пычак тапканлар, аны бит суймаганлар пычак белән, атканлар пуля белән. Аларча, әгәр дә тун үлтерүче булса, ул гаепле булыр иде. Шундан соң Исхаковдан сөаль башлана. Синме Галиевне үлтерүче, дия. Бу җавап бирә: "Юк, ахшамдан йокладым, эшкә дә чыкганым юк", - димеш. Ник алдыйсың, атылуны уйлыйсың дия гаепләүче куркыта имеш. Тикшереңез, дөрестләңез, атарсыз димеш. Алай булгач, канлы тун белән пычак кайдан сезгә барып кергән. Җавап: "Ул сиңа килеп кермәде, ул төн белән пычакны мин үзем алып кердем. Нигә дисәңез, кичдән мин фәлән кешегә ат суешырга барган идем, шунда канга буялган, мин кайтдым, мич башына ташладым. Менә кайдан ул кан", - димеш. Һәм ат суйдырган кешене чакырып сорасалар, ул, дөрест димеш. Пычакны Мәскәүгә йибәреп, тикшертеп кайтардылар, Мәскәүдән ат канлы булуына растлап кайтарганлар. Эшләр барып чыкмый этне дә йибәрмәделәр, тун белән пычакдан да булмады. Бу кешеләр бик хафада калдылар, үзләрендән үзләре курка башладылар, аткан кешеләрне арестовать итдек дип телеграмм бирде, йиңел булса да исбат итүе бик авырга калды. Шундан Эстәрлетамакга төрмә керү белән безгә бер кеше кычкырды, үлекне алдырып, дохторлар комиссияне сорап, яңадан тикшертсенләр дия. Безләр мондай эшне кылмавымыз вә күрмәвемез сәбәпле, курыкдык, бәлки тикшерүсез рәвешдә безнең зарарга эшләделәр дия. Әгәр дә шул вакытда бу эшне кылган булсак, безләр, бәлки, котылган булыр идек. Чөнки Уфада профессорлар, дохторлар унйиде кеше бу хакда акт буенча вә башка үз фикерләрне йөретеп, үзендән атылырга тиеш дип тапканлар. Әгәр дә вакытында комиссия караган булса, шундук мәсьәлә ачылган булыр иде димешләр вә өч ай Эстәрле төрмәсендә ятып, безләрне Уфага озатдылар. Барымызны да Уфага барып, следственный корпуска һәммәбезне бер камерага кертделәр. Берничә көндән соң безләргә ГПУ тарафындан унбер кешене гаепле кылып, прокуратурага эшеңез йибәрелде дия, соңра мондан башкаларны һәртөрле срок белән Себер әтрафына выселкага йибәрделәр: Омскига, Нарымский крайга вә башка җирләргә. Безләр, я, Ходай, ни булса дип ятамыз, гали суд идарәсенә берничә кәррә сөальгә чакырдылар. Шундан соң безләрне общий корпусдан дүрт катлы Столыпин корпусына төрле камераларга куйдылар. Мин икенче катда 19 нчы камерада утырдым. Галим Тукаев миңа күрше камерада иде. Хәсәнов өченче катда иде. Руза ай килеп йитде, Хода кабул итсен, төрмәнең икмәге белән салкын су эчеп, рамазан

узамыз, тәүлекдә биш вакыт намаз калмады, Ходага шөкер. Шул вакытда мәрхүмә җәмәгатем күкрәк баласы Мәрьям исемле кызым белән килеп күрешеп, сөйләшеп китде. Бу ихтирамлары өчен хак олуг әҗерләр бирсен, амин.

Шундан соң апрель айлары иде. Мыш-мыш хәбәрләр чыга башлады: безләрне коткаралар имеш. Хәзер эшләреңез гали суд алдында, зур эшләрне тикшерә торган өстәмә чыкган мәсьәләнең ахыры шушында ачыла, диделәр. Бу идарәдә, “следователь товарищ” диләр монда, Госманов дигән кеше эшли иде. Русларның пасха бәйрәмләре йитеп калды. Бердән бер көн безнең ибдәшләрдән җиде кешемезне чыгарып йибәрделәр. Тик калдык безләр биш кеше: мин, Габдеррәхим Гобәйдулла углы Тукаев, Хәсәнов, Исхаков, Һади мөәзин. Безләрне гаепле кылдылар ахры дип уйланып калдык. Котылып китүчеләр: Габдеррәхим Лотфулла углы Тукаев, Галим Тукаев, Габдрахман Айдабулов, Басыйр Дәминов, Әхмәд Галиев, Мәҗид Монасыйпов. Көнләр берендә Никифарда туган киявем Мәҗид Вәлиуллин килеп күрешде һәм күчтәнәчләр китерде, ул әйтде: “Абзый, курыкмагыз, чыгачаксыз”, - диде. Мин әйтдем: “Син мине юатыр өчен генә әйтәсең, башкалар китеп, безләрне аерып калдырмаслар иде”, - дидем. “Менә, абзый, эш мондай икән, җиде кешенең эшене караган, шундан соң авырып киткән, сезнең эшеңезгә нәүбәт йитми калган. Больницадан сәламәт чыкса, сезнең эшне карыячаклар”, - диде. Менә чыкасыз, Хода кушса, дип юатып куандырып китде. Май бәйрәме дә йитеп калды, ятамыз көтеп. Бишенче май көне көндезге ашны ашап кына бетереп тора идек, волчокдан кычкырдылар: “Кадыйров, җыен давай скорее, свобода” дип. Каушап калдым, ишекдән чыкгач, сорадым “башка ибдәшләргә бармы” дия. “Барыгыз да чыгасыз”, - диде. Шундук алар да багажлары белән килеп кушылып, бергә чыгып да китдек. Конторга кереп, кулымызга кәгазь алып чыгып китдек. Тик сәгать алтыда ГПУга барырсыз, диделәр. Төрмә капкасындан чыгып бара идек, мәрхүм Габделкадыйр Тукаев извозчик белән безгә каршы килә иде. Безләр чыкдык бит дип куанып әйтдек. Мин хәзер извозчик йибәрермен дип килеп йитде. Безләрне алып барды, безне көтеп, ашлар пешереп торган икән. Аллаһ рәхмәт итсен, амин. ГПУга бардык, сәгать алты иде. Безләр сезләрне кайткач, бу хакда берәр нәрсә ишетсәңез, я белсәңез, безнең шушы адресымыз белән язарсыз Галиев хакында, димәк, верховой суд хөкемгә бирерлек эш тапмады диде, судсыз сәламәт котылдык. Ходага шөкерләр улсын, әлбәттә, хаклык өчен булырга тиеш иде. Хөкүмәт дә бик яхшы тикшереп, гаделлек белән эш кылды. Мондагы вөҗдан белән хакыйкатьне белеп, безләрне азат итүенә яшәсен хөкүмәт һәм гадәләт[1].

[1] Гадаләт – гаделлек.

Шундан дәһшәтле эшләр булды ки, хәтта ул эшләргә карап, хөкүмәт эшләсә нә чара, боны эшләмәде, фәкать тугрылыклы эшләде. Бөтен газеталар, бөтен рабочийлар собраниесе бердән акырдылар, боларга гали җәза бирелсен дия, хәтта Америкада басыла торган рус газетасы да язды. Мәскәү газеталарында һәм булды. Ниндәй вөҗдансыз залим кешеләр бар икән, 1929 елның 19 нчы гыйнварында Исәнгилдиев дигән ибдәш, мәсьәләне белмәсдән, мине, “Кан эзләре” дия бер мәкалә язды. Коръәнхафиз Мәҗид карый Кадыйров дия, кайткач, үз күзем белән укыдым. Шундай ифтира,[1] шундай ялганны ни вөҗдан берлән язуына хәйран калдым. Менә, укучылар, дөньяда шундай вөҗдансыз  залимлар бар икән. Безнең эшемез Мәскәүгә барып, анда күрелеп, Уфага кире кайтардылар, “яхшы тикшереп күреңез, муллалар, кулаклар дия. Шәхсиятеңезгә бирелеп эш кылмаңыз” дия һәм тәнбиһ кылып[2] язмышлардыр. 1928 нче елның декабрь аенда эшемнең нумарасы[3] 520 иде. Ходаның рәхмәте, бөтен газеталар гали җәза бирелсен дип таләп кылып бакырсалар да, хөкүмәтнең гадаләт[4] белән тикшерүе аркасында безләрне судка бирерлек факт табылмады, андан судсыз чыгарып йибәрделәр. Ходага тәшәккердән гаҗиз калдык. Сәламәт корбан бәйрәмнең Гарәфә кичәсендә сәгать унбердә кайтып, гаиләләремезгә кушылдык. Ходага шөкер, барып милиция идарәсенә мәгълүм булып, тыныч кына тора башладык.  Бу көнләр безләргә зур шадлык булса, залимләр, урындагы начальникларга матәм көне булды. Инде болар ничек дә булса елан кеби явызлык итү ниятләре булса кирәк, безләрне монда яшәтәчәк түгелмез дия бер форсат табып, безләрне яңадан бер сәбәп табып, бер эш кылачакларына уйлап йөредек, чөнки болар үзләрендән курка башладылар. Боларны безгә бер явызлык кылырлар дип, без ничек дә булса монда тотарга ярамый дия миндән бер сәбәп эзләргә тырышканлар. Бигрәк дә Сабир Максудов, Хәбир Төхфәтуллин һәм башкалар. Шундан соң сентябрьнең 19 нчы көнендә вулысда налог хакында собрание булу сәбәпле, каршы сүз сөйләгәнләр Шәрифҗан Галиев, Гобәйдуллин дигән ибдәшләр. Вулыс председателе Максудов, “кайтканлар котырта” икән дип, шул кичәдә безләрне һәм Шәрифҗан, Гобәйдулла ибдәшләрне кушып, кайтадан[5] кулга алып, шул ук кичәдә Эстәрлетамак төрмәсенә озатдылар.  Эстәрлетамакда берничә көнләр ятып, янәдән Уфа төрмәсенә озатдылар. Бу алынуга, Эстәрлетамакда бер чакырып, тормышым, иҗтимагый чыгышым хакында сорап яздылар да, Уфага баргач, башка нәрсә сорамадылар. Әүвәл алынганда 58. 2/3, икенчесендә 58. 2 маддәсене

---

[1] Ифтира – ялган ягу.

[2] Тәнбиһ кылып – искәртеп.

[3] Нумарасы – номеры.

[4] Гадәләт – гаделлек.

[5] Кайтадан – яңадан.

бирделәр. Шул Уфага баргандан бирле 1929 нчы елның август аена кадәр бер сөальсез ята бирдек. Бу вакытда һәр авылдан, районнан мулла-мөэзин вә хәлле адәмләрне – һәммәсен төрмәгә китереп, төрмәне тултырып куйдылар. Хәтта урын булмый калды. Уфа төрмәсендә без бар вакытда 3 мең адәм ятдык. Июль айларында кешеләрне һәрбер тарафка озата башладылар. Бездән Шәрифҗан, Гобәйдулла, Монасыйповларны йортларына йибәрделәр, калганларымыздан бер көнне Габдеррәхим Лотфулла углы Тукаев һәм Эстәрлебаш имамы Галим Тукаевны безнең яндан алып, икенче камерага куйдылар. Бер-ике көндән соң боларны да машина белән алып чыгып китделәр. Икенче көн безләргә игълан кылдылар, ул вакытда ГПУ идарәсендә өч кешелек комиссия бар иде, шуларның карарлары буенча ун елдан миңа, Габдрахман Айдабулов, Мәҗид Хәсәновка биш елдан, Басыйр Дәминов, Әхмәд Галиев, Гыймадеддин Төхфәтуллинга, Хәбир Исхаковга өч ел. Эстәрлебаш вулысының безләрә нахальный бүләкләре шушы булды. 1929 елның 2 нче август көнендә өч йөз кешене Архангел тарафына бер эшалон кылып озатдылар. Хәерле сәфәр дип юнәлдек, көнләр эссе, кызу вагонларда, һәр вагонда 35 кеше, су бик аз бирәләр, түбәдән тимер кыздырадыр. Шул рәвешдә Самар, Пенза, Москва, Петрозаводск, Медвежья Гора шәһәрләрен үтеп, 11 нче көндә Мурман тимер юлы буенда Ляухово дигән станцияга илтеп төшерделәр. Карагай урман, сазлык, Ляухи станциясендән алты километр бер пунктка бардык. Йортлар тирәсендә берничә бараклар бар, күл буенда киртә белән уратып алынган. Безләрне тезеп куйдылар да, исем фамилиябез белән сорап, тәфтиш кылдылар, ГПУ начальниклары үзләренең әйтә торган сүзләрен әйтделәр. Шул вакытда берничә арбалар белән безләрнең багажларымызны китереп өйделәр. Үземез команда белән җәяү килдек. Шундан мунчага кудылар, исеме мунча булса да, күл буенда кечкенә бер өй эчендә берничә скамейкалар, эссе су биреп юындык. Өст-баш киемләремезне дизенфекциягә алдылар, ялангач рәвешдә чыкдык да, чыгу белән бөтен кешеләргә йитәрлек өст-баш, аяк киемләрен китереп өеп куйган иделәр, ап-пак күлмәк-ыштан, киемләр: гимнастерка, күн ботинка, бушлат (сукунный пинжәк), бүрек – барсын да бирделәр дә, юып куйган таза бер баракга кертделәр, көн батуда килеп идек, барак кергәндә көн яктырган иде, чөнки бу йирләрдә көн бик кыска буладыр. Шундан соң йоклап ял итдек. Торуымызга икмәк, бер килодан балык ашадык да, чәй эчеп беткәч, йортка чыгарып, пакетларны күреп, тәфтиш кылып, дохторга күренеп, категорияләр тәгаен кылдылар да, бик сәламәт яшьләрне дүртенче, уртарак кешеләрне өченче, авыррак, бүсерле булганлары икенче категориягә куйдылар. Төш йитде, аш-ботка, балык кеби порцияләремезне ашап, бу көн ял итдек. Өченче көндән башлап эшкә чыгардылар. Өч йөз адәм бар да йончу, бер ел төрмәдә,

11 көн юлда ачлы-туклы килгән адәмләр ашап туеп булмый. Мондагы кешеләр “болар ниндәй обжорный командамы әллә” дия абдырап сөйләшәләр иде.

Шундан бер кило ике йөз грамм арыш икмәге бирә башладылар. Балык күп, күпме ашасаң да, кухня янында мичкәсе белән тора иде. Монда эшләре шундый иде: сазлык, ташлык, карагай урман арасында станциядән 56 километр Финляндия границасына юл ясау иде. Казып, агачларны кисеп, юлларны тигезләмәк иде. Безнең эш – ат-арба белән ком-балчык ташу иде. Төяүче, бушатучы (алып барып бушатып), шундай соң бер ай эшләп, алгарак 19 нчы пунктына озатдылар. Бер генә барак, ул да начар, шунда бер күл аша күпер салалар икән. Ноябрь бәйрәме көнне эшдән кайтуымызга безләрне этабка чакыра башладылар. Безләр инде бу көн аш-су, яхшы ит дә булыр дип куанып кайтып идек, менә сиңа, “давай да давай” дип пастельләремезне җыярга тотындык. Габдрахман Айдабулов белән икәвемез, Дәминов белән Хәсәнов калдылар. Монда унъеллыкларны гына йибәрделәр. Хәсәнов борын ук киткән иде. Кайда баруымызны һичкем белмидер. Нәрсәләремезне чыгарып, бер йиргә өеп куйдылар да, үземезне җәяү йибәрделәр, багажларыңызны көймә белән алып барырлар, диделәр. Бер зур күл юлында идек. Үземез көн батканда чыгып китдек, 15 километр икән, борын торган пунктка барамыз икән. Төн урталарында надзорлар монда берәр сәгать ял итәмез, диделәр. Урман арасы, сазлык, ятырга урын юк, кайда агач төбе, кайда яткан бүрәнәләргә башымызны терәп йокладык. Яктыра башлагач, кузгалып китдек дә көн чыгуга барып йитдек. Килсәк, багажларымыз юк, көтәмез, кич булып бара. Бер вакыт хәбәр чыкды “көймә баткан” дия. Кич сәгать унберләрдә, көймә килде дип, халык шау итә башлады, йөгереп бардык, көймә килеп туктаган, бөтен нәрсәләремез суда, көймә эчендә йөзеп яталар иде. Алып, көчкә күтәреп, баракга кертдек, бөтен нәрсә су – мендәр, юрган, тун-пималар, азык, шикәр – булган нәрсәләр җебеп беткән иде. Шундан төн йокламый кояш чыкганга кадәре алып җиллэтеп, бераз гына корыды. Йокы юк, тамакга ашаганымыз юк. “Давай этапка!” дип акыра башладылар. Әле дә җүеш киемләремезне аркага асып, кулга бер–ике тозлы балык бирделәр дә, алып чыгып да китделәр. Алты километр борын төшкән станциямез (Ляухига) поездга утлтыртдылар да кайда баруымызны белмимез. Шул дәрәҗәдә кыйналдым, кулбашыма чобан[1] чыкган иде. Авыр нәрсәләрне күтәреп булмый, рәхмәт булсын, кайнагам Айдабулов ярдәм кылып күтәрешеп барды. Тозлы балык ашап, вагонда су юк, ни эшләргә белмимез, тәрәзәдән кар сорап алып ашадык, аны да бирмиләр, вагонлар суык, ноябрь

[1] Чобан – чуан.

аенда иде. Барып, Попов остров дигән, Беломор диңгезе буенда, шунда төшеп, агыр багажларымызны күтәреп, 3 километр баракга алып китделәр. Әйберләремне юлда ташлап китәргә мәҗбүр булдым, надзорлар: “Ал нәрсәләреңне, ал”, дия. “Не могу, минем кулбашым авырта, - дидем. - Ни теләсәңез, шуны эшләңез, җавап бирерсез”, - дидем. Шундан бер такталар каравылчысына калдырып китделәр. Барып баракга кердек. Эчәргә су да юк, булса да диңгез суы, тозлы, эчеп булмай. Кич булды, сәгать унларда иде. Бервакыт кемнең багажы калган дип кычкырдылар. Йөгереп чыкдым, минем нәрсәләрне ат белән китергәнләр, сәламәт алдым. Бу йирдә унике көн карантинда торамыз икән. Бондан файдаланып, юеш киемләремезне барын да кибдереп алдык. Ундүрт көндән соң янә безләрне этапка алып чыкдылар, кайда баруымызны белмимез, Беломор диңгезе буенда пароходка төяп озатдылар, кич сәгать бишләр иде. Халык күп, пароходның өстендә барамыз, шпана дигән мәхлуклар да күп иде. Пароходның өстенә төшделәр, чөнки анда товар-азык кебек нәрсәләр күп иде. Диңгез уртасына кереп китдек, төнлә булды, менә бервакыт җил, кар-буран чыгып китде, бер кыямәт булды, пароход өстендә җил бик көчле, халык бик кычкыра, бигрәк дә шпаналар, киемләре бик юка, безләр дә, тун-пималарымыз булса да, багажымызны чишмәдек, курыкдык, талап алырлар иде. Мин бик калтырый башладым, пароходның кайда баруын белмимез, тик буранда әйләнеп йөри бирә. Нишләргә инде, барам да матросларның бүлмәсен ачып керәм дә, “чава, старик” диләр, мин үтендем, мөмкин булса, аз гына елынып чыгар идем дия. “Ярар, елын да, безләр хәзер эшкә чыгамыз, син бонда каравыл булып торырсың, һичберәүне кертмә”, дия. Ул арада үзләре коймак пешерәләр иде, миңа бер-икене бирделәр һәм пешкән бәрәңге бирделәр, чәй дә эчдем, елындым, рәхәт, мунча кебек бүлмәдә бер бәйрәм. Тышдагы халык пароход өстендә тапанып йөриләр, мин монда оҗмахка кереп алдым. Ходага шөкер, дип ултыра идем, матрослар кайтып керделәр: “Ну, старик, все в порядке?” дип сорадылар да, “порядка”, дидем каршы. “Пароход адашкан, һич күреп булмай, буран-тулкын көчле, батып китмәсәк ярар иде” дип сөйләшә башладылар. Таң да якынлап калды, яктырмый көн чыкганда әйләнеп, кире Попов островка кайтдык. Пароход чыгардылар, тагын команда белән кичәге өч километр баракга алып китделәр, янә дә багаж алмадым. Надзорлар акырса да, мин авыр дия яр башына ташладым да китдем. Барып баракга кердек, әрле-бирле чәй эчеп тамакланып, йоклап ял итеп, вахта янына китдем, капка төбендә конторның өе алдында минем нәрсәләремне китереп куйган иделәр, сәламәт икән, күрдем дә баракга кайтдым. Бу көн йокладым да, иртәләп, янә этапка алып чыкдылар, вахта янына тезделәр, минем эш багажда. Рәтдән чыкдым да, надзорга: “Минем багажларым кайда, китереп

бирмәсәңез, мин китмим, теләсәңез, атыңыз”, - дидем. “Багажың табылыр, курыкма, әйдә, рәткә кер” - диделәр. Ярый, ышанып чыгып китдем, пароход янына барып туктадык. Мин һаман нәрсәләремне табдырам, беренче барып туктадык, беренче гудок булды, икенче булды, юк, “кайда нәрсәләрем?” дип, надзорлардан сорыйм, хәзер килә диләр, өченче гудок булды, безләрне пароходка кертделәр. Шул вакытда минем нәрсәләремне чанага салып китереп кертделәр, сәламәт алдым. Тышдан надзорлар: “Получил вещи?” дип сорадылар, “алдым”, дидем. Пароход кузгалып да китде, инде белдек, мондан алтмыш километр диңгез уртасында Соловки дигән утрау икән, биш сәгать юл имеш. Сәламәт барып җитдек, пароход якорь ташлады, чыгара башладылар, пристань тулы начальниклар һәм башка халыклар, чыкдык, каршымызга Хәсәнов ибдәш килеп күрешде. Мин, Айдабулов, икәүләп, бергә сау-сәламәт: “Син монда мени?” дибез, “сездән киткәндән бирле монда килеп, хәзер баракда каравыл булып торам, эшем яхшы”, - диде. “Ярый, хәзер без мунчага барамыз, безгә урын алып куй үз яныңдан” дибез. “Мөмкин булса, тырышырмын”, дип калды, безләр китдек. Мунча кереп, төн сәгать уникедә барып, Хәсәновның янына кердек. Барак Белозер карагайдан эшләнгән, якты, мичләре ягылып тора, биш кеше бар икән, яхшы гына урын куйган икән, рәхмәт. Йокладык. Иртә белән тордык, чәй-пай эчеп: “Я ибдәш, безләрне дә [...] инде”, - дидек. “Командирны күрдем, икәвеңезне дә дневаль итеп куярмыз”, диде. Ярый, дневальный булып бер көн тордык да, монда кычкыра башладылар этапка дип, шундук безләрне дә, барымызны да пастельләрне күтәреп чыкдык, өч кеше бар иде. Нәрсәләремезне тикшереп, безләрне озатдылар: Хәсәновны башка йиргә, без икәвемез 11 километр Соловкиның Муксалма дигән пунктына, йөкләремезне атка төяделәр, үземез җәяү көн батканда бардык, көн суык, бик озак тикшереп, безләрне землянка-баракга куйдылар. Бу исә карантин баракы икән. Чиләбе тирәсендән башкортлар да бик күп иде. Конашак авылы Сөләйман мулла Башкортстанның гали судында адвокат булып эшләгән. Деникиндан Ленинградны саклап калучы башкорт полкының командиры булып эшләгән Нуриәгъзәм Таһиров да бар иде. Бараклар бик эссе, кандала, бер дә йоклап булмый, бер көн кичке проверкага чыкганда суык тидереп, бик каты авырып калдым, 40 дәрәҗә эсселек булды. Шундук мине шифаханәгә алдылар, Айдабулов баракда калды. Шифаханәдә бер ай ятып, сәламәтлегемне алтынчы категориягә төшереп чыкардылар. Бу вакытда Айдабуловны кайтадан Кремльгә озатдылар – килгән йиремез, шулай итеп мин ялгыз калдым. Шифаханәдән чыкгач, яхшы агач баракга куйдылар. Барак зур, якты, йылы, өч урында мичләре бар, эшкә кушмыйлар, “сезләр инвалидсыңыз, сезләрне эшкә кушуга хакымыз юк” – начальниклар шулай җавап кайтаралар

иде. Өст-башка кышлык кием – пима, бияләй кебек нәрсәләрне бирделәр. Көненә дүрт йөз [грамм] кара икмәк, 13 грамм шикәр, дүртенче категориядән хисаплап, көненә өч мәртәбә эссе аш бирәләр иде. Баракда тик ята биреңез диделәр. Ятамыз, җәйләр йитте, аз гына икмәк күбрәк булыр иде дия конторада сторож булып керә алдым. Монда яхшы гына була башлады. Контор өемләре үзләренең аш карточкаларыны да, кайвакытда калган икмәкләрен дә бирәләр. Майга кадәр шулай яхшы гына торып идем. Бишенче майда янә этапка озатдылар. Кайда икәнен белмимез. Бардык Кремльгә, анда Айдабулов иде, безләрне кич мунчада йоклап, иртән кайдадыр алып китделәр. Иртән тордык, баракдан Айдабулов да килеп чыкды, ул да безнең белән бергә барачак иде. Китдек 20 километр кадәр Беломорның ярына барып туктадык. Биш километр кадәр диңгездән утрауга китдек. Бу вакытда диңгездә барак зурлыгында боз ага иде. Шул боз арасындан көймә белән үтеп, Анзер дигән пунктка бардык, бу йирдә зур чиркәүләр борын монастырь булган икән. Монда туктап, бераз поверка кылгандан соң, бераз кеше монда калды һәм Айдабулов да монда калды. Бөгелмә районы Габделбари Фәттахов дигән мулла да монда тора икән. Ярый, ә безләрне дүрт километр алга икенче Голгофа дигән пунктка озатдылар. Монда да чиркәүләр тау башында. Шул тау башындагы чиркәүгә безләрне куйдылар, бөтен Беломор диңгезендә пароходларның йөрүе күренеп тора иде. Киләм: безнең ибдәш Хәсәнов монда икән, очрашып күрешдек, ул шифаханәдә санитар булып эшли икән, син дә санитар булсаң, урын бар, гариза бир, диде. Шундук гариза бирдем дә, кабул итделәр, икәвемез шифаханәдә эшли башладык 1931 нче елның август башына кадәрле. Май айларында көн батса да, яктылык бетми иде. Төндә хат язып була иде утсыз. Моннан соң бу больницаны юк кылдылар да, безләрне мәркәз Кремль шифаханәсенә күчерделәр, бөтен авыруларны алып бардык. Мәркәз шифаханәсенә барып, анда эшли башладык. Шифаханә өч катлы крепость эчендә, дохторлар азәрбайҗанлы Җәүдәт әфәнде һәм башкалар иде. 12 сентябрьгә кадәр монда эшләп, соңра безләрне янәдән этапка чакырдылар. Кайда икәнен белмимез, шундан Россияга дип мыш-мышлар бар иде. Хәсәновны чакырсалар да, ул калды үзе теләп, анда канал эшләргә барыр хәл юк әле дип. Монда Русиянең мәшһүр адәмләрендән Бөгелмә Һади Атласов, шагыйрь Сәгыйд Сүнчәләй, Мәскәү имам Габделвәдүд Фәттахов, казакълардан юрист Әхмәд Байтурсуновлар бар иде һәм Солтангалиев Уфаныкы, алар калдылар. Безләр, пароходка ултырып, 800 кеше чыгып китдек. Әүвәлдә килеп киткән Попов островка килеп, андан поезд белән китделәр, Ким шәһәрен үтеп, Шавин дигән стансага дүртенче отделениегә карый Майгубә дигән йирдә килеп төшдек. Бер генә барак, сазлык, карагай, урман арасы, шунда тукталдык.

***Соловкидан Беломорга...***

Аз-маз кешеләр бар иде, мунча ясый башладык, кечкенә кухнясы бар икән, башка нәрсә юк иде. Бер-ике көндән соң этап килә башлады. Россиядән бу көн килү өстендә бер көнне этапда авылдашымыз Гыйззетдин Габдулла углы, Сәгыйдулла Сәйфулла углы Айдәрәле авылының мөәзинен каршылап алдык, бик куандык, туганларымыз килгән кебек булды, “хуш, ни эшкә йибәрделәр?”, дидек. “Без Сызраньдә эшли идек. Монда канал ясарга дип йибәрделәр, әйтделәр, шунда бардык”. Безләр дә монда каналга килүемезне, 1931 нче елның ноябрь 12сендә Беломор каналны эшли башладык, сазлык, карагай урманны кисеп, күпер салып, канал эшли торган йиргә кадәрле юл ясадык, шундан канал казый башладылар. Безләр карт, икенче категория булу сәбәпле, йиңел эшдә булды, кухняга утын кисү вә башкалар, егермеләп кеше бер бригад булып йөредек. Гяпун дигән украинлы иде бригадир. 1932 нче елга кадәрле шушы Майгубә бүлеге Шавин стансасында Беломор каналының башындан башлап эшләдек, сигез мең кадәрле мәхбүсләр булып, смена белән көнен-төнен эшләдек. Безләр, Ходага шөкер, йиңел эшләрдә генә йөредек, түкәгән комларны тигезләп, тиешле урынларны тазартып, себереп, шундай эшләрдә булдык. Шушы елның ноябрь аена кадәрле каналның йир эшләре тәмам булды һәм эш вакытында ике көнгә бер көн бирделәр. Андан канал бетү мөнәсәбәте белән, эшенә карап, яңадан бер ел бирделәр. Бу көнләрне баракларга кычкырып чакырып йөриләр, кемләр дохторлар комиссиясендә гариза бирсәләр, фәлән баракга барсын дия. Минем гаризам булмаса да, Айдабуловка әйтдем: “Әйдә, без дә барыйк комиссиягә” дидем дә, тәвәкәлләп бардык, күрендек, яздылар, бер нәрсә дә әйтмәделәр. 33 нче елның февраль айларында бик суык көн иде. Еракга барып, бүрәнә кисеп кайтып, бик арып йоклаган идек. Төн урталарында “Кадыйров бармы?” дия кычкырып чакырдылар. “Тиз бул, ирекгә китәсең”, - диделәр, Айдабулов белән янәшә йоклап ята идек. Абдырап китдек, ул калды. Мин төнлә сәгать беренчедә чыгып китдем. Чыксам, капка төбендә 25 кеше багажлары белән туктаганлар һәм йөкләрен чанага төяп ята иделәр. Аларны көндез үк чакырганлар, мине бараклардан таба алмый йөргәнләр икән. Сәламәт чыгып китдек, үземез җәяү хәлендә, төн бик суык иде, 15 километр Майгубә дигән пунктка бардык йитдек. Монда 15 көн карантин саклана имеш. Шундук карантинный баракга кертделәр. Монда унбиш көн торып, безләргә екерме биш кешегә ихтыяри сөргенгә китәргә, берәүләр Мәләкәскә, берәүләр Пугачевка, безләрне Вятка губернасында Котлас дигән шәһәргә – Двина суы буенда – шунда барырга кушдылар. Димәк, безнең иреккә чыгуымыз шушы булды. Безләрне калган биш елымызны шушында торырга тиешлемез икән. Кулымызга ГПУ тарафындан язылган документны бирделәр. 4440 номерлы

язылган. Шулай ун елга сәяси маддә 58 белән кулга алынган Кадыйров ГПУның коллегиясе каравы буенча (согласно карары белән) калган вәгъдәсене бәйләнмеш йирдә тәмамларга дия. Юлымызга азык, буш поезд билеты биреп, каравылсыз поездга ултырып юнәлдек. 8 нче март көненә Котласка барып төшеп, нәрсәләремезне камерахранениягә тапшырып, милиция идарәсенә регистрировать  ителдек. Көн бик суык, 50 градус, кунарга урын табып булмый, кич булды. Бик кыйбатчылык, кара икмәкнең килосы 10 сум, сөт ярты литр 5 сум. Бездәй мәхбүсләр ачлыкдан, суыкдан урамларда үлүчеләр бар иде. Кайда кунарга? Милициягә барсак, монда фатир юк, анда бер километр булыр, шунда бер безпризорлар, шпаналар яталар, шунда барып кунмасаңыз, башка йирдә урын булмас дип әйтде. Анда кунсаң, ике йөз грамм икмәк дә бирәләр диде. Шунда китдек, барып кердек, зур бер барак, күз күрми, эче төтен, почмакда гына бер сукыр лампа янып тора иде. Сәке кырында ултырып кына йокламый чыкдык да, иртә булгач, тиешле ике йөз грамм икмәкне алдык да чыгып китдек. Милициягә барып, “безләрне кайда йибәрәсез?”, дип сорадык. “Никольский районына барып мәгълүм булырсыз, анда әйтерләр кайда торырга” диләр. “Алайса, безгә кәгазь биреңез, юлда квартирга керергә дип, һәм, сельсоветкә язып, боларга квартир бирелсен кунып китәргә” дибез. Кулымызга кәгазьне алып чыкдык да, ибдәшләр белән җыелып шаулашдык бу көн китәмез дия. Һәрбер кеше, нәрсәләре күп булганлар, тактадан кадаклап бәләкәй чана ясап алдык. Шадрин өязе Конашак авылының мулласы Вафа Сөләйманов белән икәвемез бер чанага төяп, бергә тартып, Двина суындан боз өстендән чыгып китдек, я Аллаһ, хәерле сәфәр дия. Шундан олуг Архангел юлына төшеп китдек. Егерме биш кеше бергә. Юл буенда зур-зур рус авыллары. Кич булса, сельсоветкә барып әйтеп, фатир сорап аламыз, шулай да суыкда урамга бер-ике сәгать торырга тугры килә, һәр өйгә бүлеп тараталар иде. Шулай итеп, берничә көнләр чана тартып бардык, безнең бара торган Никольский дигән йирне һичкем белми, абдырадык. Бер авылда милиция идарәсенә кереп сорадык: “Безләр барган йиремезне белмимез, сез белеп, безләрне юлга салсаңыз”. Начальник торып, картаны карап: “Сезләр яңгылыш кирегә киткәнсез”, - диде. Хәзер юлыңыздан кире кайтып, андан юлларда сорашып, бара торган урыныңызны табарсыз дия. Безләр борылдык да әйләнеп кайтдык. Котлас каласының каршысында бер зур урыс авылы бар, килеп шунда кундык, иртәләп торып, бер урынга җыелышып, бер мәслихәт кылмышдык, я, нишлибез, барамызмы шул урынга, булмаса, кире Котласка кайтып, без сезләрнең йибәргән урынны тапмадык, нишләргә. “Икенче йиргә йибәрәмен”, - диде. Кулымызга кәгазь  алып идек. Урамда бер баракда торган рабочийларның бригадиры икән. Барак мондан ике километр, бездә эш бар,

алырмыз дип, безне чакырды, ибдәш белән сөйләшеп барырга булдык, янәдән милициягә кереп әйтдек, безләр монда калабыз инде дип, ярар, диде. Шундук күтәрелеп, баракга бардык. Берничә көндән соң безләргә эш бирделәр, шпал кисәргә. Норманы тултырсак, икемезгә 500 грамм икмәк, тулмаса, икемезгә 400 грамм столовайда сатып алырга талон бирәләр, башка юк. Шулай итеп, эшләп карадык, норманы тутырып булмый, һәр көн икәвемезгә 400 икмәк эшлимез, ул норманы да биш көндән соң бирәләр, биш көн ничек торырга кирәк. Акчага алырга 10 сум килосы, акча да юк. Киемләрне сата башладым, йиде кадак җон баскан пимамны биш йөз грамм икмәккә бирдем, яхшы күн чемоданым бар иде, заграничный, аны һәм биш икмәккә бирдем. Шулай итеп, артык нәрсәне барын да сатып ашап бетдем. Хәлсезләнеп эшдән калдым, аяк, битләр шешеп китде. Хәл мөшкелгә калды. Әҗәлем шушында икән дип уйлап ятдым. Аллаһның рәхмәтендә булсын, җәмәгатем Фатыйма, үзләренә булмаса да, барын табып, бер посылка салды, бераз акча, азрак май, токмач, сухари, он – шуның белән беразга сузылдым. Бу да бетде, янә бер посылка алдым, бу һәм тәмам булды. Бу вакыт утыз өченче ел май айларында иде. Үләнләр чыкды, Вятка тугаенда көпшә, кымызлык, кузгалак җыеп кайтам да, тоз салам, пешерергә урын юк, мунчага барып кына пешерәм, шуны ашыйм да, тирләп рәхәтләнеп ятам. Кай вакытда җитен орлыгы алам, бер стаканы 1 сум. Шуны кыздырып, төеп, ашка салам, көндән-көн хәл бетә иде, хәтта хаҗәтемә үрмәләп бара торган булып калдым. Бит шеш, аяк шеш, нәрсәне сатып бетдем, тик өйдән чыкган бер туным калды, яхшы бәрән эчле иде. Ибдәшләр әйтәләр: "Син бит үләсең, авылларга чыгып китәргә кирәк, аз-маз ризык бирерләр, шулай итеп сәламәтлекне коткарып калырсың", - диделәр. Ә минем авылга барырлык хәлем юк иде. Хода бер ярдәм бирсә, ни булса да, авылга китәр идем дидем. Инде үлүдән башка эш калмады. Минем белән бергә килгән юлдашым Сөләйманов ял көнне Котлас базарына китеп иде. Кайтканда юлда үлеп калган, бер чокыр эчендә үлгән, барып табып, милициягә барып мәгълүм кылдым. Берничә көн яткан соң, кайдадыр алып китеп күмсәләр кирәк. Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин. Күб дә көн үтмәде, дохторлар комиссияне чакырдылар. Барып күрендем, списокка яздылар бик күп процентны югалткан дия, мине акт кылалар дип аңладым. Шундан сорадым, бу комиссиянең результаты кайчан булыр икән дия. "Мәгълүм түгел, бәлки иртәгә, бәлки өч айдан, без дөрестне әйтә алмыймыз", - диделәр. Минем иң агыр көнләрем иде бу көнләр, боларның җавапны көтсәм, үлеп калырмын, булмаса, Ходага тапшырып, тунны сатыйм да, поезд белән кайда булса да китәрмен дип уйладым, үлсәм, юлда үлеп калырмын, бәлки Хода бер ярдәм бирер дия кайтдым да тунны сатдым 45 сумга, иртүк аркага капчыкны асдым да китдем Котласка, безгә

ике километр йир ди, бардым да ярты литр сөт алдым, ярым кило икмәк, тамакны азрак туйдырдым да, китдем стансага. Тәвәккәле Ходa, кассадан бер биш стансалык йиргә билет алдым, 5 сум түләдем. Инде озакламый поезд китәчәк, ләкин поездга кергәндә ГПУның кешеләре карап торалар, бездәй кешеләр китәлми дия. Я, Ходай, поезд килде, посадка була башлады. Мин дә, я Аллаһ, дия күпчелек хохол марҗалары арасына ышыкланып пездга кердем дә, ишек башына гына юкары менеп сузылып ятдым.

***Котласдан сәфәр.***

Утын куярга полканың бер читендә аз гына решетка да бар иде. Мин дә хәят белән үлем хәлендә ятам, я Ходай дип, күрмәделәр, үтеп китделәр. Шундан билет алган стансага көн батуга барып йитдем, тыныч кына килгән вакытымда күрим әле дип стансага төшдем. Әгәр дә төшмәгән булсам, иртәләп Вятка шәһәренә барып йитә идем. Төшүем белән килде дә, туктады да, документ сорый башлады. Ярый Беломорканалындан алган документны Котласда вакыт милициядән башка йиргә китдем дип сорап алган идем. Күрсәтдем, ышанмады, поезддан алып калды да, стансага алып китеп, бер урынга куйды: “Мин килгәнче шунда тор”, - диде. Бераз көтеп тордым да бер ярты сәгать кадәрле, килеп йитде, ә мине кызыл вагонлар арасында бер юл буена туктатды да, янә минем янга ун кеше алып килде. Алар да минем кебек кешеләр икән. Шундан ГПУның вәкиле уполномочие килде, документга карап сорады, ник качдың дип. “Мин, - дидем, - качканым юк, документ кулыңызда бит”, - дидем. “Юк, андагы, я мондан, Котласдан, документ юк бит”, - диде. Мин әйтдем, менә мин икенче урынга барып эшләргә дип киләм, үзем хәлсезләндем, анда минем эшләр бик авыр иде, йиңелрәк эшкә барамын, дидем. Шундан соң минем  документны кулыма бирде дә, теге ун кешене вагонга кертде. Мин калдым, кит дигән кеше дә юк, тор дигән кеше дә юк, карап тордым, бәлки мине калдыргандыр дип, акрын-акрын гына вагонлар арасына кереп китдем. Бардым вокзалга, кердем, төн баткан вакыт иде. Бу июнь айлары, төннең бик кыска вакыты иде. Вокзалда кеше юк, берүзем йокламый утырып чыкдым. Иртә булды, кешеләр җыела башлады. Бер комсомол килде дә, мине милициягә алып китде. Барып начальникка әйткәч, начальник,”пускай, ул тикшерелгән” дип, мине йибәрде. Кайтдым вокзалга, документ кулымда, утыз сум кадәр акчам бар янымда, тотам да 19 сум биреп, Вяткага билет алдым, калган акчама икмәк алдым да, поезд көн батуга килә иде. Монда көненә бер генә йөридер, вакыты йитде, поездга чыкдым да, поезд каршылап, кич мине тоткан милиция күрде дә, “бабай, китәсеңмени” диде, “китәм шул, йибәрдеңез бит”, дидем. “Әйдә, валяй”, - диде дә, мин, “Я Аллаһ” дип, Вяткага карап юл тотдым, тәвәккел, киләчәкне бер Ходa беләдер. Иртәсе көн иртәләп Вяткага килеп йитдем, станса алдына чыкдым

да, карасам, бөтен юлчылар тышда яталар иде. Минем бу вакытда бер ашарлык икмәк дә, бер тиен акча да юк иде. Кайда кешеләр ашап ултырсалар, шулар алдына барып, "аз гына икмәк бирегез" дип сорап, аз-маз йөрәк ялгадым. Базар озакмы дия сорадым. Анча озак түгел диделәр. Бер күлмәгем бар иде, кожаный, шуны алып базарга китдем. Барып кердем дә ун сумга сатдым, аз гына икмәк, катык алып ашадым. Ходага шөкер, шулай базар арасында йөрегәндә бер мөселман картны очратып, сәлам биреп сорашдым. Бу Бөгелмә өязендән икән. "Бабай, монда мәсҗед бармы?" дим. Диде: "Бар, күбдән түгел булган идем, мулласы Уфа өязендән килгән икән". "Мөмкин булмасмы миңа мәсҗедне күрсәтергә?" "Мөмкин", - диде, шундан мине алып китде, берничә кварталлар үткәч: "Менә, кардәшем, шушы урам белән тугры уң ягы белән бар, шунда мәсҗед алдына барып чыгарсың, ике этажлы, манарасы юк, кызыл кирпечдән салынган, мулласы мәсҗеднең үзендә тора", - диде. "Ярый, рәхмәт, бабай", дип озатып, аерылып китдем. Мәсҗеднең алдына туктап тора идем, берәү ике кулына су күтәреп кайтып килә, карасам, үземнең Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә бер мәдрәсәдә, күрше бүлмәдә ничә ел бергә торган ибдәшем Әхмәдсәүбән иде. Ул мине танымый торды да, бераз соң танышып: "Әйдә, рәхим итегез" дия, мине алып керде. "Хуш, хәлләр ничек? - дип сораша башлады. "Ярый, соңындан сөйләрмен, - дидем дә, - әүвәл сездән бер илтимасым[1] бар: мөмкинме сездә беравык торырга?" "Мөмкин, тормыш заманача, барын ашармыз, рәхим итегез, дия, юкны гаеп итмәссез", - диде. "Ярый, рәхмәт, минем вокзалда аз гына иске-москы киемләрем белән капчыгым калган иде, шуны барып алып килим", - дидем. "Ярый", - диде. Шундан барып алып кайтдым, чәй хәзерләде, әхвәлне сөйләдем. "Шулай бервакыт Казандан мулла да килеп чыкган иде. Кадәре халь ярдәм кылып йибәргән идем. Ул вакытда халык бар иде. Байлар да азрак бар иде. Хәзер кеше бик аз калды. Кадәре халь[2] тырышып карармын", - диде. Бичара, алты баласы бар, үзе чемодан ясап, абыстае базарда йөреп, көнлек ризык табалар иде. Хәле боның да бик авыр иде. Шулай булса, кара йөз күрсәтмәде, Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин. Инде тамак туярлык аш юк, тик җан саклардык гына иде. Мин булса, бик ахыр дәрәҗәдә йончып килгәнмен, базарга чыгам, бар кешеләрдән азрак сорыйм, кайсы катык, кайсы бер кабым икмәк бирәләр иде. Икмәк сата торган магазин алдына да барып тордым, бәгъзе берәүләре, кисәк булса да, биреп китәрләр иде. Әхмәд әфәнде кайта да: "Ибдәш, бер дә эш чыгарып булмый", - диде. Бу Әхмәд әфәнде Вятканың районный имамы һәм мөхтәсиб иде, карамагында күп мәсҗедләр бар иде. "Үзегез беләсез, бер юл бар, әгәр дә барсаңыз, мондан 45 километр. Минем

---

[1] Илтимасым – үтенечем.

[2] Кадәре халь –көч җиткәнчә.

карамагымда Нократ дигән бер авыл бар, борын бик бай авыл иде. Алты мәсҗедләре бар. Барырга уйласаңыз, менә үземдән муллаларына хат язып бирәмен сезнең хакда, мөмкин булса, мәхәлләңездән ярдәм кылдырыңыз, - дия. - Әлбәттә, анда да халык хәзер көндә йончу булса кирәк. Шулай да буш илтмәсләр", - диде. "Ярый, яз", - дидем. Шул көндүк сәфәр итдем. Вятка суны паром белән үтеп китдем, җәяүләп комлык йөрүгә авыр, үзем дә хәлсезмен. Тугай да бер километр булыр, акрын гына атлап барам. Юл буенда яшь кенә рус егете икмәк ашап утыра иде, янына барып исәнләшдем дә: "Мөмкин юлчы картка аз гына икмәк сындырып бирсәңез икән", - дидем. "Рәхим итеңез" дип, бер сынык икмәкгә май да ягып бирде, күземдән яшьләр килеп калды, бик мәмнүн булып, рәхмәт укып, юлыма юнәлдем. Шулай да, инша Аллаһ, сәфәрем хәерле булыр, беренче сәфәрдә үк 2 икмәк белән май агызыма тиде дип, хәерле фал кылдым. Барып, олуг шоссе юлына чыкдым, ике тарафы карагай урман иде, чакрым баганалы, акрын гына атлап барам. Зур-зур гына рус авылларындан үтәм, урам буенча руслардан икмәк сорыйм, рәхмәт, кайулары катык, кайулары куас, бәрәңге кебек нәрсәләр бирә иделәр.

***Вяткадан Нократка сәфәр.***

Кич якынаеп калды. Алда бер зур гына рус авылы күренә. Көн батуга барып йитсәм, фатир табып, бәлки шунда кунармын, булмаса, юл буенда урман арасында йокларммын дип киләм. Июнь айлары, төн бик кыска вакыт иде. Төн батуга авылга йитдем. Авыл бик зур, ләкин бер дә фатирга кертмиләр, карчык марҗалар чарылдап торалар. Печән вакыты булу сәбәпле, яшьләре бар да еракга тугайга киткәнләр, шунда кунып ятып печән хәзерлиләр. Мин бик йончу рәвешдәмен, кеше куркырлык йөрим, урам буена кертмиләр, шундан берәү әйтде: "Анда колхоз идарәсе бар, шунда кундырырлар", - дия. Барып табып, документны күрсәтеп, кунарга рөхсәт итделәр. Янә минем кебек бер карт поп да бар иде. Икәвемез йоклап, иртән торып, документларымыз алып чыгып китдек. Ул бер якга, мин бүтән якга. Бара торгач, янә бик зур авыл күренә иде. Ерак түгел, барып йитдем, бонда мөселманлар күренә башлады һәм магазинларда мөселманлар эшли икән. Бу бер зур күн заводы Вахрушев исемендә, рабочийның күп йире икән. Магазинга кереп, кешеләре мөселман булу сәбәпле, бераз хәлемне сөйләргә мәҗбүр булдым. Һәркайусы бер һәм ике сум ярдәм кылдылар: "Инде мосафир бабай, монда өйләргә барып йөре, монда ага-эне күп, аз булса да ярдәм кылырлар", - диделәр. Дөрест, һәркайусы тамакны туйдырып, яхшы ашлар, катык, сөт ашатып чыгара иделәр. Кич була башлады, инде кайда йокларммын дип уйлап, бер кеше белән сөйләшдем: "Бабай, гаеп итмәңез, монда кунуыңыз кыен булыр, казенный йортда туры бар да, партийный халыклар, шул сәбәпле фатир таба алмассың, - диде. - Алдыңызда өч кенә

чакрым бер рус авылы бар, шунда ике йорт татарлар тора, бик [яхшы] кешеләр, син шунда бар, сине кундырырлар һәм ашатырлар”, - диде. Ярый, дидем дә чыгып китдем. Барып йитдем, бу кешеләрне эзләп табдым. Берсенә кереп рөхсәт сорадым, бер яшь кенә хатын икән иде. “Кер, бабай”, дип, кердем, хәлемне сөйләдем. Бичара хатын кычкырып еглап да йибәрде “минем дә атам шулай йөридер инде” дия. Тамак ашатды, 5 сум сәдака бирде: “Бабай, гафу идәсез, бездә кунуга булмый, сәбәбе исә – без фатирда торамыз, хуҗа белән шартнамәмез бар башка кеше кундырмагыз, дия. Мондагы руслар чит кешеләрдән куркар имеш. Бигрәк дә бездәйләрдән, бәгъзе шундай кешеләр зарар кылып китсәләр кирәк. Бабай, ерак түгел, анавы йортда бер ага-эне кеше бар, сез инде шуңа барыңыз, - диде. - Әгәр дә ул да кундырмаса, кайтып килерсең, берәр чара кылырмын”, - диде. Бардым, тәрәзәсе ачык, чәй янына бик яхшы чәлпәк пешереп куйган. Мин, беләсез, ач кеше, бердән, тансык аш булу өчен яхшы гына ашадым, әхвәлемне сөйләдем, мөмкин булса, бу көн сездә кунсам икән, дидем. “Мосафир, бу бик бу йирдә авыр мәсьәлә инде, фатир хуҗасы бер карчык марҗа икән, ул бездә кеше кундырырга кушмый. Шулай булса да бер чара табармын, яхшы, кунарсың”, дия безне шадландырды, Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин. Икенче көн торып чәй эчдек.

***Нократка сәфәр.***

“Безгә рөхсәт биреңез”, - дидем. “Кайдан барасыз?” “Нократга, русча Карино” диләр. “Алайса, мондан Никольский каласына барырсыз, мондан фәлән сәгать поезд китә, билет хакы 90 тиен генә тора”, диде һәм акча да бирде. “Анда безнең таныш кешемез бар, шунда керерсең”, - диде. “Мөмкин булса, сез бер кәгазь язып бирсәңез, ул кешегә минем өчен барып керү йиңел булыр иде”, - дидем. Ярый, дип, хат язып бирде. Никольскийга җитдек, теге кешене эзләп табдым. Хуҗа өйдә юк икән, хатыны гына икән, рәхмәт, сорадым, кертде, хатны бирдем, шундук ашарга китерде, калган яхшы ит шурпасы, күмәч куйды. Шулай итеп тамак ашап, күршеләрендә дә мөселманлар икән, алар да килеп шаулашып ултырдылар. Йокладык, иртәләп торып, юлга чыкдым. 15 километр юлым калган, зур юлга төшдем, колхозлар буш ат-арба белән кайталар, мин бара торган йиргә берсе дә ултыртмайлар. Алар монда печән ташыйлар икән. Мөселманлардан шундай кешеләр дә бар икән дия җәяү хәлемдә барып йитдем. Әсхәд әфәнде Сәүбән әйткән Касыймов дигән муллага бардым, хатны бирдем, “Хуш килдеңез, рәхим итеңез”, дип алып өенә кертде, исән-саулыкдан соң әхвәлемез кыскача гына сөйләп бирдем. “Яхшы, мосафир, сез юыныңыз да ял итеңез”, - диде. Шул вакыт бер бала йөгереп килеп, хәзрәтне ашка чакырды. “Ярый, барырмын”, дип йибәрде дә, миңа әйтде: “Бу фәкыйрь кеше, ашка сорый, нә хәлдәдер,

шуның белән сезне бердән алып барырга тугры килмәй, баргач, хәлне күреп, сезгә баланы яңадан йибәрермен”, - дип китде. Бала килеп дә йитде, “әйдә, бабай, безгә”, дип, ярый, киендем, китдем, барсам, фәкыйрь булса да, бичара адәм, бик яхшы аш хәзерләгән. Борынгы байлар ашы кебек, минем бу ашны күрүем беренче мәртәбә булды, кунак булып кайтдык. Хәзрәт юлда миңа әйтә иде, иншааллаһ, сәфәреңез уңар, сәбәбе исә – бу ашны мин бу елларда бер кешедә дә күрмәдем. Бу көн монда күрүем бу сезләргә һәм насыйп булды. Бу көн шулай үтде. Мин дә бик кәефләнеп китдем, бу ашларны күреп ашавыма, әлхәмдүлилләһ, иртәсе көн тиешле хатларны башка муллаларга тапшырып, танышып кайтуга китдек. Барып, һәр кайусыны күреп, Вятка имамының сәламен сөйләп һәм үзенең килү максадын сөйләп, чәйләр эчеп ултырдык. “Ярый, бер 15 көнләр торырсыз, кулдан килгән ярдәмне кылып, җомга халыкга әйтермен, үзеңез дә килерсез”, - диде. Ике мәсҗеддә берәр җомга укыдым, 15 көн булды. Моның арасында күрше хатынлар, әбиләр муллага май, күкәй, җиләк кебек нәрсәләр кертә иделәр һәм миңа икмәк һәм шундай ашарлык нәрсәләр кертер иделәр. Бабай дога кылсын дип, аз-маз керә башлады. Тамак да туя башлады. Ходага шөкер. Китәсе көндә мәхәллә исемендән мөтәвәллиләр килеп, алтмыш сум акча тапшырып, ярдәм итеп китделәр. Бераз күршеләр фәлән йиргә икмәкне сатып да биш-ун сум җыйдым, барына разый булып, кире Вяткага Әхмәд Сәүбән ибдәшкә кайтырга булдым. Минем әҗәлдән калуым шушы Нократ авылы сәбәп булды. Миңа ярдәм кылган бәндәләрнең Хода гөнаһларыны ярлыкасын, амин. Аллаһ иманларны юлдаш итсен. Сәламәт булганларына хәерле гомер биреп, хөсне хатимә насыйп итсен, амин. Сәламәт әйләнеп Вяткага кайтдым. “Эшләр ни хәлдә, ибдәш, сәламәт кайтдыңызмы” дип, Әхмәд әфәнде исәнләшеп, “Ходага шөкер, сәламәт кайтуыңызга бик шад булдым, сездән соң җәмәгатемез ул кешене ялгыз йибәрдең, үзең алып бармадың, хәле бик зәгыйфь бит, юлда калмаса ярар иде дип, мине бик хафага салды. Шул сәбәпле, сезләрнең сәламәт кайтуыңызны дүрт күз белән көтә идем. Азрак ярдәм булырмы?” - дип сорады, “Аллаһга шөкер, юллык хәреҗ табдым”, - дидем. Бик яхшы булган икән, - диде. Бер-ике көн торып, базардан бер ун кадаклы бер икмәк алдым егерме сумга, Уфага поездга 49 сумга билет алып, андан икенче көн поездга ултырып, Пермь шәһәренә юнәлдем.

***Пермь шәһәренә сәфәр, Пермьдә булуым.***

Юлыма бербөтен арыш икмәге алдым, башка бер нәрсә юк: билетым бар, шушы икмәкем бар, икенче көнгә иртәләп Пермьгә йитешле тиешлемез. Төнлә поездда икмәкне баш астыма куеп йокладым. Иртән торсам, икмәкдән йилләр искән, ярый, хәерле булсын, дидек. Инде акча да юк, икмәк дә юк. Уфага йитәргә ике көнлек юл бар. Пермьгә килеп төшдем, монда пересадка

булса, Уфага төнлә сәгать уникедә китәчәкдер. Көн буе стансада көтәргә тугры килде. Корсак ач, нишләргә кирәк, вокзал алдында тапанып йөрим, бер татар ага-эне килеп чыкды. Сәлам бирдем, күрешдем. Бераз сөйләшеп үткәч, бу кешедән сорадым: "Сез белмисезме, монда Закирҗан Рәхмәтуллин дигән кешене, аның атасы монда зур сәүдәгәр булган", - дидем. "Беләмен", - диде. "Мөмкин булса, миңа адресны әйтсәңез икән", - дидем. "Дөрест, йорт номерны белмим, шулай да, тәхминән[1], әйтүгә мөмкин, Ленин урамы белән трамвайга ултырып, икенче туктауга төш дә, шунда фәлән рәвешле йорт булыр, шул йортка керсәң, йорт эчендә бәләкәй генә өе булыр, ул шунда тора", - диде. Барып тапдым. Бу Рәхмәтуллин егерме яшьләрендә иде, минем вакытымда Буби Габдулла Нигъмәтуллинлар белән хаҗга барган иде. Шунда мин аның белән танышып, бергә йөреп адресны алып идем. Тукыз йөз җиденче елда булса кирәк. Шул кешенең адресы хәтеремдә бар икән. Шул сәбәпле, барып күрешергә теләдем. Табып күрешеп, мине танымады, мин азрак төсмерләдем. Арада егерме биш ел үткән иде. Сачләре агарып киткән, ниһаять, танышдык: "Гафу ит, минем сезгә килүемнең сәбәбе шушы – мин тоткындан кайтып килә идем, менә Уфага билетым бар, мәгаттәәссеф, төнендә поездга юллык икмәкемне угырладылар, янымда билетдан башка бер нәрсә дә юк, мөмкин булса, безгә Уфага йитәрлек ризыклык ярдәм итсәңез икән, - дидем. - Әйдәңез, өйгә кереңез", - диде. Алып керде. Керсәм, өендә ап-ак сакаллы бер карт атасы, күзлек кигән, Коръән укып ултыра иде. Күрешдек, чәй хәзерләде, дөгедән пешергән бәлеш дә бар икән, аш куйды, яхшы чәй. Минем өчен бу көнне бу беренче ашым хисаплана иде. Инде рәхмәт укып, рөхсәт сорадым, бер икмәк гәзитәгә төреп, 10 сум акча бирде, Аллаһның рәхмәтендә булсыннлар, шулай итеп, Пермьдән Уфага Бирдәш аша икенче көн батарда килеп төшдем, барыргга абдырап тордым, өченче мәхәллә борынгы имам булып торган Хәбир Хәсәнов йортына бардым, караңгы төшкән иде, бер кеше вафат абыстай йортын сатып, кайдадыр икенче йиргә күчкән, монда торучылардан "сездә кунарга мөмкин булмасмы" дип сорадым. "Мөмкин түгел, бездә фатирда торучылар күп", - дип җавап бирделәр. "Абыстай кайда тора?", дип сорадым, "фәлән урамда тора" диделәр, баруга ерак булды. Күршедә мәсҗед бар икән. "Мәсҗеддә кем тора?", - дидем. "Фәрраш тора, башка кеше юк", - диделәр дә, мәсҗедкә барып, фәррашдан сорадым: "Мәсҗеддә кунып чыгу мөмкин булмасмы?" - дия. "Юк, бу кеше кундыра торган йорт түгел", - дип җавап бирде. "Мин, - дидем, - бу халык һәм Аллаһ йорты, монда намаз да укырга, мәҗбүр булган мөсафирлар да кунарга мөмкин" диюемә каршы, "сездәй берәү кунып,

---

[1] Тәхминән – якынча.

пычратып чыгып киткән иде, булмас” дип җавапка каршы, “юк, фәрраш әфәнде, мин кунам, ни кылсаң да кыл”, дидем дә, кердем дә кундым. Иртән торып базарга чыкдым да аз гына тамак ашадым. Шундан соң үзем шәрик һәм авылдашым Габделхәмид Әхмәров дигән ибдәшем эзләп китдем. Аның монда центральный китапханәгә мөдир булып торганындан хәбәрем бар иде. Барып табдым, әхвәлне сөйләдем: “Ярый, Мәҗид ибдәш, мин эшкә килеп башладым, сәгать дүртдә кайтам, рәхим итеңез”, - дия адресны бирде дә, мин чыгып китдем. Юлда үзем туенда булып катышып, йортыма чакырып кунак итеп бергә йөргән танышым Гани Хәлфин дигән ибдәш очрап калды. Бу авылымызда вакытда Габдеррәхим Лотфулла углы Тукаев дигән якын кешеләремездән кәримәсе Маһисорурны алып иде. Шул сәбәпле, башындан ахырына кадәр бөтен туйларын үткәреп, ничә мәртәбә Эстәрлетамакдан атыма ултырып алып кайткан идем һәм башка вакытларда да күп булдык. Ул бу көндә Башкортстан гали судында әгъза иде. Ярый, сәлам бирдем, әхвәлне сөйләдем: “Бер дә хәрежемез юк, мөмкин булса, азрак ярдәм бирсәңез икән”, диюемә каршы, “юк, сезләргә бездән ярдәм юк” диде дә, борылып китде. Менә дөньяда мохтаҗ хәлгә төшеп калсаң, дусларың да шулай итәләр икән, кешегә яхшылык кылган булсаң, яманлык көт, димешләр. Бу көн җомга көн икән, үзем йоклаган мәсҗедкә җомгага барырга уйладым, кайтып юынып, җомга намазына керәм, бонда килеп, Уфа мөфтисе Мотыйгулла Гатай җомга укый икән. Мәгълүмеңез: үзем бик түбән хәлдә, хибесдән кайткан кешенең хәле мәгълүм, башымда иске кепка, өстемдә алама кожан. Шул хәлдә булсам, җомгадан соң Кәлямулла укыдым, дога кылдык, тәмам булды. Җәмәгать чыга башлады, мөфтисе исә ахырга калды, барып күрешдем, сез кайдан дия сорап: “Мин Эстәрлебаш Мәҗид дигән кеше булам”, дидем. “Әллә сез Мәҗид карыймы?” - диде. “Шулай, - дидем, - тавышыңыздан бер ишеткән кешенең укуы дип уйладым”, - дидем. “Нәма, нишләп бу хәлдәсез?” дия сорап, кыска гына хәлне сөйләдем. “Ник җомгадан әүвәл әйтмәдеңез, мин сезгә халыкга әйтеп, аз вак ярдәм кылган булыр идем”, - диде. “Рәхмәт, хәзрәт, бу йиргә кайтып йиткәч, мондай ярдәм сорап сезгә мөрәҗәгать итүгә вөжданым кабул итмәде”, - дидем. Шулай да булса, әлеге мине кундырырга кертмәгән фәррашка әйтде: “Бу кешегә мәсҗед акчасындан биш сум бир”, - диде дә, исәнләшеп чыгып китде, Аллаһ рәхмәт итсен. Фәррашдан биш сумны алдым да, ибдәшем Габделмәҗидкә барып кердем, үзе генә икән, ибдәш җәмәгате өйдә юк икән. Бергәләп аш пешереп, рәхәтләнеп сөйләшеп ултырдык, ике кич торып, кайтуга ният кылдым. Шундан поездга билет алдым Раевка станцасына, анда барып төшеп, күрше Кайраклы авылы Миңнулла дигән кешенең углы очрап, ул мине Кайраклы авылына алып кайтды. Монда кич йоклап, икенче көн иртәләп Фәхреддин ага чәйгә

чакырып, еглый-еглый куанып, Ходага шөкер, сәламәт кайтдыңыз дип Коръән укытып, сәдака биреп озатды, кичкә каршы Эстәрлебашка балаларым янына юнәлдем.

***Уфадан Эстәрлебашка сәфәр.***

Мондан Эстәрлебаш 10 чакрым иде. Зур юлдан кайтмый, юлсыз тугры авылга сәфәр кылдым, чөнки зур юлда кешеләр очрап таныйрлар дия юлсыз кайтдым. Көн баеган, чишмә башы тавына килеп ултырдым. Шул тауның итәгендә, алама бер таш өйдә торалар иде. Балалар кычкырышып йорт тирәсендә уйныйлар, мин ни эшләргә белми, Ходага шөкер, балаларны күрдем бит дип, куанычымдан нишләргә белми идем. Ут якканлар, барып күрдем, сәламәт, җәмәгатем берлә күрешеп, балаларымны күрдем. Бер шадлык, Хода гына белә, кечкенә кызым Мәрьям миндән кырык көнлек бала булып калган иде, ул мине белми дә иде. Бу вакытында ул биш яшьдә булса кирәк. Еллар бик авыр, җәмәгатем бәгъзе балалар белә ерак яланларга йөреп, башак җыеп кайтып, балаларны тәрбия кыла иде. Олуг углым Мәсгуд Эстәрлебашда сыер көтүен көтә иде. Шулай итеп, ничек дә булса азык табып, кешедән хәер сорамый үз тамакларын туйдырып торганлар. Ходага шөкер, олуг кызым Хәдичә 16 яшендә таш биналар салучыларга балчык, таш ташып хезмәт итеп йөри иде. Өскә-башка һич нәрсәмез калмаган булса да, әманәт кылып куйган кешеләр бирмәгәнләр. Барын да төрле базарларга алып барып сатканлар. Бөтен яхшы киемләремез кеби нәрсәләремез күп иде. Иң зур хыянәт кылучы [...][1]. 21 нче ел ачлыкында ачлыкдан туйдырып чыгарган идем, күршемез булу сәбәпле. Анасы үлде, үзем кәфенлек биреп дәфен итделәр, менә шушы баладан безгә шул изгелек кайтды. Ул да үлде, башкалар үлде, Ходага шөкер, без бу көнгә кадәр сәламәтмез һәм балаларым да сәламәт, борынгы артык йорт һәм киемләремез булды, балаларым укыды, адәм булдылар, хөкүмәтнең ярдәме аркасында Ходага сабырлык кылдык يَتَوَكَّلْ камил иде. [3]тикадымызъаятенә иг [2]عَلَى اللهِ فَهُوَ حَسْبُهُ

***Эстәрлебашка кайтуым.***

Кайткач, барып мәхәлли[4] начальникларга кайтуымызны белдерү тиешле иде. Бераз уйланып, “мәгълүм булсам, нә булыр икән” дип, куркударак тордым. Шулай да булса, авылның картларындан углым белә бергә көтү көтә торган Ягкуб ага Тукаев дигән кешегә хәбәр итдереп, чакыртып мәслихәт итдем. Ул әйтде: “Аз гына хәбәр кылып тор, халыклар кайткаласынлар, шундан соң мәгълүм булырсың, - диде. - Габдрахман

---

[1] Кулъязмада исем-фамилия теркәлгән, ләкин биредә, мәгълүм сәбәпләр аркасында, күрсәтелмәде.

[2] Вә мән йәтәвәккәл галә Аллаһи фә һүә хәсбүһү- кем Аллаһыга тәвәкәлли, Аллаһ шуның өчен җитәрлек (Коръән, 65,3).

[3] Игътикадымыз – ышанычыбыз.

[4] Мәхәлли – җирле.

Айдабулов бездән борын кайтып иде. “Бер-ике көн хәбес кылып тотдылар, ди. - Анда-монда йөреп, бер-ике ай үтсен, шундан соң мәгълүм булырсың”, - диде. Бер якга сәфәр итүгә тугры килде. Туган кардәшем Фәрхисорур Дим буе Никифар авылында иде. Шуны барып, исәнме-юкмы икәнен белеп, күрешергә ниятләдем. Атамызның шәкерде Габдеррафикъ Габдеррәхим углы Искәндәров агага чакырып үтендем, мине, мөмкин булса, иртәләп кенә Кайраклы авылына илтеп куй, дия. Аллаһ рәхмәт итсен, берсүзсез: “Бик яхшы, минем шул якга көлтәгә дә барасым бар, алып барырмын, таң белән килерсең”, - диде. Иртәсен көн мине Кайраклыга илтеп куйды. Аллаһ мәгъфирәт кылсын, амин. Юлга бер дә хәрежем юк сәбәпле, җәмәгатем мәрхүмә бер яхшы киемне саклаган икән, шуны чыгарып бирде. Аллаһ бу җәмәгатемдән разый булсын, рәхмәт, бәлки берәр йирдә сатып акчага әйләндерермен дия алып чыкдым. Кайраклыдан җәяүләп, аякда чабата, башта иске кепка, алама кожан. Юлда ягъмур ява барып, Яңгырчы авылына йитдем, анда үги әбиемез Мәрфуга абыстайга кердем, өст-баш юеш, бик яхшы каршы алып, өст-башымны чыгарып кибәргә куеп, бары белән зур хөрмәт кылып, тәрбияләп кундырып, икенче көн Муллагөлем авылына барып, Җәмаледдин мулланың абыстае Гафифә апага төшдем. Бик хөрмәтләп, өч көн кунак итеп, юлга кадәр чыгып озатып йибәрде, Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин. Шундан Никифар авылына барып йитдем, базар көн иде. Сорашдым кардәшемне һәм киявемне, “алар монда юк, белмимез”, диделәр. Йортларына барсам, йортның исеме дә юк, тик борынгы таш анбарлар, кладовойлар гына бар, ихатасы да юк. Базарга чыгуым белән борынгы танышымыз Габдулла Максудов очрап калды, барыр йирем юк, сезгә барам инде, дидем.

***Эстәрлебашдан Никифарга сәфәр*.**

“Рәхим итеңез, килеңез, әйдә”, диде. Йортына барып кердем дә, чәй эчәргә ултыртды, киленнең атасы Мәндән авылы Хафиз дигән кеше дә бар иде, таныш кеше иде, сөйләшеп ултырганда милиция килеп керде дә, бездән документ сорый башлады. Минем китмәсдән бездән Эстәрлебаш сельсоветындан алган кәгазем бар иде: “Бу иске документ, бу ярамый”, - диде. Капчыгымны тәфтиш кыла башлады. Мине алып китәргә уйлады. Шундан мин Беломорканалдан биргән документны күрсәтдем, шундан “ни өчен башдук моны күрсәтмәдең” диде, мине калдырды. Шундан килен дә куркып калды: “Мәҗид абзый, тизрәк кит инде”, - диде. Капчыгымны алып чыгып китәргә мәҗбүр булдым. Кардәшемезгә ут күршесе булып торган Гыйниятулла дигән бер егет “фәлән елны прокурорны үлтереп, төрмәдән качып кайткан кеше” дип күрсәткән мине. Бу кичне Җиһангир ага дигән кешедә кунып һәм авылда кардәшемнең кайда икәнне сорашып: “Слак авылында Миңлеәхмәд дигән кеше белер, син шунда бар”, - диде. Слакга

барып, теге кешене табып, ул әйтде, “Бәләбәйдә тире эшендә эшли”, диде. Янә җәяү Бәләбәй китеп, барып кардәшемне табып һәм киявемез Габидне күреп куанышдык. Кардәшемнең тормышы шундай иде: өендә бер ашарлык икмәк дә юк иде. Бичара, юындырып, өс-башымны алышдырып, чөгендердән арыш оны белән пирог пешереп, аз-маз тамак туйдырды, мин ач булсам, ул бичаралар миндән ачлар иде. Бер-ике көндән соң Минзәлә тарафына чыгып китдем. Анда кардәшемнең углы Кәлимулла мөгаллим булып эшли һәм апамның кызы Мәрьям кардәшем дә шунда мөгаллимә булып эшли икән. Максад – азрак  ярдәм итмәсләрме дия барырга чыкдым, Бәләбәйдән Әсән суы буе белән авылдан авылга кунып, Ык буенда Олуг Чакмак авылына йитдем. Монда атамның бертуган кардәшенең кызы Маһисорур углы Мәҗид кунак итделәр. Мондан китеп Вәрәш Мөслим, Вәрәш Катмыш, Табын, Саклаубаш авыллары белә Минзәлә суы буенда Шәрләмә авылына барып йитеп, монда атамызның бертуган апасының кызының углы Гарифҗан муллага барып төшдем, танышып каршы алып, бары белән зур хөрмәт кылып, икенче көн Теләнче Тамакга йитдем.

***Никифардан Минзәлә өязе Теләнче Тамакга сәфәр.***

Егерме чакрым мәсафә[1] булса кирәк, җәяү хәлемдә барып йитеп, кардәшләремне күрдем. Минем шундай мохтаҗ хәлемдә кардәшлек хөрмәтенә бераз ярдәм итмәсләрме микән дип бару идем. Эшләр мин уйлаганча булмады, бәлки миндән өмид итә торган булып күренделәр. Мондан әйләнеп, янә борадәрем Гарифҗан муллага килеп, ул бичара үзе ятим хәлендә тора икән. Биш-алты баласы бар, шул әхвәлдә кулындан килгән бар хөрмәтне кылып, җәяүләп чыгып, беркадәр мине Төркәй авылына озатды. Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин. Төркәй авылындан атамызның, балаларымызның туган-үскән авыллары Сарман районында Карамалы авылына сәфәр итдем. Утыз чакрым юл иде, барып йитеп, атамыз белән бертуган Хәбибрахман углы Кәшшафетдин абзый йортына төшдем, атамыз берлә бертугма агамыз Габделгалим Карамалыда мөәзин иде. Шуның ике углы, Әхмәдлатыйф, Нурелгаян исемләрендә, килеп күрешә белмәделәр, үзем барып эзләп күрешдем. Кыз-кардәшләремез килеп күрешеп, абзый, дип кадәре халь хөрмәтләрен итделәр. Монда берничә көн торып, бабаларымызның каберләренә дога кылып, авыл тарафына кайтырга ният итдем. Мәрхүм Кәшшафетдин абзый углы Сәлахеддин мине ат белән Бөгелмәгә илтергә кушды. Бөгелмә мондан йитмеш чакрым юл иде. Андан Туймазыга поезд йөридер. Сәлахеддин анда сатар өчен бераз он төяп, мине алып барып, Бөгелмәгә йиткерде, Аллаһ кылган мәшәкатьне савапка язсын,

[1] Мәсафә – ераклык.

амин. Монда бер-ике кич куныcareful, поездга өч-дүрт станса юл Туймазы авылына килдем. Мондан Бәләбәй сиксән чакрым юл иде. Бәләбәй китдем, сәламәт барып, кардәшем Фәрхисорурга кердем, сәламәт кайтдым, бик куанып, кулындан килгән кадәрле тамакымызны туйдырып, мине стансага озатды. Мондан ултырып, Шафран стансасына төшдем дә базарга чыкдым. Базарда күкәй белән сәүдә кылучы Таһир Биктимер углы дигән авылдашка очрап, күрешеп, мөмкин булса, мине авылга алып кайт инде дип үтендем. Каршы: “Бик яхшы, карый абзый, бераз атымыз ашасын, тамак туйдырып алыйк да, андан китәрмез”, дип, мине бик шадландырды. Вакыт йитде, атны җигеп чыгып китдек, ахшам караңгысында сәламәт Эстәрлебашка йитеп, Бикмәт тавына җиткәч төшдем дә, тау башы белән тугры йортыма, балаларыма кайтып кердем. Авылда бергә ашап-эчеп, кунак бүлешеп йөргән ибдәшләремез күп иде. Шундай кыенчылык сәфәрендән кайткан дип нә берәве килеп күрешсен, хәтта урамның бер ягындан барганымны күрсәләр, алар икенче ягына кача иделәр. “Синдә акча бар вакытда бар да әшна-дуст, инде акча югын тойса, бар да яныңдан таяр”, ди Тукай. Бу бичара Таһир ибдәш, бәлки гомерендә минем йортыма кереп чәй дә эчмәгәндер, мине шул авыр вакытымда 15 чакрым юлдан хөрмәтләп ултыртып алып кайтды, менә чын мөселман кеше шулай булса икән, гомерем буенча хәтеремдән чыгарачак түгемен, Аллаһ гомеренә бәрәкәт биреп, кешегә мохтаҗ булмый, балалары белән тыныч вә рәхәт яшәсен, амин. Кылган ярдәме Хода разыйлыгы өчен булып, шул яхшылыгы өчен Аллаһ булган гөнаһларыны гафу кылып, ахыр көнләрдә Аллаһның иманы белән дөньядан үтеп, җәннәт сарайларында рәхәт яшәсен, амин. Инде калды, барып, тиешле ГПУ идарәсенә мәгълүм булырга. Берничә көндәрдән соң вакытны табып керергә булдым. Шул вакытда курыкганымны бер Хода беләдер иде. Башка вакытта Ходадан шулай курыкган булсам, бәлки бу хәлләргә төшмәгән булыр идем. Бар белгәнне укып кердем, кулымда булган документымны күрсәтдем, начальник Слак авылы Сөләйман карт углы Рәшид исемле иде.

Моның атасы Фәйзрахман безем яшь вакытымызда Эстәрлебашында Габделкәбир хәлфә мәдрәсәсендә укыр иде. Аяк киеме тегүгә оста иде. Соңгы вакытында Ялпакталга Гобәйдулла Галикәев мәдрәсәсенә барып, шунда торып, Алмалык Александр Гай стансасында казакъ арасында имам булып торыр иде. Документ Беломорканалдан алган иде, 4446 номерда постановление коллегии ГПУда “срочно бушатылды” дип язылган иде. Шундан андагы канал хакында ничек эшләдеңез, кыен булмадымы дип, төрле нәрсәләр сорашып, аз ултырып: “Ярый, бабай, милициягә кереп языла торырсың”, диде, рәхмәт, диеп чыгып китеп, милиция идарәсенә кереп язылдым, Ходага шөкер, шушы вакытда балаларыма, авылыма кайтдым дип

ышандым. Куанычдан ни дияргә белми Ходага шөкеранадан гаҗиз калдым. Аягым йиргә тими җәмәгатем янына өйгә кайтдым, авылда бичара балалар да нишләргә белмиләр иде. Инде урамга чыгып йөри башладым. Үземне бу авылның кешесе түгел кебек күрә идем. Бөтенләй бер чит илдән килгән кеби күренә идем.  Башда алама кепка, аякда чабата, өстә иске кожан. Борын җефәк чапан, кара күн бүрекләр киеп йөргәнләремне уйлап, бәлки бу хәлем шадланучылар да булгандыр, мин бу хәлне үзем Ходаның рәхмәте дип уйлап, күңелемдән шад булудан башка нәрсә юк. Бу миңа, бәлки, Ходаның сынавы булгандыр, бер авырлыкга ике йиңеллек бирәмен дия вәгъдәгә ышанып, Ходадан бер йиңеллеге булыр әле дип өмид итеп йөри идем مَعَ الْعُسْرِ إِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا يُسْرًا [1] аяте кәримәсенә иманым камил иде. Инде бер эшкә, бер чарасына тәкрарга ни эшкә керергә дә белмим, башка һөнәрем һәм юк. Авылда "инвалидлар ширкате" дигән идарә бар икән, алар хөкүмәткә кап сугып бирү, аркан ишү кебек эшләр эшләтәләр икән. Бардым идарәгә, рәисе Миңгали Зариф углы Әхмәров дигән таныш икән. Хәлемне белә, "инде, - дидем, - мөмкин булса, миңа кап сугарга бирер идеңез", - дидем. "Бирергә мөмкин, Мәҗид абзый, ләкин сездәй кешеләргә ГПУ рөхсәтендән башка бирә алмыймыз, менә ГПУдан сорармын, рөхсәт итсә, биреремен", - ди. Бу сүзенә куанып кайтдым. Икенче көн бардым, ярый, бирәмез, дия. Тиешле берничә кило юкә салабас үлчәп бирде дә, алып кайтып китдем.  Капны ничек сугарга, станок ничек була – бер нәрсә дә белмим, нишләргә инде. Тотам да барам Гафур дигән егеткә, ул кап суга икән: "Туган, бер ярдәм кылыңыз, миңа барып, берничә сәгать вакытыңызны биреңез, өем станок ясап һәм кап сугу рәвешене өйрәтеп биреңез", - дидем. "Ярый, карый абзый, барырмын", дип алды һәм тиздән килеп дә йитде, станок да ясады, барысын тиешле эшләрне үгрәтеп, капны суга да башлады, "белмәгән йирең булса, килеп сорарсың", диде, рәхмәт укып калдым. Бу Габделгафур кардәшнең мондай ярдәм кылуына Аллаһ, гөнаһсыз, гафу кылып, иманлы бәндәләр җөмләсендән булсын иде, амин.

Капның эшләү хакы бер данәсенә 45 тиен бирә хөкүмәт, һәр йөз кап башына ярты пот арыш оны, азрак көнбагыш мае, конфет, балык – шуларны бирәдер иде.

***Эстәрлебашта торам, Үзбәкстанга сәфәр.***

Шул рәвешдә ике ел эшләдем, шулай да булса тормыш бик авыр иде. Алты бала һәм бер кардәшем, үземез икәү – тукыз кешемез. Бер язында җәмәгатем Фатыйма белән ун сажин йирне тимер көрәк белә казып, тары сачдек. Көзендә 10 пот тары алдык, аз-маз печән чабып, бер биш-ун йөк

[1] Мәгаль госри йосран, иннә мәгаль госри йосран. Чынлап та авырлыктан соң җиңеллек. (Коръән, 94 , 5-6) аятеннән.

печән ясадым. Уйладым, булмас ахыры, ничек дә булса, бер чара табып, Үзбәкстанга бару фикеренә төшдем. Ләкин юл хәреҗе ясау бик кыен иде. Бәгъзе бер күрше авылларда булган дуст-ишләргә хәлемне сөйләп, ярдәм кылуларын илтимас кылдым. Авылымызда Яшерган авылы Мотаһһар Хәйрулла углы булса кирәк, бу кеше безнең Эстәрлебашында хөкүмәткә аркан ишеп, терекчелек кыладыр иде. Яшь вакытында мәдрәсәдә бер заманда ятмыш идек. Бу бичара, әхвәлемне сөйләгәч үк, берсүзсез, кырык сум акча чыгарып бирде: “Мөмкинлек булса, вакыты белән тапшырырсың, булмаса, боның өчен хафа булмаңыз”, диде. Чын күңелдән рәхмәтемне укып, шадлык белән өемә кайтдым, рафикамызга мәслихәт кылып, сәфәргә чыгарга уйладым. Мотаһһар ибдәшкә бу фарызымны тапшыра алмадым. Үзбәкстан бару белән балаларыма әйтеп йибәргән идем: “Авылда юк, кайда икәнен белүчеләр булмады”, дип кайтдылар. Үзем дә әйләнеп авылга кайткан вакытымда сорашып карадым, вафат булса кирәк, балаларын да белүче булмады. Шушы фарызымны бу көнгә кадәр тапшырырга мөмкинлек булмады. Хода гомеремә бәрәкәт биреп, берәр нәсел-нәсәбене тапсам, тапшыру ниятемне һәм балаларыма да әйтеп куйдым. Вафат булган булса, Аллаһның рәхмәтенә юлыксын, Хода гөнаһысыны гафу кылсын, амин.

Шушы аз-маз акча белән Үзбәкстанга ният кылып, Оренбургга сәфәр итдем. Хәерле сәфәр булсын, амин.

Бу 40 сум фарызымны Эстәрлебашында Хәлилулла Мифтах углына тапшырдым, мәрхүм Мотаһһарның җәмәгате исән икән, инша Аллаһ, фарызымны бирдем[1].

***Оренбургка сәфәр***

1934 нче елда Оренбургга сәфәр Эстәрлебашыннан Оренбургга чыгып китдем, сәламәт Оренбургга йитеп, авылдашымыз Мәҗид Хәбибулла углы Мөхәммәдъярга төшдем, ачык йөз белән кабул итде. Боның өендә бер ай кадәр ятдым, бер дә кара йөз бирмәде, базарга чыгып, аз-маз иске киемләр алып, саткалап йөрдем. Бәгъзе вакытларда толчок базарыннан иске киемләр җыеп алып, Каргалы стансасына барып төшеп, төрле колхоз вә совхозларга йөреп алган нәрсәләремне сатып кайтыр идем. Юлдашым Оренбурглык утиль җыючы Фәрид исемле кеше иде. Шул алып йөрер иде. Шулай итеп, сәрмаяны ясый башладым, көнләрдән бер көн Оренбург 70 чакрым йирдә Каширин (Октябрь) дигән районга иске нәрсәләр белән базарга китдем. Шунда барып, базарында нәрсәләремне сатып, биш-ун кило ак май алып кайтып, Оренбургда сатар идем. Яхшы гына файдаланып, икенче базарына бардым да, әйберләремне сатып, Ташкендка алып бару нияте белән 15 кило

[1] 1953 елда Мәҗид карый туып үскән Эстәрлебаш авылына кайтып ктә.

май алдым, чөнки Кавынчы дигән йирдә кызым Хәдичә, киявемез Хөснеддиновлар тора иде. Шуларга күчтәнәч итеп алган идем. Базар тәмам булып, инде китәм дип, фатирда тамак ашап утыра идем, шунда бер милиция килеп керде дә, фатир хуҗасы рус иде, тышка чыгып, миңа: “Бабай, сине чакыра”, диде. Кердем, мине сорашырга керешеп, базардан ни алдың дип сораша башлады, паспортны алып карады, капчыкларымны тикшерде, соңра “май алдыңмы” дия сорады, мин “алганым юк”, дидем. Фатир иясе “алды” дия әйтде дә, кладовойда майны күрсәтде. “Син үткән базарда килеп сәүдә кылдың, син спекулянт” дип, маемны һәм үземне милиция идарәсенә алып китде. Милиция акт язды һәм, паспортымны алып, мине районымызга йибәрде.

***Оренбургда булып, Эстәрлебашка кайтуым хакында.***

Йибәрәм паспортыңызны, анда алырсың дип, кулыма вакытлы бер язу бирде дә чыгып китдем. Шундан әйләнеп Оренбургка кайтдым, аз-маз гына акчам калган иде, авылдашым Мөхәммәдъяров әйтә: “Нигә паспортыңны алып йөрмисең?”, - диде. Калдырып китү кирәк иде. Бу хәлне кем белә, ни булса булды инде, үткән эшкә салават, диләр. Инде нишләргә калды, Азияга китсәм, паспорт юк, кайтсам, суд кылырлар, бәлки берничә ел төрмәгә ултыртырлар дип куркам. Шулай башым катып йөргән көнләремдә шәһәрдә Советский урамдан килә идем, каршыма кайнешем Габделәзәл Бәдиков очрап калды: “Әй, җизни, нишләп болай йөрисең?” дип исән-саулык сорашды да, мине ресторанга алып кереп кунак итде. Кич фатирына кунарга алып китде. Ул Кавказдан, Кисловодскидан кайтып килә икән. Бөтен әхвәлемне сөйләп бирдем. Кулым “кыска” калган иде: “Җизнәй, гаеп итмәңез”, дия, миңа алтмыш сум акча бирде, башка кешеләр һәм балаларга күчтәнәчләр алып бирде. Шулай итеп, тәвәккәле Хода, Эстәрлебашка кайтырга уйладым. Хода ни язса, шуны күрермен, дидем дә, кайтып да китдем. Сәламәт авылга кайтып кереп, өемездә балалар белән чәй эчеп ултыра идем, берәү килеп ишек какды. Чыксам, ага-эненең берсе: “Карый абзый, сине сельсовет чакыра, - диде дә, -паспортың монда килгән икән, сез бер йирдә май алып кулга төшдеңез кирәк”, - диде. “Дөрест, мин шуның өчен кайтдым, ярар, барырмын”, дидем дә, ул китде. Сельсоветга бардым, сине сәгать алтыда милиция чакыра, диде, ярар, дип чыгып китдем, вакытында милиция идарәсенә бардым, кичке сәгать унга кадәрле көтеп ултырдым, соңра начальник килде, кердем, ултыр, диде. Бер кәгазьләр карый башлады, сельсовет минем балаларым хакында мәгълүмат тапшырган икән, сораулар башланды.

***Эстәрлебаш милициясе начальнигы допрос алуы хакында***

“Син Галиевны үлтереп ятып кайткансың”, - диде. “Ятып кайтдым, тик кеше үлтерүче түгел мин” дим. Күреңез, күргән кеше кебек вөждансыз шундай ялган мәгълүмат биргән. “Балаларың базарларда сәүдә кылалар икән”, - ди. “Дөрест, минем аларга уку өчен китап-дәфтәр алып бирерлек куәтем юк, алар бөтен Эстәрлебашының утильне җыеп, хөкүмәт аларга шырпы вә башка яраклык нәрсәләр бирә. Шуны алып, базарга чыгарып саталар, дидем. - Сезгә бу хакда утильсырье конторындан сорарга мөмкин, дөрест җавап бирер”, - дидем. “Мондан кайда чыгып китдең, нигә китдең, миңа сөйләп бир”, - диде. “Средний Азиядә кызым-кияү бар иде, шунда барамын дип, җәяү хәлемдә авылдан авылга китдем, юл расходына артык киемләремне сата бардым. Шундан Каширин районына йитеп, анда вак-төяк нәрсәләремне сатдым да, кызымга күчтәнәч алып барыр өчен 15 кило май алып идем, шуны милиция мине “син – спекулянт” дип, маемны һәм паспортымны алды, үземне монда кайтырга кушды. Мин бу көн кайтып, чәй дә эчмәдем, алдыңызга килдем”, - дидем. Син бит 35 кило май алгансың дия. “Ялган, артык май минем кеби фатирда бер рус алып, минем маем янына фатирның келәтенә кертеп куеп иде. Милиция килеп керү белән ул йортдан чыгып качды. Шул майны да минеке дип уйладылар да, фатир хуҗасының таныш кешесе булу сәбәпле, һәм милләтчелек кылып, ул майны минеке дип гүаһлык бирде. Шундан милиция акт кылып, мине монда кайтырга кушды, кулыма справка бирде. Шундан начальник татар иде, эшеңезне судка бирәм, диде, белгәнеңезне эшләңез, дидем, паспортымны сорадым, бирелми, суддан соң алырсың, - диде. - Эш эзләп читкә чыгарга кирәк, хәзер эшнең вакытлы чагы, миңа балаларымны ашатырга кирәк бит”, - дидем. “Монда эшләрсез, читтә эшләсәң, паспортың юк” дип, сине эшкә алмаслар, миңа язарлар. Актга кул куеп, сәламәт чыгып китдем.

***Эстәрлебашдан Азияга чыгып китүем*.**

Инде икенче көн. Нишләргә кирәк. Бардым да агайны киңәш итдем. Бу кеше юридический эшендән хәбәрдар иде. Туган, минем эшләрем мондай булды, барын да сөйләдем дә, соңра бу әйтде: “Делоңны күрергә кирәк, андан бер киңәш бирермен”, - ди. “Мин, - дидем, - эш бар да мин сөйләгән рәвешдә”, дидем. Уйлап торды да: “Менә нәрсә, Мәҗид абзый, судья булган мәгълүм күршеңез, борынгы замандан бирле аш-суыңызны ашаган-эчкән кеше, нә кадәр үзе судья булып йөрсә дә, атасы бер авылның кулагы иде. Бөтен крестьянларны яллап, ашлыкларын урдырып, басдырдып, ничәшәр меңләр ашлык алыр иде, ярый инкыйлабка кадәр вафат булып калды. Шуның баласы бу көн судья булып, халыкларга, кулакларга суд итеп ята. Бу кеше бер рәхимсез-вөждансыз адәм, моңа ышаныч юк, икенчедән, син бит, Мәҗид карый булуың сәбәпле, йортыңдан тиешсез рәвешдә куып чыгарып, бөтен

балаларыңны февраль суыгында кар өстенә чыгарып ташладылар. Мин беләм, әлбәттә, сез бу законга керми идеңез, шәхси дошманлык белән сине хаксыз җәбер кылдылар. Әлбәттә, бу вакытда булган йирле түрәләр моны белсәләр кирәк. Инде шулай булгач, бу эш – бер кечкенә эш. Боның өчен бер нәрсә дә булырга тиешле түгел, минемчә. Йиденче август маддәсенә кушып, аз булса да срок бирерләр. Башка кеше булса, бер нәрсә дә булмас иде. Син, мөмкинлек булса, мондан югал, башка сүз юк", - диде. Икенче көндүк рафикамызга мәслихәт итдем дә, нишләрбез, китсәм юлга акча кирәк, китмәсәм, юк өчен мәхбүс булу да йиңел түгел бит, ни булса да Ходага тапшырып китәмен. Бер кәҗәмез бар икән, рафикам шуны берәүгә, бер мамык шәлгә алышып, миңа шуны бирде дә: "Менә, юлда сатып, юлга акча кылырсың", - диде. Мин дә шушы шәлне алып, Средний Азияга сәфәр итдем. Документ юк түгел, анда барып, бер урынга эшкә кереп, берничә айлар эшләп, метрикәм бар иде. Шушы йирдән справка алып, өч айлык паспорт алдым: Южный Казахстан районы Сары-Агач дигән йирдә иде, Ташкендка якын. Бу 1935 елда иде. Шундан Ташкенд обласе Алимкент дигән пунктда (Ак Курган районы) сельпо арасына тире, җон вә башка нәрсәләр хәзерләр өчен кибеткә кердем. Бу йирдә борын заманда Троицки Габделвәлиевләр (Яушев)нең мамык заводы булган, хәзер дә шул завод эшләп торадыр. Шулай итеп, ялгыз үзем генә торып эшли башладым. Җон, тире, кавын, күкәй, тушнина вә утиль - барыны хәзерләп, икеме километрлык Пскәнт дигән районга тапшырыр идем. Шулай итеп, яхшы эшләп тора башладым. Монда ерак түгел […] районы 16 километр йирдә иде. Монда килүем белән кызым Хәлимә эшләр иде һәм 13 яшьлек кызым да болар янында иде. Берничә айлар эшләгәндән соң, сельпоның рәисе Мөэмин Хәйдәров дигән үзбәк иде. Сорадым: "Мөмкинлек булса, сезләр ярдәм итеп, бераз аванс кылып, акча бирсәңез, олуг рәхмәтеңездән булыр иде , - дидем, - чөнки мин Россиядән хатын, балаларымны китерешем кирәк иде", - дидем. Яхшы, дип, ике йөз сум акча бирде, үземнең эш хакым ике йөздән артык булып, дүрт йөз илле сум акча белә Россиягә, кызым күрше авылымызга бер хатын кайта икән, шуңа кушып, кызымны авылга озатдым: "Бар, анаңны һәм балаларымны алып кил", - дип йибәрдем. 15 көн дигәндә кызым-балаларым Ташкендка якын Кавынчы дигән стансага алып төшкән дә, андан соң Аккурганга - киявемезгә телефон биреп, ат сораган, андан киявемез Хөснеддин барып алып килгән, Аллаһ савапка язсын, амин. Киявемез җәмәгатем һәм балаларымны Кавынчыдан Аккурганга алып килгән, рәхмәт. Шундан соң кызым Хәлимә Алимкенткә телефон белә миңа әйтде: "Әти, әниләр сәламәт килделәр" дип, күземдән яшь чыгып, куанычымдан нишләргә белми калдым.

***Үзбәкстанда Алимкентдә һәм Пскәнттә эшләүләрем.***

Рәисдән сорадым, балалар килеп калган икән, барып кайтсам икән, дия. Яхшы, диде. Шундук балаларым белә күрешеп, кичен әйләнеп кайтдым. Рәисдән фатир сорадым, бер яхшы гына бирде, рәхмәт, икенче көн рафикам һәм балалар килеп, йортны тазалап, эчен-тышын аклап куйдылар. Балаларны күчереп алып килдем дә, фатирга кереп түләдем, моңа кадәре дә булса шунда йоклап йөрер идем. Ходага шөкер, бу көнне күрдем, дидем. Бер землянкада булса да торырга разый идем. 36 нчы ел июнь аенда иде. Утыз йиденче елга кадәр монда эшләдем, балаларны укуга бирдем. Шулай итеп, шушы елның май башында бер эшемдән чыгып, Пскәнт дигән районга күчмәк булдым. Бу вакытда киявем белән кызым Хәлимә Пскәнттә иделәр. Май башы көн бер ат күреп яллап, төянеп китдек, бер кәҗәмез дә бар иде, аны җитәкләдек. Пскәнттә бер кич йоклап, икенче көн бер өйне бушка фатирга бирделәр, Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин. Бер ай кадәр монда эшсез ятдым. Соңра Муртай сельпосына махсус эшкә чакырдылар. Ул Пскәнтдән 8 километр йирдә иде. Анда барып, ат-арба белән бер ай кадәр эшләдем дә, хисап алып кайтдым. Ат белә эссе йирләрдә далада бер кыенлык кылды. Янә Пскәнткә кайтып, бер ай торгандан соң, янә мине Бүкә сельсоветына шушы сельпо рәисе Нишан Галиев дигән кеше чакырды, барып, монда заготовка дөкянен алып, үзем генә эшли башладым. Балалар Пскәнттә калдылар, бу утыз йиденче ел август аенда иде. Шулай итеп, монда утыз сикезенче елның апрель аена кадәр эшләп хисап алдым. Чөнки балаларны ташлап анда торуым кыен булды. Эшләр урынымда һичбер кимчелек кылмадым, Ходага шөкер, Пскәнткә кайтып бераз торгач, Киров сельпосына заготовитель килеп чакырды, мин эшли алмыйм дисәм куймады, безгә барасыңмы дип, ярый, алайса, дип кабул күреп барып, дөкянне кабул итдем дә эшкә керешдем. Яхшы гына эшләп йөредем, ике кеше ярдәмче булды, кышлаклардан җон, тире, утиль – шундай нәрсәләрне тапшырырлар иде. Берсе Мөхәммәдкол әкә, берсе Габделкадыйр әкә иделәр. 39 нчы елда заготовка эшендә беренче ударник булып, сурәтемне потребсоюз диварына асып куйдылар, мөмкин кадәр дөкянендә[1] кимчелек кылмадым, барына риза булып, бу көнләрне күреп, балаларымны яныма җыеп ултыруымның мең ходага шөкерана кылудан башка фикерем булмады. Мең тукыз йөз кырык икенче елга кадәр бонда эшләп, 41 елда тире сельпосыны сокращать итделәр. Шундан миңа бушдан калырга тугры килде. 42 нче елның май аена кадәр эшләп, хисабымны тәмамлап, эшемне тапшырып чыкдым. Ходага шөкер, шушы елда үземә махсус йорт алдым. Алты мең сумга. Бераз бу йортны төзәтеп, яхшы гына өй булды. Сәламәт, балаларым белән эченә кереп ултырдым. Ходага

---

[1] Дөкянендә – кибетендә.

шөкер, йортсыз калган балаларыма йорт кылып бирдем дип Ходага шөкерана кылып, бу көнне күрдем дип ятдым. Киров сельпосында бергә эшли торган ибдәшем Габдрахман Мөхәммәдрәхим углы Госманов дигән кеше иде. Ул склад мөдире булып, җыелган малларны аңа тапшырып, заготовкага тиешле мануфактур көн товарларыны аның кулыннан алыр идем. Димәк, дүрт ел бергә эшләдек, йорты һәм янәшә күршемездә иде. Һичбер кычкырышып-талашып тормадым. Шулай да булса, шәхси файдасыны күзләп, минем җыйган күкәй, кавын кебек нәрсәләрдән хөкүмәт хисабына язмый, миңа хөкүмәт бәһасе белән акча бирер иде. Кайвакытларда яхшы товарлардан [...] көнләрдән минем исемем язып, товарны үзенә алып, миңа акчаларны хөкүмәт хакына эшләп биреп иде. Шулай итеп, бер-ике мәртәбә бу эшкә күнсәм дә, соңра моны бирми башладым. Бу маллар заготовкага бирелсә, боның өчен хөкүмәткә җавап бирүем кирәк. Шулай син дә алып калсаң, мин бала-чагалы адәм балаларының өст-башларына да алдасам, мин ничек хөкүмәткә заготовка кылырга кирәк вә катгый рәвешдә туктадым.

***Үзбәкстан Пскәнт районында мәхбүс булуым.***

Ни өчен дисәң, минем җан-тән белән тырышып җыйган заготовканы ул үз файдасына Ташкендка базарга сатдырыр иде. Әлбәттә, боңа һәркемнең ачуы киләчәк. Шундан соң начар карый башлады, бәгъзе вакытларда дөкянемә кереп, "кая азрак эчәргә ал әле" дисә, мин боны эшләмәс идем. "Әй, Мәҗид абзый, синең үлүең-терелүең минем кулымда бит", - дия иде. Моңа мин һич илтифат итмәсдән йөрер идем. Чындан да, ул сәяси идарәнең вәкиле булмыш икән. Бөтен минем үзара сөйләшкән сүзләрне, хөкүмәткә хилафым булмаса да, бише белән артдырып, анда барып тапшыра икән. Ярый, ничек дә булса бер форсат табу булып, мине мондан йибәрергә хәрәкәт кылган, чөнки мондан башка бер яшерен эшләрен мин белер идем. Бер көнне незаконный хөкүмәтнең бер атны йортында урлап суеп, икенче көн Ташкенддан бер үзбәк килеп, тире төягән булып, бу ат итене тире астына басып, Ташкендка базарга озатды. Мин боны белсәм дә, һичкемгә әйткәнем юк иде. Ахырында бу мәсьәлә хөкүмәт кешеләренә йитешеп, боны мин әйткән дип уйлап, миңа ничек булса да бер явызлык кылу фикерендә булган. Хакыйкать, бу эшдән минем хәбәрем юк иде. Икенче дөкянемә бәгъзе бер татар милицияләре килеп, товар сорарлар иде. Боларның базарга чыгарып сату өчен булганын белеп, бирмәк идем. Бәгъзе вакыт гали башка начальникларымыз миндән итлек күн вә башка кавын, күкәй кебек нәрсәләр сорар иделәр. Аз-маз бирсәм, күп вакыт бирмәс идем. Алар да боның өчен миңа начар карарлар иде. Янә Пскәнтлек Хәлил Колмәтов дигән бер угры утильдә бер дөкяндә эшләп йөрер иде. Бер залим бер дә бер көн миндән килеп, туй кыла идем, безгә азрак чәй-мазар, кәлүш кебек нәрсәләр сорады.

“Ярый, склад чыгарса, мөмкинлек булса, аз-маз бирермен”, - дидем. Складдан мал бик аз бирделәр. Шул сәбәпле, боның теләкне үтәп булмады. Шулай да булса, вәгъдә хилафлык булмасын дия азрак чәй, берничә яулык бирдем. Карап торды да, ачуланып, ыргытып чыгып китде. Бу кеше дә сәяси идарәнең агенты булган икән, бу да алда барып ялган сөйләгән, шулай итеп 1942 нче елның 4 нче ноябрендә мине кулга алдылар, бу елда углым Мөхсинне 19 яшендә инде сугышка озатдым һәм киявемез Хөснеддиновны шулай ук озатдым. Улым Мәсгуд 39 нчы елдан бирле гаскәрлекдә иде. Җәмәгатем яшь кенә кызларым белән калып иде һәм мине 4 нче ноябрьдә хибескә алдылар. Алты ай Пскәнт төрмәсендә ултырып, Ташкентка озатып, сәяси мәхбүсләр төрмәсе йир астында булган камераларга ултыртып, бер ай ярымдан янә Пскәнткә кайтардылар. Ташкендның наркомына кертеп, допрос алдылар, күрсәтүче адәмләр югарыда язылмыш Габдрахман Госманов, Хәлил Курматов, бер татар милициясе үземнең дөкянемдә уборщица булып эшләгән Нурия исемле, бер [...] рус хатыны иде. 43 нче елның егерме беренче май кичәсендә төнлә сәгать 12 дә прокурор бер татар хатыны, судьялар, өч үзбәк хатыны Ташкенддан область суд килеп, миңа хөкем чыгардылар. Суд каршында прокурор хатын гали җәза бирүне суддан таләп кылса да, суд исә ун ел хөкүмәтнең концлагерьларында торырга дип хөкем чыгарды. Берничә көндән соң мине Ташкенд төрмәсенә янә озатдылар. Анда барып, берничә көн ултыргандан соң, шул ук кызым Асия килеп, ике көнлек азык тапшырып китде, рәхмәт, вакытларның авырлыгына карамасдан, ата дип мине искә алуга, җәмәгатем һәм балаларыма хәерле тормыш бирсен дип дога кылып калдым. Берничә көндән соң мине Ташкенддан 18 километр Урта авыл стансасы Занкәтә[1] дигән кышлак янында лагерьгә озатдылар. Кырык өченче елның 17 нче июнь көнендә барып, лагерьның икенче пунктына карадылар. Безләрне инвалид хисаплап, йиңел эшкә тәгаен итделәр. Берничә көн арпа урдык, печән чапдык. Огороддан кыяр җыю кебек эшләрдә бер-ике ай кадәр йөрдем. Сугыш вакыты булу сәбәпле, мәхбүсләргә ашау-эчү мәсьәләсе бик авыр иде. Мәхбүсләр һәр көн берничә адәм теге дөньяга сәфәр итә иделәр. Шулай булса да, үзем артык ачлык күрмәдем. Җәмәгатем, балаларым, авызларына булмаса да, ике айда өч-бер булса да, акча вә азык, кызым Асия китереп тапшырып тора иде.

***Мәхбүслекдә лагерьларда яшәвем***

Артык киемләрне дә сатып, ничек булса зур ачлык кыенлыгына төшмәдем. Шундан соң лагерь эчендә бухгалтерия идарәсенә фәрраш булып кердем. Конторны тазалыйм, идәннәрне юам, эш агыр түгел иде. Кырымлы

---

[1] Занги-ата.

бер ага белән икәвемез бергә хезмәт кылыр идек. Монда берничә ай соңра начальник санчастьнең кабинетына фәрраш кылып тәгаен кылдылар. Ялан эшенә чыгып йөрми башладым. Берничә айдан соң мондан алып, йортка йорт себерүче итеп штатны кылып, бер ленинградлык рус Богданов белә икәвемез тәгаен кылындык. Айлык 6 сум иде. Моңа лагерь базарында ике йөз грамм кара икмәк алып була иде. Ләкин йортның коменданты Хәбибуллин дигән татар, Әндиҗанга якын, бер унъеллык мәхбүс иде. Шул бик зур җәбер-золым кылды. Мин исә аның золымларны шикаять итмәсдән эшләп йөрдем. Аллаһдан курыкмагандан курык, диләр. Шулай итеп, сабыр кылдым. Бу эшдә ике ел эшләдем. Ходага шөкер. Балаларым армиядән килеп йөрде, җәмәгатем һәм киявем килеп күрешеп тордылар. Надзорлар яхшы карадылар. Хәбибуллин кебек һич золым-җәбер кылмадылар. Монда ике ел эшләп, мине лагерьның өченче пункты булган инвалидлар лагерына озатдылар. Монда бер ай торып, 46 нчы елның 8 нче апрель көнендә мине һәм бер 70 ләп кешене Ташкендтан 66 километр инвалидлар лагеры Таваксай дигән лагерьга озатдылар. Бу да инвалидлар лагеры иде. Бармыйм дип карышып карасам, начальник доктор барырга мәслихәт итде. Анда яхшы булыр, диде. Шулай итеп, 76 кеше идек. Ике машина белән Таваксайга юнәлдек. 35 кешене алып калдылар, калганын кире кайтардылар. Шулай итеп, Таваксайда калдым. Бер ай кадәре мамыкдан җеп эшләргә кушдылар. Бер ай кадәр эшләдем, лагерь биргән норманы тултырып булмый, норма тулмау сәбәпле, икмәкне дүрт йөз грамм гына бирәләр иде. Бер көн начальник санчастька гариза бирдем – минем тазалыгымны уйлап, бер ярдәм кылсаңыз дия. Комиссия килеп карап, мине больницага алырга кушып китде. Икенче көн, майның 21ләрендә булса кирәк, Ходага тапшырып, больницага кердем. Больница бик таза, эчендә китапханәсе, радио […] эчендә иде. Ятуга тимер караваt, одеал, простыня, мендәр һәм тастымал, янымда бер кечкенә генә тапочка бар иде. Унда бер мунча йибәрәләр, андан таза күлмәк-ыштан биреп, искеләрне алдылар иде. Ашау өчен көненә ике йөз грамм ак нан, дүрт йөз грамм кара нан бирәләр, палатаның эчендә ак нәрсәләр ябылган, ашны шунда китереп бирәләр, көненә йигерме-егерме биш грамм шикәр, бәгъзе вакыт сөт, азрак ак май, сары май, колбаса кебек нәрсәләр бирәләр иде. Укырга китап вә гәзитә журналлар булыр иде. Һәрвакыт Ташкендның “Правда Востока” гәзитәсене үз исемемә алып укыр идем. Әлхасыйль, больницаның тәрбиясе яхшы, дохторлар һәркөн карап, дару биреп торалар иде. Берничә айдан соң, хөкүмәтнең карары буенча, 60 яшьдән югары булган картларны һичберсен калдырмасдан больницага алуга карар булды. Шундан, булган картларны больницага җыеп, тәрбия кыла башладылар. Шул көндән бирле кайда йибәрсәләр дә, тугры капкадан ук больницага йибәрерләр иде. Шушы Таваксайда кырык

тукызынчы елга кадәр тордым. Мондан соң Ташкендкә якын Луначарскийда Ялангач дигән лагерьгә вакытлы кылып йибәрделәр. Монда больницага алдылар, ике айда ун көн торып, янә Таваксайга кайтардылар. Ялангачда торган вакытымда углым Мәсгуд Луначарскийда тора иде, киленем белән 4 километр йирдә иде, һәрвакыт углым килеп, азык яки ашлар тапшырып китәр иде, рәхмәт Фатыйма киленемә, бик яхшы ашлар йибәрер иде. Таваксайга кайтып, берничә ай торгач, сентябрь айларында булса кирәк, янәдән безне Ангрен дигән лагерьга йибәрделәр. Бу Ангрен үземнең йортымдыр, балаларым Мөхсин, Асия үземнең йортымда торалар иде. Йортымыз лагерьдан 3 километр иде. Монда шифаханәгә кердем. Илле беренче елның февраль аенда бик нык суык тиеп, 39-40 дәрәҗәдә хәрарәт[1] булып, рентгент алдылар, бу көндә хәлем бик авыр иде. Носилка белән күтәреп, арбага салдылар, ике километр лазаретка барып йитдем, кар-ягмурлар явар иде, баткач, ярдәмче юк, җаным бугазыма килеп барып кердем. Шул көнләрдә илле төрле ашамлык бар иде. Тик ашап булмый, мунчага бөтен киемләрне салып, бөтен азыкымыз шунда ташлап чыгып китдем. Яланаякга ертык кәлүш, эченә кар тула, барырга хәлем юк, лазаретның бер хадиме, йитәкләп алып барып, палатага салды. Баракдан хәбәр итәргә бер ага-энегә үтенеп киттем, мөмкин булса, вольный чыгып берәр кеше булса, шушы адрес белән минем балаларыма хәбәр итә күреңез дия. Иткән хезмәтләре Аллаһ ризалыгы өчен булып, дөнья вә ахирәт максудларына ирешсенләр иде, амин. Иртүк Асия кызым килеп киткән, передача бар дип чакырдылар, чыгып күрешүгә начальник дохтор рөхсәт бирми ди. Хәлеңез авыр, чыгарга ярамый, диде. Шундан соң передачамны палатага кертделәр. Минем теләгән нәрсәм катык иде. Бар икән, күрү белән катыкны алып капдым, азрак күзем ачылып калды. Каймак, һәртөрле фрукта, тавык ите, күкәй вә башка нәрсәләр күп иде, балаларыма ата дип хөрмәт итүләренә рәхмәт. Бу хөрмәтләрне балаларындан кайтсын дип, дога кылып калдым. Август башларына кадәр монда ятып, яхшы сәламәтләндем, Ходага шөкер, һәрвакыт балаларым килеп хәлемне белеп тордылар, рәхмәт төшсен. Надзорлар да бик ригая кылып[2] тордылар, янә дә мине мондан Ташкендка мәркәзе шифаханәгә озатдылар. Бу исә Ташкендның Орджоникидзе районына [К..] дигән кышлакда иде. Монда килеп шифаханәгә салдылар. Миндә үпкә авыруы дип, шундан камерага куйдылар. Берничә көн рентгендан үтеп: "Бабай, синдә үпкә авыруы юк, бронхит дигән авырудыр, башка нәрсә юк", - дип, мине икенче палатага күчерделәр. Бу больницаны Сангородок дип йөртәләр иде. Монда ике ай торып, янәдән безләр Таваксайга кайтдык. Сентябрь айларында иде. Декабрь

---

[1] Хәрарәт – температура.

[2] Ригая кылып- игътибар күрсәтеп.

айларында миңа фалиҗ рәнҗүе сугылып, бердән, телсез калдым, көндез сәгать өчләр иде, әле дә доктор китмәгән иде, бердән, шундук дару эчереп, бер йөз илле грамм тамырдан кан алдылар. Унҗиде көн бер сүз сөйләмәдем, кеше белән сөйләшергә, гәзитә китереп укуга рөхсәт ителмәде. Бөтен хаҗәтем өстемдә улды, унйиденче көн аз гына телем әйләнә башлады. Ходага шөкер кылып, куанып, акрынлык белән телем яхшы ачылды. Мондан бераз аруланып идем, тәрәзәдән суык тиеп, янә 39 дәрәҗәдә хәрарәт булды. Унбиш көнләрдән соң яхшы гына булып килә идем, янә бердән этапка чакырдылар, 51 нче елның февраль аенда хәлем бик авыр иде. Икенде вакытында култыклап алып чыкдылар, [...] куйдылар, биш тәрәзә ачык, бик суык булды, төн буе йокламасдан чыкдык, иртәләп тордык, янә чакырдылар этапка. Шул вакытда хат алдым Хәлимәдән, посылка салдык дигән, килеп йитмәй калды, бик авыр вакытым иде. Шулай да таныш надзорларга үтенеп китдем, күрәсез бит авыру хәлемдә китеп баруым мөмкин, булса, килү белән минем артымдан шул посылканы тизлек белән йибәрсәңез икән, дидем, ярый, дип сүз бирделәр. Күтәреп машинага төшерделәр, стансага алып бардылар, анда көн буе тикшереп, вагонларга кертделәр. Хәлем бик авыр иде. Аллаһга тапшырып йөреп китдек, төнлә янә вагон суык, идәндә ятамыз, торып хаҗәт үтәргә хәлем юк, я Аллаһ, ярдәм үзеңдән дия барам. Кавынчыда ничә ел бергә ятып йөргән ибдәшем Кавалиев, карт булуына һәм дә авыру булуына карамасдан, кулындан килгән кадәрле ярдәм биреп килер иде. Үзбәк, татар кардәшләр берсе дә авызыма су салмадылар. Шулай итеп, Сәмаркандкә якын Йозак дигән стансага кич сәгать тукызда төшерделәр. Халык аркасына нәрсәләрен күтәреп китделәр, мин баралмыйм, надзорлар давай дия, мине кыстайлар иде. Минем хәлем юк, һаман кычкыралар давай дия. Мин мәҗбүр булдым әйберләремне юлда ташлап китәргә. Соңра надзорлар үзләре күтәреп алып барып, лагерьга кертделәр. Монда берничә көн яткандан соң да мине шифаханәгә алдылар, доктор үзбәк Ризаев дигән кеше иде, яхшы адәм иде. Мине яхшы карады, рәхмәт. Бер дә хәлем юк, ашарга да май кебек нәрсәләр юк иде. Рәхмәтле кызым Хәлимәнең мәгълүм посылкасы килеп чыкды. Хак сөбханә вә Тәгалә, балаларына тәүфикъ-бәхет биреп, үзенә хәерле озын гомер насыйп итсен, амин. Аллаһ разый булсын, бик [күп] нәрсә йибәргән: каз, ит, ак май, сары май, чәй, конфет. Бик өзек вакытымда бик зур файдасы булды, хәтта надзорлар гаҗәп итеп тордылар, "мондай яхшы посылка берәүгә дә килгәне юк иде", диләр иде. Ярый, монда бер-ике ай кадәрле ятып, яхшы гына йөри башладым, шундан соң безләрне – 10 еллык мәхбүсләрне – һәммәсен йибәрделәр "Фәрхатстрой" дигән лагерьга, Урсатский стансасындан бер станса үтеп, Әндиҗан юлында, шунда килеп төшдек. Монда төнлә килеп, безләрне лагерьның баракларына урнашдырдылар.

Монда бездән элек япон әсирләре торып киткән икән. Бараклар бик яхшы, таза, безләрне аерым бер баракга куйдылар. Сәяси статьямыз булуы сәбәпле чакырсалар да, монда шифаханәгә кермәдем, ни булса да булыр, үз киемләремне киенеп, иркен һавада йөрим дия калдым, больницадан бик зирегеп калдым, бу вакыт май ае иде, 1952 нче ел, насыйп булса, бу ел 4 нче ноябрь көн 10 еллык мәхбүслек көнем тулыг тиешледер дип, Ходадан сәламәтлек сорап ятдым. Октябрь  егермеләре җитә иде, мине чакырып фотокарточкам алдылар, иншааллаһ, йибәрсәләр кирәк дип, бераз өмидләнеп калдым. Мәхбүсләрнең вәгъдәсе тула башласа, 15 көн алдан паспортымызга куяр өчен рәсемләрен алалар. Шулай да булса, бераз куркуда тордым, чөнки бездәй сәяси статьялыларның кайберәүләрен йибәрми дә куялар иде. Дүртенче ноябрь көнне дә җитеп калды. Я Аллаһ, нә булыр икән дия көтеп ятдым. Иртән ашымызны чыгып, мине Урба исемле идарәгә чакырып килделәр, бардым, начальник “кая кайтасың?” дип сорады. “Мин, - дидем, мөмкин булса, Ангрен дигән шәһәргә кайтамын”, - дидем. “Баш өсте, анда йибәрәмез”, - диде. Ходага шөкер, өемә, балаларым янына йибәрәләр икән дип, чөнки бәгъзе кешеләргә өенә йибәрмәй янә өч, я биш елга ихтыяри выселка йибәрәләр иде. Шуларны уйлап куркыр дидем. Инде чын котылып китүемә инандым. Шундан начальник МВД миңа бер сигез урында бер кәгазьгә кул куйдырырга кушды. Бик ашыгып лагерь эчендә йөгергәләп йөри идем, үзбәк ибдәш карт:  “Ата, углыңыз килгән дип әйтәләр”, - диде. Исем китеп калдым, каушап китдем, “куй, булмас” дия. Капка төбенә йөгереп барсам, углым Мөхсин легковой машина белән тора. Ни әйтергә белми еглап йибәрдем. Мондан кычкырдым: “Бүген чыгамыз, Хода насыйп итсә, син шунда көт, мөмкин булса, начальникдан күрешергә рөхсәт алыйм, андан соң керерсең”. Начальникга барсам, ул: “Нинди күрешү, менә берничә сәгатьдән сезне чыгарамыз”, - диде. “Ярый, алайса, - дидем дә, килеп углыма кычкырдым, “сәгать бишсез чыгып булмый, бөтен эшләрем тәртиптә. - дидем. – Син барып чәйханә, берәр йирдә ял ит”, - дидем. Шундук безләрне чыгарып йибәрә торган начальник тышка Мөхсин торган йиргә чыгып китде. Мин кычкырдым, “әнә шуның кулында инде безнең эшемез”, дидем. Шундан улым начальникны утыртып, кайдадыр алып китде. Мин дә, бөтен эшләремне бетереп, әйберләремне бәйләп куйган идем. Бу вакыт, сәгать берләрдә булса кирәк, килеп дә чакырдылар, мин дә тиз генә багажымны күтәрдем дә, баракда калган ибдәшләрем белән исәнләшеп, капка төбендәге конторга чыкдым. Монда тиешле кәгазьләргә кул куеп, кулыма гомерлек паспорт биреп чыгардылар, углым Мөхсин каршымда машина белән тора иде. Шундук утырдык да, лагерь эчендә калган ибдәшләр белән, сез дә котылыңыз дип дога кылдым да, борылып китдек, ибдәшләрем кул болгап

калдылар. Әлхәмдүлилләһ, Хак Тәгалә бу көнләрне насыйп итде дип, Ходама шөкеранә кылып, стансага сәфәр итдек. Мондан алты километрда иде. Мине чыгарып йибәргән начальник: “Кич сәгать 11дә поезд да китә, үзем барып ултыртып йибәрермен”, - дип калды. Без барып стансага туктадык. Әйткән вакытда начальник килеп, Ташкендка билет алып бирде. Безләр дә, хәерле сәфәр дип, ултырып китдек. Әлхәмдүлилләһ Раббил галәмин. Бән гөнаһ мәзлум булу сыйфаты илә мөмкин булган унъеллык хөкемемезне Ходаның кушуы буенча сабырлык белән тәмам кылып, бу көнемезгә Ходага шөкеранә кылып юнәлдек. Ходага мең-мең шөкерләр улсын, мәхбүс вакытларымда шикаять итәрлек зур агырлыклар күрмәдем. Рәхмәтле җәмәгатемә, газиз балаларыма, һәрвакыт ярдәмдә булып, ашау-эчү тугрысында бер дә кыенлык күрмәдем. Ун ел эчендә алты ел ярым шифаханәдә, 60 яшьдән югары картларны, ачык авыруы булмаса да, шифаханәгә куйдылар, монда да хөкүмәт авырулар ашы белән тәрбия кылды. Алдымызга аш вә чәйне китереп бирәләр, су кайнап тора, һәрвакыт табиблар күрәләр. Ашау шундай булды: көненә ике йөз грамм ак икмәк, дүрт йөз грамм кара, 25 грамм шикәр, кайвакытда ак май, 50 грамм казылык, сөт, башкаларын биреп тордылар. Фрукта вакытда һәртөрле фрукталардан, һәр карбыз-кавын, кыяр кебек нәрсәләрне, күп булмаса да, бирәләр иде. Яткан шифаханәмез эчендә радио, көтепханә, һәртөрле гәзитәләр һәр көн килеп тора иде. Уку өчен һәртөрле китаплар бар. Көн дә бер мунча, ак күлмәк-ыштан, пружинный карават, матрас, одеал, мендәр, тастымал, ак мендәр тышы – һәммәсе һәр мунчада алышдырып тора иделәр. Хөкүмәтнең бу мәрхәмәтенә һәрбер картлар догалар кылып тора иделәр. Лагерьның эчендә дөкян һәм ашханә, чәйханә, ихтыяри үз ашымызны пешерергә махсус ашханәче бар иде. Акчасы булган кешеләр һәрвакытда ашханәләрдән ашап торалар иде. Ходага шөкер, үземез дә күп вакыт үземезнең пешереп һәм акчалы ашханәдән ашап тордык. Лагерьның йортында сузанә һәм һәртөрле гөлләр, төрле сачкәләр белән тулыдыр. Башкача помидор, бәрәңге кебек нәрсәләр дә үстерәләр, сулары белән сугаралар иде. Ун ел мәхбүслекдә йөргән-күргәнләремне кыскача язып, ошбу урында тәмам кылдым. 1952 нче елның 4 ноябрендә нәҗат булып,[1] 6 нчы ноябрь көнендә сау-сәламәт үз йортым һәм җәмәгатемә вә балаларыма, шәһәремез Ангренга углым Мөхсин алып кайтды. Әлхәмдүлилләһ Раббил галәмин. 1955 сәнә 9 нчы октябрь бу мәхбүс булган вакытымда эш нумерасы №32263 иде.

***Сәламәт кайтып, беренче мәртәбә егерме ел эчендә Эстәрлебашка кайтуым.***

[1] Нәҗат булып – исән калып, котылып.

Балаларым янына кайтып, 52-53 елның кышында шушы Ангрен шәһәрендә үткәреп, язында июнь ае башларында кызым Вәсилә килеп, ул мине үз хәражате белән Россиягә – туып үскән авылым Эстәрлебашка һәм туганым Фәрхисорур олуг кызым Хәлимәләргә барып, авылымызда кардәш-ыругларга, ата вә аналарымызга зиярәт илә мөшәррәф[1] булдым. Кызым Вәсилә бу вакытда Кашкадарья обласе Шәһрисабз дигән шәһәрдә шифаханәдә аптека мөдире булып эшли иде. Безләрне "ата" дип хөрмәт итеп, мин унъеллык мәхбүслекдә үткәргән атасыны хөрмәт кылып, мине кардәш вә туганларым һәм ата вә анамызның каберләренә зиярәт кылырга насыйп булды...

Үткән язылмыш нәрсәләрем гомеремдә күреп үткән вә тормышларым хакында иде. Хода насыйп итсә, үземнең белдекем кадәр нәсел-нәсәбемне язмага ният кылдым. Киләчәкдә балаларыма бер хатирә булып һәм үзләренең ата-бабаларын белү бер файдадан буш булмас кирәк.

Юкарыда язылмыш иде тугма атам Шәйхелислам бине Габделкадыйр бине Биктимер борынгы тарих буенча Уфа губернасы Минзәлә өязе Александр Карамалы вулысы Татар Камали авылында тугмышдыр. Хәзерге көндә Татарстан җөмһүрияте Казанга караган Сарман районы Татар Карамалысы дип йөртеләдер. Габделкадыйр бабамыздан тугмыш: 1 нче - Шәйхелислам, 2 нче – Габделгалим, 3 нче – Хәбибрахман, 4 нче – Йөзлебикә, 5 нче – Хөббиҗамал, 6 нчы –Мәхүбә дирләр.

Атамыз Шәйхелисламдан тугмыш: 1 нче Зөһрә, 2 нче – Габделмәҗид, 3 нче – Фәрхисорур.

Мондан башка балалары вафат итмешләр.

Атамыз мәрхүм 1843 нче миладидә туган, вафаты 1918 нче ел миладидә, Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә, үз кулым белән дәфен кылдым, язулы ташы бардыр.

Зөһрә апамыз гомерне тегү эше белән үткәреп, ахырында үпкә авыруы белән 1906 нчы миладидә вафатдыр. Кабере Эстәрлебаш олуг мәкъбәрәсендә, баш тарафында язылмыш ташы бардыр. Зөһрә Эстәрлебаш Әхмәдгали хәлфә дигән кемсәнең Ниязгали исемендә углына тормышка чыгып, апамыз һәм җизнәмез вафаты соңында калмыш кызлары бере - Өммиҗиһан, икенчесе Мәрьям исемендә булып, ничә еллар минем тәрбиямдә иделәр.

Күзләре тавык күзләре дигән рәнҗү белән мөбтәля[2] булып, тормыш күрә алмадылар, Эстәрлебашында Бакый Мөхәммәдъяровның углы Габделкәрим дигән кешегә никахланып, андан бер углы бала калып, үзләре вафат итделәр, Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә күмелмешдер. Моннан Раим

[1] Мөшәррәф – хөрмәтле.
[2] Мөбтәля – дучар.

исемле бала бу көндә Эстәрлебаш балалар йортында тәрбияләнеп, хәзерге көндә шунда хезмәт кыладыр. Мәрьям кардәшем 10 ел кадәр мөгаллимлек итеп, ахырында күздән зәгыйфь калып, хөкүмәт ярдәме белән тормышдыр. 2 нче Габделмәҗид - 1909 нчы сәнә миладия 29 нчы апрельдә Эстәрлебашда мәшһүр казакъ таифәсендән мөдәррис Гали хәлфә Айдабуловның кызы Фатыйма белән никахымыз булып, икәүдән тугмыш, дөньяда сәламәт булган балаларым түбәндәгеләрдер:

Юкарыда язылмыш Фатыйма иде. Габделмәҗид 1881 нче ел март аенда туган.

1 нче Хәлимә. 1913 миладиядә тугмыш, Эстәрлебаш гаилә дәфтәренә язылмышдыр. 1934 елда Эстәрлебаш районы Айтуган авылы Гыйбадулла Төхфәтулла углы Хөснеддинов дигән кешегә 1934 нче миладиядә тормышка чыгып, хәзерге көндә Башкортстан җөмһүрияте Бәләбәй шәһәрендә яшәмәкдәдер.

Хәлимәдән тугмыш балалар: 1 нче – Әминә, 2 нче – Наил, 3 нче – Шамил, 4 нче – Мәдинә, 5 нче – Халидә исемләрендәдерләр. Кызым Хәлимә русча, татарча уку-язу белеп, күп магазинларда сәүдә эшендә эшләде, хәзерге көндә йорт хуҗасы булып яшәмәкдәдер.

2 нче углым Мәсгуд 1917 нче елның 13 нче гыйнварында туган, Эстәрлебаш гаилә метрикә дәфтәрендә язылмышдыр. Үзбәкстанда Ташкенд обласе Туйтүбә дигән районда Фатыйма дигән бер кызны никахланып, андан Рәйсә исемле бер кыз бала булып иде. Ни сәбәпләр араларында килешмәүчелек булып, фиркать кылмыш[1], бу киленем хәзер дә кызым Рәйсә белән Ташкенд шәһәренә якын Луначарский поселкасында укытучы булып яши.

Мондан соң Башкортстан җөмһүрияте Туймазы дигән районда Шәрәфеддинов дигән кемсәнәнең Закирә исемле кызы никахланып, Вәсилә исемле бер кызы булды. Хәзер көндә Туймазы районында торадыр. Олуг җиһан сугышы вакытында әүвәл гаскәрлеккә алынып, Ленинград мәктәбендә авиятехниклекгә укып, беренче Финляндия сугышында иштиракь кылып һәм дә олуг җиһан сугышы вакытында Мәскәүдә аэродромда хезмәт итеп, лейтенант икенче дәрәҗәсене алып, сәламәт кайтды. Татарча уку-язу белә.

3 нче кызым Асия 1922 нче елында Эстәрлебашында тугып, соңра Үзбәкстанга кылып, 1 нче торган йиремез Ташкенд обласы Пскәнт мәктәбендә унъеллык укуны әгълачы[2] булып тәмамлап, соңра Ташкендта табибә мәктәпнең техникумында укып, әгълачы булып тәмамлап кайтып, Пскәнт шифаханәсендә эш башлап, бу көнгә кадәр шул эшдә эшләп торадыр.

[1] Фиркать кылмыш – аерылды.
[2] Әгълачы – яхшы, югары дәрәҗәдә.

1941 нче еллар булса кирәк, мәктәбдә әгълачы булу сәбәпле, бер ай Мәскәү, Ленинградка сәяхәткә йөртеп кайтардылар. Пскәнтдә Төрче шәкерд дигән кешенең углы Рәсим Миңлевәлиев дигән егетгә тормышка чыгып, Фәрид исемендә бер углы бар, бу көндә мәктәпнең икенче сыйныфында укыйдыр. 10 яшендә.

4 нче углым Мөхсин 1924 нче елында тугды, Эстәрлебаш гаилә дәфтәрендә язылмышдыр. Үзбәкстан Пскәнт районында әгълачы булып, унъеллык мәктәп тәмамлап, соңра Пскәнт районы Дунгкурган кышлагында мөгаллимлек кылып, 1942 елның 19 нчы августында 18 яшендә иде, олуг җиһан сугышына гаскәрлеккә алынып, гаскәрлек вакытында пулеметчикка укып, сугыш вакытында беренче лейтенантлык исемене алып, сәламәт сугышда булып, сәламәт калды. Шулай да булса, 10 ай кадәр Кавказда Краснодар шифаханәсендә ятып, 1946 елда сәламәт кайтды, күп урында тәнендә осколоклар кереп, беразы чыкмай да калган. Мәшһүр Донбас дигән күмер шахтасында туган Ворошиловград обласе Кировский районы Барабинский рудникда Сәмигулла Мотыйгуллин дигәннең Дилбәр исемле кызыны никахланып, 1945 нче елның 12 нче февралендә армия вакытында алып кайтды. Углым Мөхсин белән киленем Дилбәр арасында түбәндә сәламәт булган балаларыдыр:

1 нче – Мәхмүд Кадыйров, бу көндә 8 яшендә улып, 1 нче сыйныфда мәктәбдә укыйдыр.

2 нче – Мөнирә исемле, бу көндә 6 яшендәдер. Мондан башка туып үлгәнләре – Равил исемле бер угыл, Мансур исемле, Морад исемлеләр иде. Равил Донбасда мәдфүн. Мансур Ангренда, әбисе Фатыйманың кабере янында, Морад Башкортстан Күмертауда мәдфүн, 54 нче елда. Мөхсин хәзерге вакытда ун елдан бирле суд эшендә хезмәт кыладыр.

3 нче кызым Диләрә Башкортстан җөмһүрияте Күмертау дигән районда 1956 нчы елда 13 нче февральдә тугмышдыр. Хәзерге көне ата-анасы белән Оренбург шәһәрендә тормыш кылыбдыр.

5 нче кызым Вәсилә 1926 миладидә Эстәрлебашында тугды, Эстәрлебаш гаилә дәфтәренә язылмышдыр. 9 яшь вакытында Үзбәкстанга килеп, Пскәнтдә 10 еллык мәктәп тәмамлап, соңра Ташкент шәһәренә табибә мәктәбенең фармацевт бүлеген әгълачы булып тәмамлап, бу көндә Кашкадәрья обласында областной аптекада мөдир булып эшли, мондан элек Шәһрисабз районында эшли иде. 1953 елның 31 нче декабрендә шул йирдә тереклек кылучы Фидаи Исламморадов дигән кешегә тормышка чыгып, 1955 елда Флюра исемле кыз бала дөньяга килде, никах туенда үзем никахны укып тапшырдым.

6 нчы кызым Мәрьям 1928 елда Эстәрлебашында тугды. Эстәрлебаш гаилә дәфтәренә язылмышдыр. 8 яшь вакытында Үзбәкстанга килеп, Пскәнтдә 10 еллык русча мәктәпне әгълачы булып тәмамлап, соңра Ташкент табибә мәктәбенә керде. Анда берничә ел укып, Ленинград табиби мәктәбе институтына гариза биреп керде, анда укып, 1953 миладиядә мәктәпне тәмамлап, әгълачы (отлично) булып, шәһадәтнамә (диплом) алып, янә шул ук мәктәпдә өч [ел] укуга керешеп, аспирантурага керде. Сәламәт булса, бу ел 1956 елда тәмам итәчәк. Тормышка чыкганы юк әле. Хода тәүфыйк, үзенә ибдәш булырлык бәндә насыйп итсә иде, амин. (56 нчы елда мәктәпне тәмам кылып, Мәскәүнең мәгариф министры тарафыннан Ульянов обласына тәгаен кылынып, Мәләкәс районына ошбу көндән бирле табибәлек вазыйфасыны үтәп тордык, ди. Хәзерге көндә Башкортстан җөмһүрияте Салават шәһәрендә табибә булып хезмәт итмәкдәдер. Зөһрә исемле бер кызы, исем-шәрифәсен үзем куйдым. Наилә исемле кыз дөньяга килде, 1961 нче елның февралендә булса кирәк)[1].

3 нче бертугма кардәшем Фәрхисорур 1883 елда Эстәрлебашында тугмышдыр. Әүвәлге вакыт укуы белән яхшы гарәпчә, Кәлямулланы укуны бик әйбәт beләдер. 1905-1906 нчы елларда Дим буе Никифар авылында Казан сәүдәгәрләрендән мәшһүр Сәмигулла Габдуллин дигән кешегә, яше 60ларда булса кирәк, тормышка чыкган. Әүвәлге вакытның мәдәнияте шундай булган икән, дини китапларда көфүлек[2] кирәк. Үтенсәләр дә, бай булса көфү булмаса да ярый дип, замана муллалары шәригать чыгарганлар. Бу киявемездән 1906 нчы елда бер угыл бала туып, исеме Кәлимулла булгандыр. 1917 елның март ае ахырларында Сәмигулла киявемез вафат булып, Никифар мәкъбәрәсендә дәфен кылынмышдыр. 1922 нче ел олуг инкыйлаб вакытында бөтен мал-милекләре мөсадәрә кылу[3] сәбәпле, кардәшем Фәрхисорур сабый углы Кәлимулла белән тик икәве йортта калдылар. Мәзлум[4] булып калган кардәшем һәм углы бу көндә Бәләбәй шәһәрендә сәламәт яшиләр. Залимләр бар да үлеп бетделәр. Соңра кардәшемә тормышлар авыр була башлады, читдә Уральский тимер юлы буенда [...] стансасында анамыз белән бертугма агамыз Гыйззәтулла Вәлиулинның углы Мәҗид Вәлиуллинны: “Монда килеп тор, кардәшеңезнең йортын карап торырсың”, дия чакырып идем, ул бичара килеп, бер-ике [ел] торып, соңра кардәшемезне никах кылып, бергә тора башлады. Боларның уртасында дүрт кыз бала булып, яхшы гына тормыш кылып яшәделәр. Ахыр

---

[1] Истәлекнең бу өлешенә автор шул рәвешле өстәмә керткән.
[2] Көфулек- тиң булу.
[3] Мөсадәрә кылу - конфискацияләнү
[4] Мәзлум – рәнҗетелгән.

гомерләрендә Бәләбәйгә күчеп китделәр. Балалары: 1 нчесе – Әминә, 2 нче – Зәйтүнә, 3 нче - Зөһрә, 4 нче – Рәйсә исемләрендәдер.

Әминә Бәләбәй унъеллык мәктәбендә нимес телендә укып чыгып, хәзерге көндә Башкортстан мәктәпләрендә нимес теле укытучысы булып эшлидер. Бер башкорт егете судья Сәгыйдов [*никахланмыш*] иде. Араларында килешмәүчелек булу сәбәпле, аерылышдылар. Араларында бер угыл бала калды – Бату исемендә, берсе кыз – Ләлә исемендәдер.
Берничә еллар Эстәрлебашында укытып, бүгенге көндә Уфада Черниковка якын бер мәктәпдә укытадыр. Кызы 15 яшендә, углы 10 яшендә.

Кәлимулла Сәмигулла [углы] Габдуллиндан калган ятим хәлдә укып, агрономлык мәктәбене тәмамлап, хәзерге көндә Бәләбәйдә анасы Фәрхисорур белән бергә торалар. Заводской урам, 17 нче номерда үз йортларында, хәзерге көндә Бәләбәйдә газета идарәсендә мөхбир-корреспондент булып хезмәт итә.

Зәйтүнә Бәләбәй шәһәрендә унъеллык мәктәп тәмам кылып, соңра Уфада табиби мәктәп, институт тәмамлап, бүгенге көндә Уфада Черниковкада доктор булып хезмәт итәдер. Чишмә районы Сәфәр авылының Сәгыйд исемле кешегә тормышка чыкды. Рәшидә исемле бер кызы бар, икенче кызы Мәрьям 1955 нче елның август аенда тугмышдыр.

Зөһрә Бәләбәйдә унъеллык мәктәп тәмамлап, соңра Ленинградда шәрык телләре институтында өч ел укып, аннан Казан шәһәрендә академиянең бер шөгъбәсендә өч ел укып, Мәскәүгә барып ике ел укып, 1951 нче елдан Казан педагогия институтында укытучы булып хезмәт итәдер. Барысы егерме ел укышда булып, бу ел Казанда тормышка чыгып, 1955 нче елда Искәндәр исемле бер углы бар.

Рәйсә Бәләбәйдә унъеллык мәктәп тәмамлап, соңра Ленинградда педагогия институтын тәмамлап, Ленинград мәктәбендә укытучы булып, Гафуров исемле бер татар егетенә тормышка чыга, Рәшид исемле бер угыл бала булды. Бүгенге көндә Свердловский шәһәрендә (Екатеринбург) ибдәше белән бәрабәр укытучы булып хезмәт итәдер.

Менә икемезнең арамызда булган балаларымыз юкарыда язылганлардыр.

*Агамыз Габделгалим исемле агамның балалары*:

Габделгалим бине Габделкадыйр Карамалы авылының беренче мәхәлләсендә мөәзин булып хезмәт иткән. Балалары – Нурмөхәммәд, Фаизә, Һаҗәр. Беренче җәмәгате Мәрьямдән туганлары. Мәрьям җиңгәмезнең вафаты соңра, икенче хатыны Нөркәй авылындан алмыш Хөснибану исемледер. Бу җиңгидән Рәйхан, Әхмәдлатыйф, Нурлыгаян исемлеләрдән булмышлардыр. Мәрьям җиңги Буралы авылында Хаҗи мулланың кызы

булса кирәк. Бу Хаҗи мулла белән җәмәгатем Фатыйманың әнкәсе Рабиганың анасы белән бертугмалардыр.

Нурмөхәммәд Ык буе Тымытык мәдрәсәсендә Әхмәдлатыйф хәзрәтдә укып, соңра Эстәрлебашына килеп, бер-ике ел укып, шул ук Карамалы авылында мөәзин булып хезмәт итеп вафат булды, кайсы елдадыр, мәгълүм булмады. Мәрхүм бик яхшы кеше иде.

Фаизә Илбәк авылы Габделгалим исемле кешегә тормышка чыгып, шунда вафат улмышлардыр. Һәр икәүләрене күреп беләм, Аллаһның рәхмәтендә булсынлар.

Һаҗәр Мәллә суы буендан ерак түгел Чалпы авылында берәүгә тормышка чыкмышдыр. Боны яшь вакытда күреп беләм.

Икенче хатыны *Хөснибанудан:*

Рәйхан Нөркәй авылына тормышка чыкган, кияве мәгълүм түгел.

Әхмәдлатыйф Карамалы авылында тормыш кыладыр.

Нурлыгаян шулай ук Карамалыда тормыш кыладыр.

Габделкадыйрдан туган:

3 нче – Хәбибрахман […] Кәшшафетдин исемле бер агамыз бар иде Карамалыда, яхшы гына тормышда булып, кайу елдадыр вафаты Карамалыда булса кирәк, яхшы кеше иде. Ничә мәртәбә шушы Карамалыга кайтканыма, әткәмез шушы Кәшшафеддин абзыйда кунак булып тора иде. Сәлахеддин исемле бер углы бар иде, сәламәтдерме-юкмы, хәбәрем юк. Җәмәгате Мәстүрә исемле иде.

4 нче – Йөзлебикә апамыз Ык буе Мөслим районы Катмыш авылында тормышда иде, атамыз мәрхүм белән һәрвакыт барып күрешә идек. Әхмәдхафиз исемле бер генә углы бар иде. Бик диндар, яхшы тормышда булып, атамызның вафаты соңында, кайсы елларда булса кирәк, тәхминән[1] 1923 нче еллардамы, Минзәлә буенда Шәрләмә авылында тормышда Сахибгәрәй исемле кешедә иде. Шуның белән килеп, безнең Эстәрлебашында үземдә кунак булып киткән иделәр, Аллаһ рәхмәтендә булсынлар, амин.

Шушы Йөзлебикә апамызның кызы Фәрхисорурдан Гарифҗан исемле бер углы бар иде. Яхшы укымышлы, шул Шәрләмә авылында мулла иде. Нөркәй авылында Мөхәммәдҗан хәзрәтдән укыган, 1933 нче елда барып күрешеп, кунак булып китдем, гаять диянәтле тәкъва адәм иде. 6 баласы бар иде. Йөзлекәй апамызның өченче кызы Маһисорур Ык буе Олуг Чакмак авылында тормышда иде. Габделмәҗид исемле бер углы бар иде. Шул ук 1933 елда барып күрешдем, игенчелек белән көн күрә, урта тормышда иде.

[1] Тәхминән – якынча.

Габделкадыйр бабамызның 5 нче баласы Хөббиҗамал исемендә, Нөркәй авылында тормышда иде, ирене белмим, яшьли вафат булса кирәк. Гарифҗан углы бар иде. Бераз колагымы ким ишетә иде, бервакытда атамыз мәрхүм белән барып күрешеп идем. Игенчелек белән көн күрә иделәр. 6 нчы кызы Мәхүбә апай Карамалыга якын Баллытамак авылында тормышда иде, ирене белмим, бер углы бар иде.

***Мәрхүм анамның нәсел вә нәсәпләрене язамын:***

Мәрхүмә анамыз Галимә Вәлиулла кызы Ык буена якын Бәйрәкә авылында тугмышдыр, Бөгелмә өязе Чәкән вулысында. Вәлиулла Рәхмәтулла углы, Рәхмәтулла Хәсән углыдыр. Вәлиулла бабамыз мәрхүмнең өч хатыны булмышдыр. Анамызның анасы Шәрифҗамал Мостафа кызы Казандан күчеп килмеш. Безнең анамыз шушы Шәрифҗамалдан тугмышдыр. Вәлиулла бабай Бәйрәкә авылында азрак сәүдә эше белән кәсеп итсә кирәк. Яз көнендә су вакытында  Чегән базарына ат менеп барган икән, кайткан вакытында бер текермән янында юлда үлтермешләрдер. Әйтүләренә күрә, кичен Гафифә исемле хатынны аерып, иртән базарга китсә кирәк. Шул хатынның үлтерүенә сәбәп булган имеш диләр. Янә бер хатыны булган, исеме хәтеремдә юк, андан Фәрхисорур, Гыйззәтулла туган, Фәрхисорурдан Әсма исемле бер кыз булган, Фәрхисорур белән Әсма кызы Кәмәлек суы буенда башкорд арасында торып, шунда вафат булганлар. Гыйззәтулла абзый юкарыда язылмышдыр иде. Шул Гыйззәтулладан калмыш киявемез һәм энемез Мәҗидкә хәзерге көндә сәламәт кардәшем Фәрхисорур  тормышка чыгып, шундан туган кыз балалары юкарыда язып үтдем. Гыйззәтулла абзый сәламәт вакытында барып күрешмеш идем. Бичара, фәкыйрь генә, бик юаш адәм иде. Бераз укымышлы да булу сәбәпле, шул йирдә башкорд балаларына дин сабакы укытып тормыш. Җәй көнләрдә чит базарларга барып, уракга яллanып, байларның ашлыкны урып йөргән һәм малларының елкыларын да карап көн кичергән. Ахыргы вакытында шул Азинка стансадан поездан төшкән кешеләрне, бер аты булу сәбәпле, шуларны ташып да йөргән. Бер авылга пассажирларны илтеп кайтып килгәндә, төнлә бер кеше тарафындан бигөнаһ мәзлум булып үлтерелгән. Мәрхүм бик яхшы адәм иде. Аллаһның рәхмәтендә булып, шәһид бәндәләр җөмләсендән булсын. Бу киявемез һәм борадәрем Бәләбәйдә ашказаны авыруы белә авырып, Уфа шифаханәсендә берничә айлар яткан соңра, Уфа докторлары операция кирәк, Ленинград шифаханәсенә йибәргәнләр, анда барып операциядән соң дүрт кенә сәгать торып, әманәт җанны тапшырган.

Операция вакытында Ленинград табибилек вакытында укучы кызым Мәрьям дә иштиракь иткән. Ленинградта туган кияве, академиядә укучы һәм

Рәисә исемле кызы бик яхшы тәрбияләп, ислам дине исеме белән дәфен иткәнләр, фәкыйрь  хәлдә укытып, аталарын тәрбияләп күмүләре өчен җәнабе Аллаһ күп әҗерләр насыйп итсен. Бу көндә Уфада Черниковкада эшләп торган кызы Зәйтүнә дә, Уфадан барып җитеп, дәфен мәрасименә иштиракь кылган һәм мәрхүм атасыны хөрмәтләп каберенә тимердән рәшәткә ясатып куйган.

Мәрхүм Вәлиулла бабамыз вафаты соңында бертуган агасы Хәлилулла Рәхмәтулла углы Эстәрлебашында дин дәресе укытып һәм ул да азрак сәүдә белән шөгыльләнгән булган. Бертуган борадәре Вәлиулланың вафат хәбәре ишетеп, шундук Бәйрәкә авылына кайтып, анамыз булган кардәшне һәм әбиемез Шәрифелҗамалны Эстәрлебашына алып кайткан. Эстәрлебашдан Бәйрәкә авылы 180 чакрымлык юлдыр. Ул вакытда безнең анамызның кыз вакыты булган. Соңра үз тәрбиясенә алып, Галимәне Эстәрлебашка якын Гайнә исемле авылның Хафиз Насреддин мулланың углына никахландырмышдыр. Бу Хафиз вафат булып, анамыз Галимәне Эстәрлебашка алып кайткан. Соңра үзенең шәкерде безнең атамыз Шәйхелисламга биргән. 1870 нче елларда булса кирәк. Мәрхүм Хәлилулла хәлфә колакга катырак кеше булган, шул нәсәбе дә колакга каты булды. Бәгъзе бер балаларына тәэсирсез калмады. Хәлилулла хәлфәнең ике хатыны булса кирәк. Беренче хатыны вафат булу сәбәпле, икенче хатынга Эстәрлетамак мәшһүрендән Өммегөлсем дигән хатынны алган. Әүвәлге хатыны Минзәлә суы буе Буралы исемле авылда Хаҗи мулла дигән кешенең кызы булса кирәк. Шуңардан бер Рабига исемле кыз туган. Бу Рабиганы Эстәрлебашына казакъ таифәсендән булган бер шәкердкә вирмешдер. 14 яшьләрендә булса кирәк Рабига, шәкерд Дусмөхәммәд исемле хәлфә намында булмышдыр. Эстәрлетамакдан алмыш Өммегөлсем исемле хатындан Мөхәммәдкәрим исемле бер углы Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә укуга барып, шунда вафат булып калган, зиярaты Мәдинәдә Җәннәтел-Бакыйгдадыр. Икенче углы  Мөхәммәдшәриф гаскәри хезмәттә йөреп кайтып, Эстәрлебашында торып, игенчелек һәм азрак күн сәүдәсе белән сәүдә итеп, тереклек кылмышдыр. Яхшы гына дәүләтле булып, диндар вә юмард кеше булып яшәде, 1928 нче елда Эстәрлебашында нахак бер бәла хакында кулга алынып, Сибирияга йибәрелде. Анда Омски шәһәрендә мәсҗеддә фәрраш булып, хатын вә балаларын шунда алдырып, тормыш кылып, Омски шәһәрендә вафат булып, Омски каберстанында мәдфүндер. Хәзерге көндә җәмәгате Зәйнәп Мәхмүд исемле углы белән Омскида торалар. Зәйнәп Эстәрлебашда Хөсәен Вәлидов углының кызыдыр. Бу кеше соңгы көндә Өршәкбаш Карамалыга якын Аит исемле авылда тегермәнчелек белән

кәсеп идеп, шул ук Аит авылында вафат булды. Аллаһның рәхмәтендә булсын, бик галим вә голямага мохлис[1] адәм булып, диянәт белән гомер итде.

Язылмыш Рабиганы Эстәрлебашында олуг мәдрәсәләрдән хисапланып дәрес укыткан Гали хәлфә бине Асанали Айдабулов дигән кешегә никах кылмышдыр. Мәзкүр Рабига белән анамыз Галимәнең аталары бертугма Рәхмәтулла *(бу урында кулъязма киселгән)* ошбу Гали хәлфә белән Рабигадан тугмыш рафикам Фатыйма, мин – Габелмәҗид Шәйхелислам углы һәм 1909 нчы милади 29 нчы апрельдә никах булмышдыр. Никах туйларымыз бик күңелле булып үтмешдер. Туй мәҗлесенә Никифардан киявемез Сәмигулла Габдуллин һәм Эстәрлетамакдан мәшһүр сәүдәгәрләрдән Хәбибулла Госманов вә башка мәхәлләмезнең бөтен голямәсе вә башка авылда мөхтәрәм улмышлар – бар да хазир улмышлар. Никахымызны Эстәрлебашда мәшһүр имам Габдулла хәзрәт Мөхәммәдхарис [углы Тукаев] җәнаблары укымышдыр. Кода булып килгән һәм ата-анамызга вә башка хәзрәтләр дә [...] вирелмешдер... Кияүгә махсус һәдияләр – ефәк чапан, шерсть бишмәт, чалпар, читек вә башка плюш кәләпүшләр вә башка күлмәк-штанларның һәр төрлесендән иде. Ашлар, ягъни туй ашларының хисабы да булмады. Кыска гына әйтсәм, кияүгә пешергән баллы бавырсак бу йир татарларының борынгыдан калмыш гадәте буенча эшләнә торган бер махсус ашдыр. Шул бавырсакга 120 күкәй, бер пот ак он, бер каз май хәраҗәт кылынмышдыр. Мәҗлескә бу бавырсакны ике кеше чак күтәреп алып чыкмышлар. Бондай вак нәрсә – аш мәсьәләләрен язуга сәбәп – балаларга борынгы гадәтләрне әйтеп язарга уйладым. Бәлки ышанмаслар, шулай булмагандыр инде дия. Аллаһ рәхмәт әйләсен, әби-бабаларның болай хөрмәт кылуларына. Ходa ахирәтдә аларга җәннәт нигъмәтләрене алларында насыйп итсен, амин. 1910 нчы ел июнь аенда мәрхүмә рафикамны йортымызга күчереп алдым. Озатып килгән кунаклар – кайнагам Габдрахман һәм Габдеррәхим баҗамыз, Батыр авылындан Мортаза Бәдиков кайнага белән Габдрахман кайнаганың кайнагасы Габдулла Урманцев үзем белә биш повозкада килдек. Янә бер арба йөк: туйга махсус ашлар, бер йөк бабамыз тарафындан җиһазлар (придан) – шкаф, сәгать, мебельләр, тегү машинасы, өч комган, тас, җиз, бөтен посуда – һәммәсе бер төшдә, келәм-киез вә башка ясдык-мендәр кебек нәрсәләр – барын да алып килде. Сөлге, ашъяулык кебек нәрсәләр дә күп иде.

Шулай итеп, бу җәмәгатем Фатыйма белән 40 ел гомер кичереп, 49 нчы елда Үзбәкстан Ташкент обласе Ангрен дигән шәһәрдә ахыргы нәфесләрене тәмамлап, ахирәт сәфәренә күчде. Ангрендә Тишекташ мәхәлләсендә булган мәкъбәрәдә дәфен иделеп, баш очына гарәпчә таш язылып, 1954 нче елда

[1] Мохлис – ихлас.

тимер белән ихата кылдырып кайтдым (фотография белән рәсемен дә алдырып, балаларыма тапшырдым, хатирә өчен).
Зиярат ташына ошбу рәвешдә язылмышдыр:
Бу кабердә куелмыш Фатыйма Гали кызы
Искә алып дога кылыңыз,
Бу кабердә Фатыйма Гали кызы Мәҗид карый җәмәгате
вафат 1949 нчы елда, язгучы агасы Габдрахман август 26 нчыда яздыручы углы Мөхсин дия.
Гали хәлфәдән тугмыш:

Гайшә – Ашкадар буе Батыр авылында имам Мортаза Бәдиков дигән кешегә тормышка чыкмышдыр. Асылда Мортаза Бөгелмә өязе Тайсуган авылындандыр. Гайшәдән туган балалар түбәндәгеләрдер:

Зәйнәп – бу шул Батыр авылында Шәйхелислам Кяшаев дигән кешегә тормышка чыгып, мондан [туган] балалар Зөбәрҗәд Казакъстан җөмһүрияте Сары-Агач районында, Ташкендка якын, халык хакиме булып торган казакъ Җумабай дигән егеткә тормышка чыгып, мондан бер бала тугып, 1935 нче елда Сары-Агачда вафат булып, андан бер кыз бала калган иде, соңра [баласы] Зәйнәп кулында калды. 1935 нче елда барып күрешдем. Кабере Сары-Агач мәкъбәрәсендәдер. Ике угыл бала булмышдыр. Бу көндә кайдадыр, мәгълүм түгел.

Икенче Габделхәйдер – Батыр авылында тугып, соңра Оренбургда бераз вакыт торган, соңра Таҗикстан җөмһүриятенә күчеп, анда сельпода сәүдә эшендә эшләп, соңра җиһан сугышында булып, шунда вафат булды, җәмәгате Оренбург шәһәрендән Һаҗәр исемле иде, аларның балалары булмады. Сталинабад шәһәрендән йөз километр Куйбышев районында эшләде. 35 нче елда барып күрешеп идем.

Өченче Габделәзәл монда Батыр авылында тугып, соңра Оренбург шәһәрендә эшләп, яхшы гына дәүләт сахибе булып, яхшы йортлар да алмыш иде. Соңра инкыйлаб мөнәсәбәте белән Ташкентга күчеп, Сталинабаддан бер йөз илле километрда Курган-Түбә дигән районда үтеп, Тугалан дигән йирдә сәүдә эшләп, хатыны Оренбург шәһәрендән Гобәйдулла Кяшаев дигән кардәшене алмыш, Хәят исемендә иде, болардан берничә бала булып, бер кызы булып, хәзерге көндә сәламәт тормышда булып, бу көн шул Тугаланда яшидер. Җиһан сугышы вакытда гаскәрлеккә алынып, андан бераз гакылына зәгыйфьлек булган. Гакылы ким булу сәбәпле, җәмәгате Хәятнең үлүенә сәбәп булып, 15 елга хөкем иделмешдер. Хәзердә мәхбүслекдә хөкүмәт лагерьларында эшлидер. Без дә 1935 нче елда углым Мәсгуд белән барып күрмеш идек. Углымны эшкә үгрәтәмен дия алып калмыш иде.

***Хәдичә бинте Гали хәлфә***

Оренбург өязе Биккол авылында Габделгалим исемле муллага чыкмыш иде. Күп тормады, бер елдан соң баладан вафат булып, Биккол авылы мәкъбәрәсендә күмелмешдер. Башында язулы таш бар иде. Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин.

***Габдеррәхим Гали хәлфә углы***

Бу көндә сәламәт, Эстәрлебашында укып, соңра Истанбулга барып, анда берничә еллар укыган соңындан, Эстәрлебашында мәктәпдә осуле җәдидә белән укыта башласа да, мәхәллә мәдрәсә мөдирләре Тукаевлар боның укытуына юл бирмәделәр, бу да аңа буйсынмады, тотды да, сәүдә юлына керешеп, яхшы тиҗардан булып яшәде. Ачык мәгълүматлы халис адәм иде. Тукаевлар күп җәфаларга хәрәкәт кылсалар да, үз фикерендә калып, хөрлек белән яшәде.

***Габдеррәхим Чалатаевдан туган балалар:***

Ничәнче еллардадыр, хәтерем юк, Эстәрлебашка якын Яшерган авылында Камәреддин мөэзиннең кызы Шәмсекамалны никахланып, бондан тугмыш балалар түбәндәгеләрдер:

***Хәдичә Габдеррәхим кызы***.

Эстәрлебашында тугып, Эстәрлебашында Лотфрахман Габдрахман углы Галиев дигәнгә чыгып, Лотфрахман инкыйлабдан соң укуга кереп, Казанда авиация мәктәбен тәмамлап, олуг җиһан сугышында авыр хезмәт күрсәтеп, капитан дәрәҗәсендә булып, инвалид, хәзерге көндә Эстәрлебашында 1600 пенсия алып яшәмәкдер. Бер икәве араларында өч углы бар, хәзер көндә угыллары укуда.

***Зөһрә Галиева***

Бу һәм Эстәрлебашында тугмышдыр. Кыз вакытында Эстәрлетамак кешесе Төхфәтуллинга тормышка чыгып, күп тормады, Төхфәтуллинның әхлаксыз булуы сәбәпле, аралары фиркать-аерылышу булды. Соңра Уфада Давыд дигән башкорд егетенә тормышка чыгып, андан бер Искрина исемендә кыз бала булып, Давыд вафат булып калды. Бу кыз баласы белән Үзбәкстанга барып, янә бер татарга чыгып иде. Андан да аерылып, яшьлекдә газиз әманәт җанны Аллаһга тапшырып, Үзбәкстанда Нәманганда мәдфүнә булып калды. Кызы Искринаны бертугма кардәше Мәрьям тәрбияли, бүгенге көндә Ташкенд шәһәрендә тимер юл мәктәбенең институтында укымакдадыр.

***Мәрьям***

Эстәрлебашында тугмышдыр. Бераз укып, соңра Эстәрлебашында Закир Фазлулла углы Әхмәров дигән егеткә чыгып, яхшы мәхәббәтле, тыныч тормыш итделәр. Закир хөкүмәт эшләрендә эшләп, 1941 нче елында олуг җиһан сугышында гаскәрлекгә алынып, әманәт җанны сугыш сафында

җәнабе Хакга тапшырды. Аллаһ гөнаһысыны ярлыкап, шәһид бәндәләрдән әйләсен, амин. Бик инсафлы бала иде. Яшь вакытында Эстәрлебашында 21-22 нче елларда ибтидаи мәктәпдә укыр иде, гаять үткен зиһенле бала иде. Атасы Фазлулла Әхмәров Эстәрлебашында башда күмәч пешереп, соңра йомырка сәүдәсендә булып, ахыр көнләрендә яхшы дәүләт иясе булып, Русиянең олуг инкыйлабы мөнәсәбәте белә хибесдә[1] вафат итмешдер.
Соңгы көндә Ташкендда акушеркага укып, хәзерге көндә Кашакадарья обласе Шәһрисабз шәһәрендә хөкүмәт эшендә эшли.

***Маэвә Галиева***

Эстәрлебашында тугып, Эстәрлебашында укып, соңра Үзбәкстанга китеп, Нәманган шәһәрендә тормышка чыгып, ибдәше белән килешмәүчелек булу сәбәпле аерылып, соңгы көнләрдә юридическийда Харьковда укып, халык хакиме булып, соңра Кашкадарья обласе Шәһрисабз дигән шәһәрдә халык судында тәфтишче булып эшләп, соңгы көндә Эстәрлебашка кайтып, хөкүмәт эшендә эшли башлады. Федор районында инспектор булып эшләп тордыкдадыр.

***Габдеррәшид Галиев***

Шул ук Эстәрлебашында тугып, яшь вакытдан Үзбәкстанга туган апаларына барып, Ташкендда тыйбби мәктәпне кырык икенче елда тәмамлап, олуг җиһан сугышында табиблык эшендә хезмәт итеп, сәламәт кайтып, соңра Үзбәкстан Кашкадарья обласе Мирәкә районында табиб булып эшләп, соңра Эстәрлебашка кайтып, Эстәрлебаш шифаханәсендә күз табибы булып хезмәт итә башлады. Эстәрлебашында Шәрифҗан Ахунҗан углының Маһинур исемле кызын никахлап, бу көндә өч кыз баласы бар. Күз докторлыгына 54 нче елда Ташкендда медицина институтында өч айлык курсда укып, шәһадәт алды.

***Маһирә Галиева***

Бу һәм Эстәрлебашында тугып, соңра Үзбәкстанга китеп, анда художество мәктәбендә укып, художник булып һәм укытучы булып эшләде, 1954 нче елында эшләп торган урыны Шәһрисабздан Эстәрлебашка кайтып, хәзер көндә Эстәрлебашда укыта һәм художник булып эшли. Ибдәше Карагыш авылы Габдеррәхим Закир углы Рәшид дигән кешегә тормышка чыгып, хәзерге көндә ике кыз баласы бар. Бу балалар аналары Шәмсекамал, күкрәк авыруы белән авырып, ятим калдылар. Югарыда язылмыш балаларның тугма аналары вафат булу сәбәпле, аталары Габдеррәхим Чалатаев икенче хатын алырга мәҗбүр булып, соңра Тәтер Арслан

[1] Хибесдә – тоткынлыкта.

авылындан Танау Әхмәд дигән берәүнең кызыны алып, андан Рәшидә исемле бер кыз бала дөньяга килеп, бу һәм яшь вакытдук апалары янында Үзбәкстанга барып, медтехникум мәктәбене тәмамлап, хәзерге көн Шәһрисабзка якын бер урында эшләмәкдәдер.

Бу икенче хатыны да янә вафат булып, өченче хатынлыкга Эстәрлебашының, Салкын Усман диләр, шуның кызы Габдеррәхим Латыйф углына тормышка чыгып, Габдеррәхим вафат булып, андан бер Габделбари исемле углы бала белән калган. Гайшә Госман кызы углы Габделбари белән никахланып алып, хәзер көндә яше 80 нән артык, Эстәрлебашында сәламәт яшәмәкдәдер.

Бу өченче хатыны баласыны ияртеп килү сәбәпле, балалар арасында күңелсезлек булып, әлбәттә, үги ана үз баласыны артык күреп, бу алты баланы читләтү сәбәпле, һәркайулары, аталарын ташлап, чит илләргә китәргә мәҗбүр булган, [...] дигән сүз буенча Габделбари олуг җиһан сугышында вафат булды. Аллаһ гөнаһысыны гафу итсен, амин.

Юкарыда язылырга тиеш Гайшә Гали хәлфә кызының икенче кызы Өммегөлсем Батыр авылында тугмыш, соңгы көндә агалары Казакъстанга барып, шунда Кызыл Урда дигән шәһәрдә Арслан Шакиров дигән таҗик егетенә тормышка чыгып, хәзерге көндә Кызыл Урдада яшидер. Шакиров исә сачтәраш булып эшлидер – парикмахер, яхшы гына кеше, берничә мәртәбә булып китдем. Балалары:

Фәрид бу көнне Ташкендда табиби мәктәбдә укыйдыр, икенчесе аякга зәгыйфь, Кызыл Урда мәктәбендә укый. Өченче бер углы исеме хәтеремдә юкдыр.

Андан Гайшә шул ук Кызыл Урдада вафат булып, кабере Кызыл Урда мәкъбәрәсендәдер һәм башында язылмыш ташы бар, зияратка барган вакытда тугмыш ага-энесе Габдрахман Айдабулов язып китмешдер.

***Габдрахман Гали хәлфә углы*.**

1881 нче елда тугмышдыр. Яшь вакытында Уральский якын йирдә, соңра Эстәрлебашында үсеп, 20 яшенә кадәр атасы мәрхүм Гали хәлфәдә укып, соңра Бохарага тәхсиле голүм дөнья өчен Бохарада “Мир гарәп” мәдрәсәсендә алты [ел] торып, йиденче елында Эстәрлебашка кайтмышдыр. Эстәрлетамак шәһәрендә Нурмөхәммәд Урманцев дигән кешенең Гафифә исемле кызыны никахлап, соңра ел Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укытучылык булып, 1921 нче елларга кадәр дәвам итмешдер. Соңра Эстәрлебашына икенче мәхәллә артдырылып, мәсҗед салынып, Эстәрлебашның түбән оч мәхәлләсендә 1920 нче елларда имам булып сайладык, Уфа диния нәзарәтендә шәһадәтнамә алып, рәсми имамлык вазыйфасыны үти башлау 1928 нче елга кадәр, бу елның 11 нче декабрь кичәсендә бер вакыйга булып

югарыда язылмышдыр. Шул вакыйга мөнәсәбәте белән мәзлум уларак хибескә алынып, фәкыйреңез дә шуларның эчендә булып, Уфа хибесханәсендә биш [ай] ултырып кайтып, 1929 нчы елның 19 нчы сентябрендә кабат алынып, янә Уфа төрмәсендә 11 ай ултырып, 1930 нчы елда янә ун ел мөддәт белә Мурман тарафы Беломорканалда булып һәм Ак диңгез утравы Соловки дигән йирдә булып, 1933 елда биш елдан нәҗат булып кайтып, Эстәрлебашында кара эшче буларак, терекчелек кылына башлады. Соңра 1939 нчы елда әгъдаэның[1] нахак донослар биреп, янә 6 елга Сибирияга сөргенгә йибәрелеп, вәгъдәсендән элек сәламәт котылып, Эстәрлебашына кайтды. Новосибирский лагерында бик халис хезмәт кылып, сәяси мәхбүсдән хисап кылса да, хөкүмәт тугры калды, хезмәтенең вәгъдәсендән элек ике сәнәне гафу идеп нәҗат кылмышдыр. Сәламәт гаиләләренә кайтып кавышып, Эстәрлебашында балалары янында тереклек кыла башлады. Соңра хөкүмәтнең дини мәрасимләрне иҗраэ кылуга[2] рөхсәт заманы чыгарып, һәр мәшһүррәк мәхәлләләргә мәсҗедләр ачарга рөхсәт булып, мәзкүр Габдрахман Гали хәлфә углы Айдабуловны йирле халыкның таләбе буенча хөкүмәт шул ук мәсҗедкә имам булуына рөхсәт кылып һәм дә Уфа диния нәзарәте тарафындан да шәһадәтнамә бирелеп, хәзерге көндә Эстәрлебаш мәсҗедендә имамлык вазыйфасыны үтәп тормакдыр. Аллаһга истикамәт[3] белән дәвамы насыйп итсен.

Габдрахман Айдабулов белән җәмәгате Гафифә арасында туган балалар:

*Мөкәрәмә.* Эстәрлебашында тугып үсеп, 1930 нчы елларда булса кирәк, тормышка чыгып [...] булу сәбәпле, аерылмышлардыр. Соңра Эстәрлебашына якын Өршәкбаш Карамалы авылында Сәлахеддин дигән, хатыны вафат булган кешегә тормышка чыгып, бу Сәлахеддиннең ким гакыллы булуы сәбәпле, андан янә аерылып, мондан бер ир, бер кыз бала булып калмышдыр. Углы Әнвәр исемле булып, Эстәрлебашында унъеллык хөкүмәт мәктәбене тәмамлап, яхшы гына рәссамлыкга үгрәнмешдер. Хәзер көндә Карамалы авылында колхоз идарәсендә хисапчы булып эшләп тормакдадыр. Кызы исә колхоз хезмәтендә эшләп йөрмәкдә.

Соңра Габдрахман Айдабуловның 1 нче рафикасы вафат булу сәбәпле, икенче җәмәгатене Карагыш авылы Садыйк мөәзин дигән кемсәнәнең кызы никахланмышдыр. Диләфрүз исемле боларның туе мәҗлесләренә мәрхүмә рафикам Фатыйма белән Карагыш авылына бармыш идек, 1914 елларда

[1] Әгъдаэның – дошманнның.
[2] Иҗраэ кылуга – үтәүгә.
[3] Истикамәт – туры юл.

булса кирәк, ул вакытда олуг кызым Хәлимә имчәк баласы иде. Март айларында булса кирәк, юкарыда язылмыш мәрхүмә Гафифә Нурмөхәммәд кызы бала тудыруда кыенчылык күреп, җәнабе хакга әманәт җанны тапшырмышдыр, Аллаһның шәһидә бәндәләрендән булса иде, амин. Мәрхүмә инсафлы яхшы бәндә иде. Безләр кияү булып йөргән вакытларымызда күп хөрмәтләр итде.

Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә мәдфүнә улып, башында язылмыш ташы бардыр.

Габдрахман Айдабуловның икенче рафикасы белән араларында тугмыш балалар түбәндә:

*Мөнәвәрә* тормышка чыгып, берничә ел торган соңында ире фиркать кылып, бер кыз бала калмышдыр. Бу көндә сәламәтдер. Мөнәвәрә исә күкрәк авыруы белән вафат булып, яшьлекдә Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә күмелмешдер. Башында язулы ташы бар, Аллаһ мәгъфирәт әйләсен, амин.

*Мәгъмүрә* исемле бер кыз булып, яшьлекдә вафат булмышдыр. Эстәрлебашында мәдфүн, бер углы Хәлилулла Эстәрлебашында хөкүмәт мәктәбендә укып, олуг җиһан сугышында булып, хәзерге көндә Мәскәү шәһәрендә хөкүмәтнең гали мәктәбендә укымакдадыр. Бер үткер зиһенле бала иде, сәламәтлек белән укуны тәмамлап, ватан хадиме булып, ата-анасына ярдәмче булса иде, амин.

*Мәкъфүрә* исемле бер кызы хәзерге көндә ата вә анасыны тәрбияләп тормакдадыр. Тормышка чыгу вакыты ирешсә дә, чыкганы юк әле.

*Оркыя* хәзерге көндә Эстәрлебашда унъеллык мәктәпне тәмамлап, бер ел мәктәп балаларын тәрбияләде һәм укыган соңында хәзерге көн [дә] Эстәрлетамак мөгаллимлек гали мәктәбендә укымакдадыр. Ходa тәүфикъ биреп, ата вә анасына ярдәмче булырга насыйп итсен.

Сәламәт вакытым кадрел-хәл белдекем нәсел вә нәсәпне яздым, алдагы көндә кардәш вә нәсәпне белүгә теләүче булса, шушы язуга кушып язсалар мөмкин. Яздым 1955 нче ел милади октябрь аенда. 1375 нче һиҗриядә рабигыль-әүвәл аенда, Күмертау шәһәрендә.

**Ошбу укыган Эстәрлебаш карьясенең белдекем кадәр тарихын язуга уйладым.**

Бисмиллаһир-рахманир-рахим...

Моның соңында мәшһүр Эстәрлебаш авылы Уфа губернасы Уфа шәһәрендән 150 километрда Эстәрлетамак шәһәрендән 55 километр кыйбла тарафында булып, олуг Сибирия тимер юлындагы булган Шафран

стансасындан 75 километрда тәкърибән[1] 73 дәрәҗә тавилдә[2] 53 дәрәҗә гарызда[3] Эстәрле суының башыннан бер километр урында корылмыш карьядер. Ул заманда башкордлар йиренә Казан әтрафыннан, Оренбург Каргалысыннан бәгъзе кешеләр солых вә мәслихәтләре илән сәүдә вә кәсеп илә шөгыльләнмәк өчен, ошбу Эстәрлебаш урынына утар салып ултырганлар. Соңра сәүдә вә кәсебләре алга баруларны игътибар кылыб, башка адәмләр дә килә башлаганлар. Шуннан авыл башланып киткән. Бу тарихның кайу елларда булуы бик мәгълүм булмаса да, Пугачев вакыйгасыннан йөз еллар әүвәлендә булса кирәк диләр. Пугач вакыйгасы безем бу йирләрдә 1773 нче елларда булган. Эстәрлебашка якын төн тарафында Боскын чокыры дигән урын бар. Шул вакытда бу йирләр урманлык булу сәбәпле, Пугач сугышы вакытында, урман эчләренә чокырларда землянка ясап, яшеренеп калганлар имеш. Шул сәбәпле, Боскын исеме калган дип бабайлар нәкыль итәләр[4]. Бәгъзе кешеләрнең нәкыленә күрә, Эстәрлебашына әүвәл килеб ултырган кемсәләр бераз торгач, йирне башкордлардан иҗарәгә[5] алганлар, иҗарәләре илле елга булган имеш. 1850 елда 25 нче апрельдә язышкан кәгазьләре Әбүнәгыйм Мөхәммәдлатыйф дигән кемсәнәнең кулында бар. Аның бабасы Йосыф сәүдәгәр булыб, Каргалыдан килеб сәүдә итеп, поташ заводын тоткан. Мәгълүм кәгазьне 1809 нчы елда башкордлар белән ул язышкан. Ошбу кәгазь өченче мәртәбә алулары имеш. Һәр мәртәбәдә иллешәр елга язышкан имеш дия нәкыль итәләрдер. Шуңар бинаән[6] башкордлардан кәгазьләшеп йир алу 1809 нчы елдан йөз ел элек ала башлаганлар. Кәгазь язышмай утыз ел торган булсалар, Эстәрлебаш 1680 нче еллар чамасында була башлаган булырга кирәк. Ошбу заманда нәчә кешеләрнең нәселе вә бабалары улдыкы күрелмәс вә беленмәйдер. Пугач вакыйгасыннан соңрак булган эшләрне белүче әби-бабайлар бер йигерме биш мөкаддәм[7] заманларда бар иде вә бәгъзе кешеләрдә искедән сакланган язулар арасында 1774 нче, 1797 нче елларда бәгъзе мөгамәләт кәгазьләре бар. Эстәрлебаш авылы төн тарафыннан биек тау буенда Эстәрле елгасының ике тарафында ултырмыш авылдыр. Кыйбла вә көнчыгыш якларында ачык ултырмыш урманлары бар. Эстәрлебашның һавасы яхшы һәм мивә[8] бакчалары азлап бардыр. Һәр кайу мивәләр

[1] Тәкърибән – якынча.
[2] Тавилдә – озынлыкта.
[3] Гарызда – киңлектә.
[4] Нәкыль итәләр – сөйлиләр.
[5] Иҗарәгә – вакытлы файдалануга.
[6] Бинаән – нигезләнеп.
[7] Мөкаддәм – элекке.
[8] Мивә – җимеш.

вакытында йитешәләр, алма-армуд[1] кебиләрдер. Яланларында йир җиләге, каен җиләге кеби йимешләр күп була. Урманларында читләвек, шомырт-балан, миләш, кура җиләге, бөрлегән, су буйларында карлыган кебек йимешләр йитешәдер. Уртача кышларда суыклык 12 дәрәҗәгә тугры булып, җәй көнләрендә уртача 17 дәрәҗәгә хәрарәт[2] күтәреләдер. Эстәрлебаш халкы татардыр. Күпчелек халыклар иген сачеп кәсеп кылалар. Ваграк булса да бераз һөнәр ияләре дә бардыр, ташчы, печник, аяк киемләре тегүче, пычкычы, балта осталары - столярный кебекләр, күмәч пешерүчеләр һәм бардыр. Хатын-кызлардан чигеш эшләү, шәл бәйләү, кәҗә мамыкындан палас, сөлге, ашъяулык кебек нәрсәләрне эшләүчеләр бардыр. Эстәрлебашында 1897 нче елның перепись буенча 1072 ир җаны, 1052 хатын җаны булып, җәмгысе 2124 нөфүс[3] күренде. Эстәрлебашында атнага бер көн базар булып, һәртөрле халыкга кирәк нәрсәләр сатылмакда Эстәрлетамакдан вә башка әтрафдан базар көне сәүдә өчен килүчеләр күб була. Эстәрлебаш үзендә байтак гына дөкян[4] ачып, һәртөрле сәүдә итүчеләр дә бардыр. Һәр көн кем ни теләсә, сатып алырга мөмкиндер. 1910 нчы елдан башлап, бер сәүдә ширкате тәэсис иделеп[5], байтак гына әгъзасы булып, “Нур” исемендә ширкәт дөкяне ачылды. Йәнә 1915 нче елларда янә бер ширкәт магазины ачылды. “Шәфкать” исемендә булып, һәр әгъзага йөз сумдан җыеп, бик яхшы сәүдә итә башлады. Мәзкүр ике ширкәтнең дә үзем берничә кеше хөкүмәтдән рөхсәт юллап ачдык. Эстәрлебаш карьясе мәшһүр карьялəрдән хисап кылынып, мәдрәсәләрендә һәр елда ничәшәр йөз шәкерд һәр әтрафдан килеп, гыйлем тәхсил кылып[6] китәр иделәр. Казакъстан, Кыргызстан тарафларындан килеп укучы шәкердләр күп булыр иде. Русиянең эчке шәһәрләрендән Саратов, Әчтерхан, Уральски, Сембер, Казан, Уфа вә башка губерналардан килеп укучылар күп булмыш. Шулай ук тарикать гыйльме батыйн дәресләрендә шәехләргә килеп мөрид булып йөрүче кешеләр күп булмышдыр. Мондан ике йөз еллар мөкаддәм Эстәрлебашындан укып чыгып гыйлем тарала башлаган.

Эстәрлебаш авылында 1 нче мәртәбә имам булып хезмәт иткән кеше Монасиб мулла дигән кеше булмышдыр. 1720 нче елдан соң Эстәрлебашда мәсҗед салынып, әүвәл мәдрәсәләр салып, дәрес укыта башлаган кеше – Хөсәен мулла Габдрахман углы. Мәрхүм беренче мәртәбә Эстәрлебашка

[1] Армуд – груша.
[2] Хәрарәт – эсселек.
[3] Нөфүс – халык.
[4] Дөкян – кибет.
[5] Тәэсис иделеп – оештырылып.
[6] Гыйлем тәхсил кылып – белем алып.

мәсҗед бина кылып, җомга укый башлаган. (Бүре Мөхәммәдша ләкабе[1]) Эстәрлебашында булган мөнбәр таягының бер тарафына “Хөсәен бине Габдрахман” дип язылгандыр. Фәкыйрь, шул таяк вакытында булуым сәбәпле, бу язуны үзем укыган идем. 1870 нче елларда бу таякга йөз илле ел бар дип әйтәләр иде. Бу мәрхүм Хөсәен мулланың зияраты Эстәрлебаш авылының уртасында, борынгы иске зиярат урынында, язулы ташын Эстәрлебашында Мөхәммәдша ага яздырып куймыш иде. Хөсәен мулла әүвәл мәртәбә мөфти булып килгән Мөхәммәдҗан мөфти Хөсәеновның атасыдыр. Мөхәммәдҗан мөфти олуг Екатерина икенче заманында – фәрмане һөмаюн[2] буенча, 1789 нчы елда мөфти булып килгән. Юкарыда мәзкүр буенча Хөсәен мулла 1720 нче елларда Эстәрлебашында дәрес башлаган. Шул вакытларда мәсҗед вә мәдрәсәләр бина кылынгандыр. Эстәрлебаш мәдрәсәсенең тарихы 1720 нче еллардан хисапларга ярый. Мәзкүр Хөсәен мулланың кайу елларда вафат булуы мәгълүм булмады. Һәм ничә еллар дәрес укуы да мәгълүм булмады. Ләкин галим салих кеше дия нәкыль идәләр иде.

Эстәрлебашында икенче мәртәбә дәрес укыткан кеше Гаделша хәзрәт бине Габдулла Богданов булган. Ошбу Гаделша хәзрәт Оренбургга якын мәшһүр Чебенле Дәүләтша хәзрәтнең атасыдыр. Гаделша хәзрәт хакында мәгълүм булган хәбәрләрдән Чакмак Ык буенда Габдулла хәзрәт Гафуров әйтә иде: Минзәлә өязе Вәрәш-Мөслим авылында Шәмгун мулла дигән кеше, Эстәрлебашда Гаделша хәзрәт мәдрәсәсендә укып кайтып, указной имам булып торып, 90 яшьләр чамасында 1860 нчы елда вафат булган. Мәрхүм Шәмгун мулланың Эстәрлебашында торган вакытлары 1795 нче елларда булса кирәк. ә Балыклы карьясендә, Эстәрлебашка кырык чакрым йирдә, мәшһүр Хөснеддин ахун хәзрәт мәрхүмнең Гаделша хәзрәт мәдрәсәсендә 1799 миладида язган китабы бар. Ошбу мәзкүрләргә бинаән, Гаделша хәзрәт 1785 елларда, бәлки мөкаддәмрәк яшәгән булса кирәк, Хөсәен мулладан соң Эстәрлебашында Гаделша хәзрәткә кадәр, ягъни аларның икесе арасында мөдәррис булдымы, юкмы, яки Хөсәен мулла бик карт булып, Гаделша хәзрәт аңардан соң мәсҗед вә мәдрәсәгә хәлифә булып калдымы, тәгаен белгән кеше булмады.

Гаделша хәзрәт заманасында Эстәрлебашындан мөтәфәннин[3] галимләр чыгып, араларында могтәбәрләре чит йирләрдә дәрес әйтә башлаганлар. Шул замандан тәхминән[4] 1700 нче еларда Эстәрлебашында галим кешеләр чыга башлагандыр дип хисап кылырга мөмкин. Гаделша хәзрәт 80 яшендә 1812

---

[1] Ләкабе – кушаматы, “Бөре Мөхәммәдша” да булырга мөмкин, ягъни Бөре өязеннән.

[2] Фәрмане һөмаюн – патша фәрманы.

[3] Мөтәфәннин – төрле фәннәрне белүче.

[4] Тәхминән – якынча.

нче елда вафат булган (рәхмәтуллаһи галәйһи), галим фазыл кеше иде дияләр иде.

Гаделша хәзрәт заманында вә беркадәр Нигъмәтулла хәзрәт заманында углы Дәүләтша хәзрәт Эстәрлебашында дәрес әйткән вә соңра Бохарага киткән диләр. Гаделша хәзрәтдән соң Эстәрлебашында Нигъмәтулла бине Биктимер бине Тукай улмышдыр (кәттә хәзрәт дип мәшһүрдер). Нигъмәтулла хәзрәт 1773 нче елларда тугмышдыр. 1801 нче елларда Бохараи шәрифкә тәхсиле гыйлем өчен китмешдер. Шушы 1801 нче елда 1 нче март чыгып киткәне бәгъзе иске кәгазьләрдә язылганы күренә. Нигъмәтулла хәзрәт мәрхүм Бохарага бармасдан борын, Мәчкәрәдә Мөхәммәдрәхим ахун мәдрәсәсендә дәрес укыган. Гаделша хәзрәт вафатындан соң, 1812 нче елдан башлап, 1813 нче елда 22 нче августда указ алып, Эстәрлебаш мәдрәсәсендә мөдәррис вә мәсҗеддә имам булып, гыйльме заһир вә батыйндан[1] дәрес бирә башлаган камил, шәехе фазыл[2] улып, бикадрел-имкян[3] гавам арасында булган тиешсез бидгать  эшләрне бетереп, рәсүлуллаһ юлына өндәгән пәйгамбәр, ходайның юлы белән йөрүне биреп, дини хорафатларны бетерүгә иҗтиһад кылган. Мәсәлән, авылларда җыен (сабан туе), нәүрүз көннәрендә туйлар кылып, кеше үлгәч, өчесе, йидесе, кырыгынчы көннәрендә аш кылып, мәетләрне искә төшерүләрне тиеш түгел димеш. Хәзерге көндә муллалар мәетнең варисларына тәкъдим кылалар  мәеткә, ягъни атасы вә анасы вә башка якыннары үлсә, шуларның рухына Коръән хәтем әйтдерүне. Әлбәттә, бу эшләр Хода ризалыгы өчен генә укылса, бик яхшы. Ләкин болар мәетнең киемен, түшәк-ясдыкын эләкдерү нияте белән укыладыр. Шундан мәгълүм ки, мулла белән мөәзин булмаса, аз-маз Коръән укый белгән мәхәллә карты араларында талаш вә бер беренә гадәвәт[4] булулары, көнчеллек кылулары бу хәтем Ходай өчен булмаган булуны күрсәтеп торадыр. Бу хәтем өчен мәетнең варислары бер нәрсә дә бирмәсләр иде. Болар да хәтем дип талашмас иделәр, бәлки миңа хәтем әйтергә кушмаса ярар иде дип кача башларлар иде. Хәзерге вакытда муллалар мәүлүд уку бидгать дип укыган кешеләрне бидгать кылалар, чөнки бидгать булган нәрсә хәрәм дип, ул кешеләрне халык арасында абруйларын югалтырга хәрәкәт кылырлар иде. Ләкин ул вакытда мәүлүд аены мәсҗеддә күпчелек хозурында укып, күпчелек белән салават шәриф һәм пәйгамбәремезнең нәсел-нәсәбен әхлак вә әүсафын[5] сөйләрләр

---

[1] Гыйльме заһир вә батыйндан – Тышкы һәм эчке дөнья турындагы тәгълимат.  «Гыйльме заһир», «гыйльме батыйн» төшенчәләре, иң беренче чиратта, суфыйчылык белән бәйләнешле. Бу тәгълимат нигезендә дөньяны, тирә-юньне, кешене эчке тою, интуиция белән аңлап, танып-белеп була.

[2] Шәехе фазыл – белемле шәех.

[3] Бикадрел-имкян – көченнән килгәнчә.

[4] Гадавәт – ачу саклау.

[5] Әүсафын – сыйфатларын, якларын.

иде. Һичбер кешедән хәер вә сәдакалар алып, ашлар хәзерләп кылмаслар иде. Инде хәзер шул ук мәүлүд уку бидгать дигән муллалар мәүлүд ае якынлап калса, хатынларны мәсҗедкә җыеп, әллә нинди булмаган сафсаталарны сөйләп, беркем бу мәүлүдне укымас. Шундан кимчелек кылган болар дип вәгазьләр сөйли башладылар. Матуррак тавыш белән укысалар, бичара хатын-кызларның бик кәефләре килер иде. Ләкин пәйгамбәремез, ходаның әхлак-әүсафын яхшылап сөйләмәсләр иде. Әлбәттә, мондай мәүлүдләр бидгатьдер. Әлбәттә, мәүлүден-нәбине укып, хосусан, бу заманда диннең тәгаен вакытында мотлак сөйләп, яшь буынларга пәйгамбәрнең ниндәй кеше булган, ул ислам динене ничек бөтен йир йөзенә тараткан, шуларны ана телендә бик нык сөйләргә тиешле дия. Боңа һич инкарь кылмас. Ләкин ашлар кылып, сәдакалар алып мәүлүд укуларын, матур көйләп укып хатын кыз вә башка халыкларның рухына һичбер файда бирмәсә кирәк, әмма муллаларга яхшы бер ай буена бәлеш, пылау ашап, кесәгә салып кайтулар бик күңелледер. Мәүлүд борынгы пәйгамбәремезгә якын заманларда уку рәсми булмаган, соңрак биш-алты гасырлардан соң укый башлаганлар, укысалар да юкарыда язылмыш тиешле булмаган мәсҗед җамигъда халык җыелып Коръән хәтем кылып, пәйгамбәремезнең юлны әхлак вә әфгальне, булган сөннәтне халыкга аңлатудан һәм салават шәрифләр укып, пәйгамбәремезнең юлы белән йөрергә дип вәгазь сөйләп, кыямәт көнендә пәйгамбәремезнең олуг шәфәгатене сорап дога кылынса, менә мәүлүд шулай буладыр. Пәйгамбәремез Ходага якын гасырларда сөннәте Рәсүл вә аның әхлак вә әфгале[1] һәркемгә мәгълүм булган, һәркем белеп вә аңлап яшәгәнләрдер. Шул сәбәпле, мәүлүд укып, аның хакында сөйләү булмаган. Хәзерге вакытда гакес[2] [...] буенча хәзерге көндә мәүледен-нәбине уку тиешледер.

Эстәрлебашына килгән олуг кешеләрдән мәрхүм казак ханларындан Җиһангир хан вә Ширгази хан иде дию нәкыль идәләр. Җиһангир ханның угылларындан берәү 1840 нчы елларда Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укып ятмышдыр. Безем заманымызда хан мәдрәсәсе дия аталмыш бер мәдрәсә бар иде, бәлки шушындан вакыйф иделмешдер[3]. Нигъмәтулла хәзрәт заманында Эстәрлебашында гыйлем тәрәккъый табып укучы шәкердләр күбәя башлавындан мәсҗед вә мәдрәсәләрне зурайтырга хаҗәт төшеп, мәзкүр мәсҗед вә мәдрәсәләр өчен күп хәраҗәт[4] вә һиммәт сарыф кылынган. Хәзерге мәсҗед исә әүвәлге урындан йөз таяк кадәрле түбәнрәк авылның уртасында күчереп салынган. Бүгенге көндә октябрь инкыйлабындан соң 1930 нчы

[1] Әфгале – фигыле.
[2] Гакес – киресенчә.
[3] Вакыйф иделмешдер – аңлатыладыр.
[4] Хәрәҗат – чыгым.

елларда халык тарафыннан мөсадәрә кылынып[1], хәзерге бу мәсҗеднең алдагы олуг бүлмәсене Казакъстан Таловка кыйсемендә тормыш кылган Исәнбай авылында Исәнбай Хуҗабәк углының ярдәме белән бинаи кылынмышдыр. Мәсҗеднең түбәсене тимер белән Урал области Ялпакталда (Сламихин) Куҗантай хаҗи Абдулов дигән затның садакаи җарияседер[2].

1836 нчы елда Нигъмәтулла хәзрәт заманында Эстәрлебашына фонтал китерелгән. Шул фонтал хәзер дә эшләп тормакдадыр. Эшләнгәндән бирле өч мәртәбә тәгъмир кылынмышдыр[3]. Безем заманда, 1926 нчы елда, үзем әһалигә тәшвикъ кылдым,[4] комиссияне дә үзем хәрәкәт кылып, янә су тукталып калып иде, тәгъмир кылдык. Янә 1954-1955 елында хөкүмәт тарафыннан бишенче мәртәбә тәгъмир кылынды. Бу фонтал хакында югарыда язылып үтде. Шуннан карарсыз. Нигъмәтулла хәзрәт гыйльме заһир вә батыйннан тәгълим вирмешдер. Күбрәк гыйльме заһиргә иҗтиһадын сарыф кылып, заманында матбагалар аз булу сәбәпле, күп хәраҗатлар кылып, китаплар табу өчен зур иҗтиһад кылмышдыр. Үз кулы белән язмыш мәҗмугълары бар күренәдер. Һәр фәннән нәкыльләре бар, “Тәфсире Казый” вә “Тәфсир Шәехзадә” күчереп алу өчен ерак йирләргә барып кайтуын сөйлиләр иде. Шушы көнләрдә Бохараи шәрифдән алдырган күп язма китаплары бардыр. Аллаһ рәхмәт кылсын, олуг әҗер саваплары насыйп итсен, амин. Нигъмәтулла хәзрәтдән 1810 нче елда Мөхәммәдхарис исемле бер углы вөҗүдә килмешдер[5]. 1814 нче елда Мөхәмәдхәррас исемле бер углы вөҗүдә килмешдер. 1833 нче елда углы Мөхәммәдхарис Оренбург губернаторы тарафыннан 1833 нче елның 23 нче сентябрьдә 1380 номерлы рөхсәтнамә бирелеп, Бохараи шәрифкә укуга сәфәр кылды. 1841 нче елда сәламәт кайтды. Атасы Нигъмәтулла хәзрәт заманында шул ук елда Эстәрлебашында дәрес әйтә башлап һәм бер-ике елдан соң шәехлек белән мөрид тәрбия итә башлады диләр. Икенче углы Мөхәммәдхәррас 1844 нче елда Бохарага тәхсиле голүмгә сәфәр итде. Бу елларда Эстәрлебашында җәмгыять күп иде, һәр тарафдан гыйлем тәхсил кылыр өчен гыйльме заһир вә батыйн дәресләре бик тәрәкъкый итеп торган вакыты булгандыр. 1844 нче елда, 1260 һиҗриядә Кәттә хәзрәт Нигъмәтулла бине Биктимер хәзрәтләре 27 нче мартда дарелбәкая күчде, йитмеш өч яшендә вафат. Нигъмәтулла хәзрәт заманыннан калган Эстәрлебаш мәсҗеденә җәмәгать сыймый башлагач, алдагы олуг бүлмәне 1858 нче елда бина кылмышлар, дүрт йөз кешене сыйдырадыр. Нигъмәтулла хәзрәтдән соң углы Мөхәммәдхарис хәзрәт

[1] Мөсадәрә кылынып – кулга төшереп.
[2] Сәдакаит җария – савабы дәвамлы сәдака.
[3] Тәгъмир кылынмышдыр – яңартылган.
[4] Тәшвикъ кылдым – өндәдем.
[5] Вөҗүдә килмешдер – туа.

Эстәрлебашында имам вә мөдәррис улмышдыр. Кануни указ алганга кадәр Оренбург мөфтисе Габделвахид Сөләйманов тарафындан 1844 нче елның 4 нче апрелендә Эстәрлебаш авылында имам булып һәм мәдрәсәләрендә дәрес укытырга, мәхәллә халкының эшләрне тәдбир кылуы[1] өчен дип биргән кәгазе бардыр. Шул ук елда рәсми хөкүмәтдән рөхсәт кәгазе булса кирәк. Каргалыда Габдулла бине Дәүләтшаның Чебенле карьясендән Фаизә исемле кызны никахланмышдыр (вакытында Туташ абыстай дип йөртәләр иде). Бу Габдулла Дәүләтша углы башкордлар тарафыннан кантун булып сайланып, түрәлек итмешдер. Боның кантун булуы хакында Кыргазы[2] буенда Кинҗә (Габдулла авылында) бер карт язмыш бәете дә бардыр (ягъни мөнәҗат), хәзерге вакытында Габдулла мулла көенә дип җырлыйлардыр. Соңгы вакытларда Дәүләтшин фамилиясендә йөргән кешеләр шуның нәсәбендәндер. Җөмләдән, Ленинградда Габделгазиз Дәүләтшин генерал булып яшәде һәм Ленинградда салынмыш мәсҗеде җамигънең салынуы турысында комиссиядә булып хезмәт кылды. Аллаһ рәхәмәт әйләсен. Вә башка угыллары күпдер. 1852 нче елда Харис хәзрәтнең тугма борадәре Хәррас Бохараи шәрифдән сәламәт кайтып, дәрес укытырга башлады. Бу вакыт Эстәрлебашның камил шөһрәт вә тәрәккъкый иткән вакытыдыр. Эстәрлебашына күп галим вә голәмәләр килеп, мәмнүн[3] булып китмешләр. Һәм вакытында Габдессәлам һәм Габделвахид мөфтиләр Эстәрлебашка тәкрар[4] килмешләрдер. Һәм мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев хәзрәтләре Эстәрлебашка килеп тору нияте белән бер өй салдырып иде, килеп тору насыйп булмады. Соңра бу өйне вәкыф идеп[5] калдырган. Хәзерге вакытда бу өй сәламәт почта идарәсе булып тормакдадыр. Эстәрлебашына укуга килүче шәкертләр күп булу сәбәпле, Мөхәммәдхарис хәзрәт заманында күп мәдрәсәләр бинаи кылынмышдыр. Мәдрәсә янында суханә (фонтал) ташдан бина кылынып, өстенә дәресханә Мөхәмәдхәррас хәзрәт өчен бинаи кылынмышдыр. 1888 нче елда бу суханә Хәбибулла бине Мөхәммәдхарис хәзрәт углы заманында янәдән Яшерган ташындан бина кылынып, өстендәге дәресханә алынып, икенче урынга күчерелеп салынды. Суханә эчендә госелханә булып, кышлык өчен госел, тәһарәт алу өчен һәрвакыт эссе булып тора иде. Суханәнең фәррашы[6] һәр көн пичне ягып, тазалап тора иде. Бу суханә олуг инкыйлаб вакытында бозылып, ташны төрле гыймарәтләргә[7]

---

[1] Тәдбир кылу – тиешле чаралар табу, эшләү.
[2] Көергәзе.
[3] Мәмнүн – рәхмәтле.
[4] Тәкрар – кабат.
[5] Вәкыф идеп – җәмәгать файдасына биреп, бүләк итеп.
[6] Фәррашы – каравылчысы.
[7] Гыймарәтләргә – төзелешләргә.

сүтеп алдылар. Мөхәммәхәррас хәзрәт Эстәрлебашына икенче имамлыкга тәгаен кылынды. Мондан соң Мөхәммәдхарис хәзрәт 1859 нчы елда хаж сәфәренә ният кылып, 1859 нчы елның 24 нче декабрендә Оренбургның генерал-губернаторы тарафындан рөхсәт бирелеп, 1860 нчы елда хаж сәфәренә китде. Сәфәрендә Шам шәриф вә Мәдинәи-Мөнәүвәрә барып, 1860 нчы елда сәламәт кайтдылар. Мөхәммәдхарис хәзрәт кунакга ике-өч мәртәбә Казан тарафларына барган, янә Әстерхан губернасы Таловка дигән Сары Үзән буена. Казакъның могтәбәр балаларындан Исәнбаев Хуҗабәк углы кунакга чакырылып бармышдыр. Эстәрлебашындан сигез йөз чакрым мөсафәдә Уральски шәһәрендән үтеп баралар. Бу мәрхүм Исәнбай дигән адәм халис[1] голямаигә ихласлы булу сәбәпле чакырса кирәк. Югарыда язылды: Эстәрлебашына алдагы зур бүлмәне шул адәм салдырмышдыр һәм мәсҗедкә намазлык итеп, куй җонындан басылган киез - дүрт йөз кеше сыярлык бүлмәгә намазлык - кылып йибәргән мәрхүмнең сәдакаи җариясендән булып, Ходა ахирәтдә бу кешене мәгънәви бәндәләре җөмләсендән әйләп, җәннәт сарайларында булырга насыйп итсен, амин. Мәзкүр Исәнбай Хуҗабәк углының зияраты Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә Җәннәтел-бакыйгда мәдфүндер[2]. Башында ташы бар. Исәнбай Хуҗәбәк углы вафат 1272 нче сәнәи һиҗриядә язылмышдыр. Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә вакытымда барып табып, зиярәт кылдым. Бән фәкыйрь исә мәзкүр Исәнбай авылында вөҗүдкә килмешмен, атам-анам белән шул авылда ир-кыз балаларын укытып тормышдыр. 1879 нчы елларда булганлардыр. Шул Исәнбай авылына барудан икенче елны Исәнбаев Хуҗабәк кызы Хәдичәне никах кылмышдыр. Бу Хәдичә мәрхүмә Эстәрлебашка килен булып килеп, күп җиһаз алып килмешдер. Хәтта казакъ рәсеменчә бик зиннәтле кылып, киездән өй алып һәм килмешдер. Бөтен өй эчендә булган яхшы кыйммәтле Бохара келәмләре, бөтен чаршау-чыбылдык кебек өйгә алына торган нәрсәләрне иң кыйммәтле хәтфәдән эшләнмешдер. Әйтүләренә караганда, бу хәтфәләрне фабрикга махсус заказ кылып алдырган диләр. Бу җиһазны безләр дә бәгъзе берәүләрнең күреп үтдек. Мәрхүмә күп тормаган, берничә елдан соңра вафат булып, Эстәрлебаш мәкъбәрәсенә дәфен иделмешдер[3], язулы ташы бар, олуг хәзрәтләрнең кабере янындадыр. Бу Хәдичә ападан Мөхәммәдзариф исемле бер угыл бала калмышдыр. Кырык яшьләр чамасында вафат итде. Бичара, күп вакытлар гакылы зәгыйфьләнеп, җөнүнлек[4] белә мөбтәля булды[5]. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Яхшы инсафлы адәм иде.

---

[1] Халис – чын.

[2] Мәдфүндер- җирләнгән.

[3] Дәфен иделмешдер - күмелгән

[4] Җөнүнлек – акылдан язу

[5] Мөбтәля булды – дучар булды.

Бу Мөхәммәдзариф мәхзүмдән ике углы бала калып, яшьлек вафат итделәр. Хәзерге көндә Эстәрлебашында Өммегөлсем исемендә бер кызы мәрхүмәдер. Шул вакытда Исәнбай авылына кода булып, мәрхүм Сәлимгәрәй мөфти дә бармышдыр. Әйтүләренә караганда, туй 10 көн дәвам итеп, ничә йөзләп куй, вә ничә сыгыр, вә ничә елкы һәм төяләр суелмышдыр. Җәмгыять бик булып, хәтта Таловкадан Казан сәүдәгәрләре шунда килеп, ун көн буена сәүдә кылмышлар. Мөхәммәдхарис хәзрәте бик киң холыклы булып, халыкга мәхәббәтле булып яшәгән һәркемгә тигез карап килгән, кунакларны ачык йөз белән каршы алмышдыр. Һәрвакыт йортында күп кешеләр миһман[1] булып, аш ашаганлар. Үзенең утарханә дигән йортында кырык кадәрле гариб, ятим вә гаҗизләрне туйдыру өчен бер ашханә кылдырып, һәр көн шуларны ашатмышдыр. Бер ачлык елында бер дә иген үсмәү сәбәпле, халыкга 3 мең пот иген таратмышдыр. Александр икенче заманында халыкга бу ярдәмләре булуы колагына ишетелеп, падишаһ тарафындан 1869 нчы елда 16 нчы августда тарханлык дәрәҗәсе бирелеп мөкяфәтләнмешдер. Мөхәммәдхарис хәзрәтнең олуг әҗерләрендән бөтен халыкга гам булган бинаи кылынмыш Эстәрлебашының урталыгында Эстәрле суы аркылы ак ташдан ыспутлап (свод) бер таш күпер бина кылмышдыр. Бүгенге көндә бу күпере бардыр. 1956 нчы елда сәламәт иде. 1869 нчы елда Оренбург әтрафында казаклар хөкүмәтгә каршы тавыш чыгарып, шуларны тынычландырыр өчен Оренбург губернаторы Крыжановский[2] Мөхәммәдхарис хәзрәтне чакырып, үгет-нәсыйхәт кылуларны боермышдыр һәм үтенмешдер. Шушы боерыкга бинаән, 1869 нчы елның 23 нче мартда язган кәгазь нөсхәсе Эстәрлебашында бар иде. “Үзеңез һәлак булырсыз, ничек дә булса, тыныч булырга тырышыңыз. Безем ислам дине һәрвакыт тынычлыкга чакырадыр” дип язмышдыр. Шушы нәсыйхәте буенча казаклар тынычлап хөкүмәткә буйсынып калганлар. Язган кәгазендә мөһере вә кулы бардыр. Мөхәммәдхарис хәзрәт дөньядан хәбәрдар кеше улып, фәнләр үгрәнмәк, һәртөрле телләр белмәк зарур вә кирәк эш дия әйтәдер иде диләр. Ошбу Мөхәммәдхарис хәзрәт вакытында Эстәрле суы буенда яшәгән алты авыл башкордларындан 14 мең десятинә микъдарында мәңгелекгә йир сатып алмышдыр. Алган йире Эстәрлетамак юлы буенда Эстәрле су аша чыгып, Эстәрле суының ике тарафындадыр. Хәзерге көндә Николаевка-Сергеевка дигән рус авылы белән Кунакбай арасындадыр. Мөхәммәдхарис вафатындан соң варислары мәрхүм хәзрәтнең карзы[3] өчен өч йөз десятинә йирләрне һәр дисәтинәсен илле сумдан сатмышлардыр. Хәзерге

[1] Миһман – кунак.
[2] Николай Андреевич Крыжановский (1818-1888).
[3] Карзы – бурычы.

көндә (Сухадол) исемендә рус авылы яшидер. Борынгы Чикрәле шушы авылның юкары ягында иде. Безем заманда гран[1] баганасы бар иде. Әйтүләренә караганда, шул йирләрне десятинәсене бик арзан хак белән алмышлардыр. Биш сумдан артык булмаса кирәк. 1917 нче ел олуг инкыйлаб вакытында мөсадәрә кылынып[2], халык файдасына тапшырылды.

Мөхәммәдхарис хәзрәт 1870 нче елның 2 нче ноябрендә 1286 нчы һиҗри шәгъбән аенда алтмыш өч яшендә вафат итмешдер. Эстәрлебашының олуг мәкъбәрәсендә мәдфүндер. Язулы ташы бардыр, җеназа күп җәмгыять булып, ике-өч мең дия нәкыль идәләр. Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин. Мөхәммәдхарис хәзрәтнең җәмәгате – Иманлыкол авылының Оренбург өязендә Габдулла кантон Дәүләтшин кызы Фаизә исемендә. Бу Фаизә абыстайны “туташ абыстай” дия йөртерләр иде. 1910 нчы елларда вафат булып, Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә дәфен кылынмышдыр. Нигъмәтулла хәзрәт зәүҗе Харис хәзрәт каберләре янындадыр. Башында язылмыш ташы бардыр.

Мөхәммәдхарис хәзрәтдән соң варис булып калмыш балалары Габдулла, Гобәйдулла, Хәбибулла, Мөхәммәдшакир, Габделмәҗид, Габделкадыйр, кызлары – Зөбәйдә, Зөһрә - ошбулар калмышдыр.

Габдулла хәзрәт безем гасырымызда Эстәрлебашында имам булып, 1909 нчы елда хаҗ сәфәренә барып һәм Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә зиярәт кылып, сәламәт кайтды. Соңра 1919 нчы елга кадәр имамлыкга әда итеп[3], октябрь аенда дарелбәкайә күчде. Мәрхүм хәзрәт аз сүзле, үзенең вазыйфасын бик яхшы вәгазь-нәсыйхәт кылып, гаять истикамәтле[4] кеше иде. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә мәдфүндер. Бик тугры сүзле, һичкемдән курыкмый хаклыкны әйтер иде.

Гобәйдулла Эстәрлебашында имам булып, һәм ахун, мәдрәсәләр мөдире булып, азрак дәрес белән дә шөгыльләнеп, 1920 нче ел февраль аенда вафат итде. Аллаһ мәгъфирәт итсен. Гүзәл холыклы кеше булса да, күбрәк вакыт балаларның ялган сүзләренә ышаныб, бәгъзе адәмләргә кинә тотып, байтак халыкны наразый кылды[5]. Мәгълүмеңездер, бай балалары, ишан мәхдүмләре[6] бар да шулай булып, ахмаклыкда калдылар, кешеләрне нахак сүзләр белән аталарына сөйләп, тикшермәсдән шул кешеләргә хөкем кылырлар иде. Аллаһ мәгъфирәт әйләсен, яшь вакытында Чакмак Габдулла хәзрәт мәдрәсәсендә булып укымышдыр.

[1] Гран – граница, чик.
[2] Мөсадәрә кылынып – кулга төшерелеп.
[3] Әда итеп – үтәп.
[4] Истикамәтле – намуслы.
[5] Наразый кылды – канәгатьсезлек уятты.
[6] Мәхдүмләре – балалары.

Хәбибулла бине Мөхәммәдхарис әүвәл Эстәрлебашында укып, соңра Минзәлә өязе Олуг Чакмак Габдулла хәзрәт мәдрәсәсендә укып, соңра Бохараи шәрифкә барып, яхшы галим вә мөдәррис булып кайтып, Эстәрлебашында ничә еллар бик яхшы дәрес укытып, Эстәрлебашының мәсҗед-мәдрәсәләрен бик яхшы гыймарәт кылдырып[1] һәм ташдан суханә салдырып, Эстәрлебашының гыйлем вә башка дәрес вә шәкердләре күп булып, соңгы вакытда голүме диния тәрәкъкый иткән вакыт булды. Мәзкүр Хәбибулла хәзрәт гыйлем сөюче һәм дә бөтен мәсҗед вә мәдрәсәләр алдына агачлар утыртыб, һәр мәдрәсәнең алдына фонарь якдыртып, суханәләр эченә госел вә тәһарәте өчен сулар йылытдырып, барын да яхшы күркәм юлга салган иде. Мәрхүмнең бакыят салихатларындан[2] булса иде, амин. Фәкыйреңез дә бер ике-өч еллар дәрес укыдым, Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин. Мәрхүм Эстәрлебашында мәүгуд әҗәлне тәмамлап[3], Эстәрлебашның олуг мәкъбәрәсендә бабалары Нигъмәтулла хәзрәтнең аяк очында дәфен кылынмышдыр. Өстендә язылмыш ташы һәм бардыр. Варисларындан Габдрахман вә Зәйнәб вә Габделгалим вә Габдулла исемендәдер. Габдрахман Мәккәи-Мөкәррәмәдә 1908 нче миладиядә ваба хәстәлеке белән вафат булып, Мәккәи-Мөкәррәмәнең җәннәтел-мәхәлләсендә борадәре Габделмәҗид бине Мөхәммәдхарис кабере өстенә дәфен кылынды. Мәккәи-Мөкәррәмәдә вакытымда үзем һәм шәрикем Мәҗид Мөхәммәд Әхмәров белән бергә тәгаен тәҗвиз кылып дәфенләдек, Аллаһның мәгъфүр бәндәләрендән улсын, амин. Гыйлем тәхсил юлында әманәт җанны тәслим кылды.

Бохараи шәрифдә Мәрҗани хәзрәтләре белән бер гасырда укымышдыр. Вафаты 1896 нчы миладидә октябрь ахырында булса кирәк, җеназасында хазир булдым.

Зәйнәб Гобәйдулла Мөхәммәдхарис углы Габдерәхимгә тормышка чыгып, Габдерәхим яшьлекдә вафат булып, Зәйнәб Ташкендка барып, анда вафат булып калды. Габделгалим соңгы Эстәрлебашның олуг мәсҗедендә имам булып, инкыйлаб мөнәсәбәте белә мәхбүс[4] булып, 1930 нчы елда Уфа хибесханәсендә[5] вафат булды.

Габдулла яшь вакытында Эстәрлебашында укып, соңра Казанда Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә (Мөхәммәдия)дә укып, соңра фалиҗ зәхмәтенә дучар улып, эшдән калды. Бу көнне сәламәт ике углы бардыр. 1954 нче елда йортында булдым.

[1] Гыймарәт кылдырып – төзеп.

[2] Бакыят салиатларындан – мәңгелек изгелекләренән.

[3] Мәүгуд әҗәлне тәмамлап – вафат булып.

[4] Мәхбүс – тоткын.

[5] Хибесханәсендә – зинданында.

Мөхәммәдшакир Мөхәммәдхарис углы Эстәрлебашында бераз укыгандан соңра, бераз Чакмак мәдрәсәсендә укып, соңра Оренбург "учительская школа"сында укып, тәмам кылмасдан, Эстәрлебашына кайтып, җәмәгать алып, тормыш кыла башламышдыр.

Атасы Мөхәммәдхарисдан мирас булмыш биш йөз десятинә кадәр тупракы булып, Эстәрле суы буенда Кунакбай авылында якын йирдә иде. Шунда утар кылып, бераз иген сачдереп, янә Эстәрлебашында йорты алдында бер кибете булып, бераз сәүдә эше белән дә шөгыльләнеп яшәде. Табиблыкдан бераз хәбәрдар булу сәбәпле, рәнҗүләргә дәва биреп, шулай ук шәкердләргә күп ярдәме бар иде, чөнки ул заманларда авыл йирләрендә шифаханә вә табиблар булмау сәбәпле, бу халык өчен зур ярдәм булыр иде. Аллаһ әҗерне насыйп итсен, амин. Бәгъзе вакытларда хөкүмәт эшләрендә, комитетларда вакытлы хезмәтдә булыр иде. 1905 нче ел - Русиянең инкыйлаб башланган елларында, государственный думада өч мәртәбә сайлануда әгъза булып, Петербургда эшләде. Дума ябылу белән андан кайтды. Мәрхүм бик юмард иде. Шулай да әхлакы ким иде, бәгъзе вакытларда бер дә гаепсез булу сәбәпле, адәмләрне рәнҗетү кебек хәлләре булып үтде. Аллаһ гафу итсен. 1917 нче елның олуг инкыйлаб тулкыны сәбәпле, 1924 нче елында хөкүмәт тарафындан боерык булып, ихтыяри рәвешдә Эстәрлебашындан китүгә мәҗбүр булды. Йорт-йирендән башка өе әсбаблары алынмады. Үзе сатып файдаланды. Соңра Оренбург шәһәрендә торып, берничә еллардан соң әманәт җанны тапшырып, Оренбургның олуг мәкъбәрәсендә дәфен кылынмышдыр.

Аллаһның рәхмәтендә булсын. Оренбург шәһәре мәхәлләсендә Касыйм дигән адәм: "Үзем, янә өч кеше бәрабәр ат-арбам белән алып барып, дәфен кылдым", - дия сөйләде. Борынгы җәмәгате вафат булып, икенче җәмәгате Агыйдел буе Йомран карьясендән булып, андан Хәбибулла исемле углы калган иде. Сәламәтме-юкмы - мәгълүм түгел. Борынгы җәмәгате Стәрлетамак Рәмиев фамилиясендә Маһитап исемле иде, Габделхаликъ кызы булса кирәк. Андан калган сәламәт бу көндә Эстәрлетамакда Мәрьям, Хөршидә, Әминә, Уфада Хәлимә, Сәмәркандда Фатыйма исемле кызлары бардыр.

Хәбибулла Мөхәммәдхарис углы әүвәлдә Эстәрлебашында укып, Буби карьясендән килмеш Габдулла Нигъмәтулла хәзрәт углы (хаҗи хәлфә дия мәшһүрдер) дигән кешедән укымышдыр, соңра Чакмак карьясендә Габдулла хәзрәт Габделгафур мәдрәсәсендә укып, соңра Бохараи шәрифкә барып, хәтме көтеб кылмышдыр,[1] 1881 нче елларда булса кирәк. Мәрхүм хаҗи хәлфә

[1] Хәтме көтеб кылмышдыр – укуны тәмамлый.

Нигъмәтулла углы Эстәрлебашында йикерме ел кадәр дәрес укытып, камил иҗтиһад берлә тәгълим кылып, 1883 нче миладиядә рамазан шәрифдән соң август аенда хаҗ сәфәренә китеп, хаҗны тәмамлап, рәнҗү уларак Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә сәфәр итмешдер, юлда рәнҗүе артып, 1883 милади йәүмел-гашурәдә, 2 нче ноябрь, Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә вафат итеп, кабер шәрифе Мәдинәдә Җәннәтел-бакыйгдыр. (Рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән). Мәрхүм галим вә фазыл, хосусан галим осуле фикъһедә маһир улып, шул вакытларында төрки телендә сарыф китабы язмышдыр. Мәшһүр Буби карьясендә борадәре Нигъмәтулла хәзрәтнең мәхдүме Габдулла Буби безем Русиядә голүме җәдидә ирләргә һәм кызларга махсус осуле җәдидә берлән мәдрәсәләр ачып, беренче милләт хадиме булып хезмәт итеп, үз гомерендә Русия татарларының яхшы гына мөрәббисе[1] булды. 1907 миладидә бәрабәр хаҗ Бәйтуллага килеп, махсус Мәккәи-Мөкәррәмәдә гар шәрифкә барып зиярәт итдек. Гар шәрифнең эченә керү белән ике рәкагать нәфел намазы кылып, соңра шушы урында ислам диненең дөньяга таралуына сәбәп булмышдыр дия нотык сөйләде. Аллаһның рәхмәтендә булсын.

Габделмәҗид Мөхәммәдхарис углы әүвәл Эстәрлебашында укып, соңра Минзәлә өязе Чакмак карьясендә Габдулла Габделгафур хәзрәт мәдрәсәсендә укып, соңра 1886 нчы миладиядә Бохарага барып, голүме диния укырга тотынды. 1890 нчы елда сәламәт кайтып, Җаек суы буенда Илек карьясендә могтәбәр сәүдәгәрләрдән Гобәйдулла хаҗи Килдишев дигән кемсәнәнең Мәхфүзә исемле кызын никахлады. Гобәйдулла хаҗи үзенең хәраҗаты[2] белән Бохарадан кайтарып, кызны бирмешдер. Июнь аенда туйлары булып, сентябрь аенда шул елны янә тәкмиле голүм (ягъни укуларны тәмамлау өчен янә Бохараи шәрифкә барып, 1892 нче елда Эстәрлебашына кайтып, шәкердләргә дәрес әйтә башлады. Мәрхүм Габделмәҗид мәхдүм ачык йөзле, юмард табигатьле, хуш мәҗлес адәм иде. Дәрес юлында яхшы тәкъририрле булып,[3] шәкердләр мәхәббәт кылырлар иде. Мәзкүр Габделмәҗид мәхзүмне бән фәкыйрь дә күреп беләмен. Ул вакытда мин 10 яшемдә идем. Атамыз мәрхүм белән һәрвакыт өлфәт кылып сөйләшер иде. Мәрхүм 1893 нче сәнә март унында хаҗ сәфәренә юнәлеп, әүвәлдә Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә барып, борадәре Габделкадыйр белән күрешеп, (бу вакытда Габделкадыйр Мәдинәи-Мөнәвәрәдә укуда [...] мәдрәсәсендә торыр иде). Соңра борадәре белән Мәккәи-Мөкәррәмәйә барып, хаҗны тәмам кылып, 1893 нче милади 14 нче июньдә 12 нче зөлхиҗҗә аенда ваба рәнҗүе белән 10 сәгать эчендә әманәт җанны тәслим кылып, Мәккәи-Мөкәрәмәдә Җәннәтел-Мүәллә дигән

---

[1] Мөрәббиисе – тәрбиячесе.

[2] Хәраҗаты – чыгымнары.

[3] Тәкърирле булып – аңлатып.

мәкъбәрәсенә борадәре Габделкадыйр дәфен кылып, башына таш яздырып куймышдыр. Мин фәкыйрь дә каберенә барып зиярәт кылып, шуның кабере янына борадәре Габдрахман Хәбибулла углыны дәфен итдек. Юкарыда язылмыш иде. 1907 нче елда шулай ук ваба рәнҗүе булып, күп хаҗилар мәрхүм булып калдылар. Фәкыйрь дә бу вакытта Мәккәи Мөкәррәмәгә хаҗ нияте белән Мәдинәи-Мөнәүвәрәдән килмеш идем. Аллаһ мәгъфирәт әйләсен, амин.

Эстәрлебаш мәкъбәрәсе мәрхүм Габделмәҗид Харис углының садакаи җариясендән [...] таш белән бер километр әйләнәсендә булган ихатасы бу көнгә ошбу таш ихата сәламәтдер.

Габделкадыйр Мөхәммәдхарис углы яшь вакытында Эстәрлебашда укып, соңра Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә тәхсиле голүм кылу нияте белән барып, [...] мәдрәсәсендә тормышдыр. Сәламәт Эстәрлебашка кайтып, бер-ике ел шәкердләргә голүме кыйраәт тәгълим һәм аз вакыт башка дәрескә шөругъ кылса[1] да, боларны куеп, дөнья эше белән мәшгуль булып китте. Аталарындан мирас калмыш йирләрен эшләтеп, Эстәрле суы буенда мәшһүр Николаевка дигән рус авылының түбән ягында утар корып, игенчелек вә малчылык белән мәгыйшәт итте. Зур гына дәүләт иясе булды. Ватанпәрвәр кеше иде. Бик мохтаҗларга ярдәм бирер иде. Мадди вә мәгънәви ярдәм итәр иде. Беренче җәмәгате Оренбургда Гариф Дәүләтшин кызы Мәфтүхә иде. Бонда вафатындан соң, Эстәрлетамак сәүдәгәре Гыйлаҗетдин бине Хисаметдин Баязидов дигән кешенең Әсмабикә исемле кызын никахлап, ахыр гомерендә Үзбәкстанда Нәманган шәһәрендә булып, әманәт җанны шунда җәнаб хакга тапшырды, Аллаһ мәгъфирәт әйләсен, галим галлям вә башка фәкыйрьләргә ярдәмче иде һәм дә Эстәрлебашының ничә еллар мәсҗед вә мәдрәсә вә су юлларын карап, барча гыймарәтләрне дә кылды. Хода садака җариясендән насыйп итсен. Амин. Мәфтүхә дигән җәмәгатьдән бер Габделгазиз исемле углы бар иде. Услы карьясе Хәмзин фамилиясендән Локман исемле кешенең Нәфисә исемле кызыны никахланмыш иде. Бу көндә сәламәт Каракалпак областендә торса кирәк. Әсмабикәдән бала булмады.

Яхшы кеше иде, икътисад белән, бик тугрылык белән дөньяда тереклек кылды.

Харис хәзрәтдән калган кызлар Зөбәйдә Эстәрлетамак Габдрахман Кәмаледдин хәзрәт углы Ногаев никахында булды. Зөбәйдә 1911 нче миладиядә хаҗ сәфәренә барып, сәламәт кайтды. Зөһрә Эстәрлетамак сәүдәгәре Габдулла Мөхәммәдзариф углы Үтәмишев никахында булып, бер ир, бер кыз баласы булды. Габделкәрим исемле углы апасы Зөбәйдә белән

[1] Шөругъ кылса - башласа.

хаҗ сәфәренә барып кайтды. Безнең гасырымызда Эстәрлебашның мәшһүр Тукаевлар ошбу язылмышлар булды, янә башка балалары булса да, инкыйлабдан соң төрле тарафка таралып китделәр.

Мөхәммәдхаррас Нигъмәтулла углы 1814 нче ел миладидә тугып, 1844 нче елда Бохарага тәхсиле голүме диния өчен барып, 1856 нчы ел сәламәт кайтып, Эстәрлебашында имам булып һәм дәрес әйтү белән шөгыль булды. Күп вакыт рәнҗү булып, 1871 нче елның 30 нчы ноябрендә дарелбәкая рихләт әйләде. Мәрхүм галим вә камил бик истикамәтле, тугры сүзле булып һәм сахибе гыйззәт[1] булмышдыр. Аллаһ рәхмәт әйләсен. Мәрхүмдән Зәйнәб исемендә бер кыз, Габдерәхим исемендә бер углы калмышдыр. Аналары Һәдия абыстай сабыйлыкдан карап үстереп, Зәйнәп Уфа Каргалысы Гыйсмәтулла Еникеев дигән кешегә тормышка чыкды. (Уфа тимер юлында начальник станции булып эшләр иде). Әмир-Әхмәд исемле углы бар иде. Рус кызы никахланмыш иде. Эстәрлебашына 1910-1911 нче елларда беренче мәктәб һәм больница салдыручы һәм почтаханә кертүче Габдерәхим Лотфулла углы Тукаев булды. Күп кыенлык белән салдырды, мәхәлләле хәзрәтләр халыкга игъва биреп,[2] салдырмау тарафында булдылар.

Габдерәхим Лотфулла углы укыту вакытына йитү белән Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укып, соңра Эстәрлебаш рус мәктәбендә укып, тәмамлап, халык эшләренә катышып, соңгы вакытында Эстәрлетамак земство идарәсенә рәис могавине[3], соңра рәис булып, 10 елдан артык хезмәт итде. Мәрхүм бик тугры юлда булып, бөтен халыкга мәктәпләр ачдырып, больница кеби вә башка күперләр кебек һәм агырлык елларында, ачлык елларында фөкаралар[4] өчен, шундай олуг хезмәт күрсәтде, бик гакыллы, тугры сүзле, эшендә бик мәхкәм[5] иде. Бөтен көчене артка калган мөселманларны агарту юлында хезмәт итде. Эстәрлетамакдан Газзә исемле бер җәмәгать алып торса да, күп тормасдан, мәхәббәте булмау сәбәпле, голүм эш-шәргъ аерып, ахыр вакытына кадәр ялгыз торды, араларында бер кыз калып, Маһисәрвәр исемле, бәлягатькә йитешү[6] сәбәпле, Эстәрлетамак шәһәре Гани Хәлфин дигән кешегә тормышка чыкты, соң вакытда Уфа шәһәрендә торадыр. Хәлфин мал докторы булып хезмәт кылса кирәк. Мәрхүм Габдерәхимнең аталарындан мирас булып калмыш беркадәр йире һәм Николаевка-Сергеевка дигән рус авылларының ас ягында, Эстәрле суы буенда, тегермәне бар иде. Мәрхүм

[1] Сахибе гыйззәт – хөрмәт иясе.
[2] Игъва биреп – начарлыкка өндәп.
[3] Могавине – ярдәмчесе.
[4] Фөкаралар – ярлылар.
[5] Мәхкәм – төгәл.
[6] Бәлягатькә йитешү – үсеп җитү.

Русиянең олуг инкыйлабына сәбәбендән мәзлум нахак[1] бәлагә дучар була. 1930 нчы миладиядә мәхбүс хәлендә мәрхүм булса кирәк. Аллаһның рәхмәтендә булсын, вакытсыз югалды. Гомерендә халык өчен тырышып, иткән хезмәтләрне Хода садакаи җариядән әйләп, гөнаһларына кәффарәт[2] булса иде, амин.

***Эстәрлебаш вакытында мәшһүр хәлфәләр түбәндә:***

1. Зәйнулла Хөсрәүшир углы Галикәев Уфа янында Арыслан авылындан килеп, Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укып, яз көнләрендә авылына кайтмый олуг хәзрәтләре Харис Нигъмәтулла углының һәрдаим хезмәтендә булып, бөтен хуҗалык эшләренә баш булып, ягъни әмир булып йөрмешдер. Шундан әмир хәлфә ләкабе[3] алып, калмышдыр. Соңра Харис хәзрәткә мөрид булып, гыйльме батыйн юлына керешеп, Харис хәзрәт һәм Хәррас Нигъмәтулла хәзрәтләр заманында булып, 1810 нчы елда тугмышдыр. 1827 нче елда Эстәрлебашка килмешдер. Соңра, Мөхәммәдхарис вафаты соңында, Чиләбе Габделхәким хәзрәтдән шәехлекгә рөхсәт алып, Эстәрлебашында шәехлек кылмышдыр. Яше туксан бишдә 1905 елларда дарелбәкая рихләт идеп, Эстәрлебашының олуг мәкъбәрәсендә дәфен кылынып, ак ташдан ихатасы һәм язулы ташы бардыр, рәхмәтуллаһи галәйһә васигатән. Безнең гасырымызда булып, мәрхүм хакыйкый шәех буларак кеше иде. Дөньяны үзенә йитәр кадәр иген сачеп, тереклекдә кадер әл-кифая[4] маллары булып, чын кеше булып яшәде. Мөридләрне кушып, хезмәт итдермәде, ярдәмгә бер-ике ярдәмче тотар иде. Һәркемне бертигез күреп, андай-мондай халык арасына күп катышып йөрмәде, мәҗлесләрдә артык сүз сөйләмәс иде. Авылга йөреп, мөридләрдә кунак булып йөрмәде. Бәгъзе вакытларда гына зуррак туй кеби мәҗлесләргә чакырсалар, бик сирәк вакытда гына барыр иде. Башка шәехләр кебек нәфсе зур булып, корсак симертеп йөрмәде. Аллаһның рәхмәтендә булсын, бәлки халис[5] шәехлекгә охшыйдыр иде.

Мәрхүм Зәйнулла хәзрәтнең варисларындан калмыш Гобәйдулла, Хәйрулла, Лотфулла, Гатаулла исемле угылларыдыр. Кызлардан Хөснежәмал, Өммегөлсем, янә Шәмсеҗәмал – болар беренче җәмәгатендән булып, ул вафат соңында Йөзәй авылы Оренбург өязендән Камилә исемле икенче җәмәгать алып, бондан Лотфулла, Мөкәррәмә, Хәбибулла атлы варислары калмышдыр. Әмир хәзрәтнең (хәлфә хәзрәт дип йөртәләр) 1 нче углы Гобәйдулла Галикәев яшь вакытында Эстәрлебашында Хаҗи хәлфә (югары язылмыш) Габдулла Нигъмәтулла углы Бубидан дәрес укып, соңра

---

[1] Мәзлүм нахак – хаксыз рәнҗетелеп.

[2] Кәффарәт – гөнаһтан арыну өмете белән эшләнгән эш.

[3] Ләкабе – кушаматы, исеме.

[4] Җитәрлек.

[5] Халис – чын.

Бохарага барып, берничә еллардан соң гыйльме заһир вә батыйнны тәхсил кылып кайтып, 1880 нче елларда булса кирәк, Урал областе Ялпактал (Сламихин) дия Казачий авылында имам вә мөдәррискә тәгъйин кылынып[1], ахыр гомеренә кадәр шунда истикамәт кылды. Берничә мәдрәсәләре булып, күбрәк казакъ таифәсендән һәм безем татарлардан күп кешеләр дәрес укып чыкдылар. Мәрхүм ачык йөзле, миһман[2] сөюче сәхи[3] адәм иде. Шул ук Ялпакталда борынгы имам Гатаулла Абдуллов дигән мулланың Мөнәвәрә исемле кызыны никахланып гомер итмешдер. Мәзкүр Гатаулла мулла үзенең имамлык вазыйфасыны ташлап, урынны бу Гобәйдулла хәзрәткә тапшырмышдыр. Гобәйдулла хәзрәтнең варислары 1 нче углы Һидиятулла вә Хәбибулла вә Габделгазиз, Габделһади вә Габделбасыйр вә Габделбарый исемендә, бер генә кызы Гайшә исемендәдер. Мөнәвәрәнең вафаты соңында Исәнбай авылының Мөхәммәдгали Исәнбаев дигән кемсәнәнең кызы Фәрхисорурны толлата никах кылып, Габделбарый шушы Фәрхисорурдан тугмышдыр. Бу никахы 1910 нчы елларда иде.

Һидиятулла яшь вакытында шул як Ялпактал мәдрәсәсендә укып, соңра Оренбург Каргалысы үзенең борадәре Хәйрулла бине Зәйнулла хәзрәт мәдрәсәсендә укып чыкды. Соңра дөнья эшләре белән мәшгуль булып, Уральски шәһәрендә Габбас Белоусовның углы Гобәйдулла дигән кешенең Сәгадәт исемле кызын никахлап, болар арасында берничә балалар булып, соңра вакытда Габделхәмид, Габделмәҗид исемендә игез балалар Бохарада техникум мәктәбендә укытучы булып, соңра Каракалпак җөмһүриятендә Нукус шәһәрендәдерләр. Һидиятулла Русиянең олуг инкыйлаб мөнәсәбәте белән Үзбәкстан тарафына күчеп, хөкүмәт эшләрендә, бухгалтер эшләрендә эшләп, соңгы вакытында Каракалпак Нукус районында ашказаны рәнҗүе белән әманәт җанны Ходага тапшырмышдыр, Аллаһ мәгъфирәт әйләсен, амин. Мәрхүм фәкыйреңез илә күп вакытлар бер-бергә йөреп һәм сәфәрләрдә булып, дустанә булып яшәдек. Бик ачык йөзле, халыкка хезмәт сөюче иде.

Хәбибулла Галикәев яшь вакытында укуга Истанбулга барып, яшьләй вафат булды.

Гайшә Казакъстан районында Яңа кала (Новая Казанка) шәһәрендә олуг сәүдәгәрләрдән Шәмседдин хаҗи Үтәкәевның углы Мөхәммәдҗанга тормышка чыгып, олуг инкыйлаб вакытында Азияга барып вафат булды. Соңгы вакытында күп хурлыкларга дучар булып вафат итде. Гайшә кайдадыр, Габделгазиз Галикәев яшь вакытында Ялпактал мәдрәсәсендә бераз укып, 1909-1910 нчы елларда мин мөгаллим булып торган вакытда

[1] Тәгъйин кылынып – билгеләнеп.
[2] Миһман – кунак.
[3] Сәхи – юмарт.

бездән Коръән әл-кәрим хифыз кылып, соңра Каргалы Хәйрулла хәзрәт мәдрәсәсендә барып, анда янә тәкрар кылып кайтып, Ялпакталда хәтем кылып, 1921-1922 нче елларда ачлыкка дучар булып, Самара (Куйбышев шәһәрендә) вафат итмешдер.

Габдессабир Габделһади 1909-1910 нчы елларда минем алдымда берничә сыйныфда укып, соңра кайдадыр яшьли вафат булмышдыр. Габделбари Галикәев Шура хөкүмәте мәктәбендә Мәскәүдә дә укып, 1950 нче елларда Башкортстан җөмһүрияте Дәүләкән станциясендә торадыр дип ишетдем, ахыры мәгълүм түгел.

Юкарыда язылмыш Гобәйдулла хәзрәт мин фәкыйрьгә ярдәм кылып, Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә йибәрде. Шушы мәрхүмнең ярдәме белә дүрт ел Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә укып, Корънел-кәримне хифыз кылып, сәламәт кайтдым. Безнең вәли нигъмәтемез булып, мондый хәерхаһ юлына җәнабе Хак рәхмәт вә мәгъфирәт кылып, кылган садакаи җарияләрне йәүмел-җәзада Хода алдында кылсын. Амин. Гобәйдулла хәзрәт Ялпакталга 90 километр [ераклыкта] Александр Гай (Алмалык) шәһәрендә вафат булып, кабере шундадыр. Тәхминән[1] олуг инкыйлаб вакытында шул урынга нәфи кылынып[2], шунда бераз вакыт тормышдыр. 1929 нчы елларда булса кирәк, җәмәгате Мөнәвәрә Эстәрлебаш Харрас хәзрәтнең Рабига исемле җәмәгатендән тугмышдыр. Безем гасырымызда Ялпакталда вафат идеп, кабере шундадыр.

Әмир хәзрәтнең икенче углы Хәйрулла яшь вакытында Эстәрлебашда хаҗи хәлфә мәдрәсәсендә укып, соңра Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә барып, Баб әс-сәламдә Мәхмүдия мәдрәсәсендә ничә еллар укып, “Кыйраәт сәбга” вә гашәрә белән Коръән әл-Кәримне хифыз кылып, сәламәт Эстәрлебашка кайтып, Оренбург Каргалысы Өммебай мәсҗедендә имам вә мөдәррис булып, күп шәкерд тәрбияләп, бик күп Коръәнхафизләр йитешдереп, гомер буенча казакъ вә татар вә башкорд шәкердләренә гыйлем үгрәтү юлында булды. Безем гасырда да мәдрәсәләрендә 6-7 йөз шәкерд укыр иде. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Олуг галимләрдән иде. Кылган иҗтиһадлары ахырында Хода каршысында савап булсын, амин. Русиянең инкыйлабы мөнәсәбәте белән нәфи кылынып, нәҗат соңында[3] Ташкенд шәһәрендә вафат булды.

Вафатына кадәр Ташкендда Габдулла исемле углы тәрбиясендә булып, Хәйрулла хәзрәт (1853 елда туган) 1934 елның 18 гыйнварында вафат, Ташкенд шәһәрендә дәфен кылынды. Күп голамәләр җыелып, мәрхүмгә хәтем кылып, догалар кылмышдыр. Габдулла Ташкендга якын Бустандыкда

[1] Тәхминән – якынча.
[2] Нәфи кылынып – сөрелеп.
[3] Нәҗат соңында – котылганнан соң.

бухгалтер булып эшләр иде. Хәзерге көндә Бустандыкда сәламәтдер. Мәрхүм Хәйрулла хәзрәт белән гасырымызда күп мәҗлесләрдә булып, сөхбәтләрдә булдык. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Җәмәгате Уральски шәһәрендән Габбас Белоусов кызы иде. Хәйрулла хәзрәт: “Эстәрлебашында Гали хәлфә, Мәҗид карыйдан башка дөрест кыйраәтле кеше юкдыр”, - дип әйтә икән. Борадәре Хәбибулла мәхзүм шулай дип нәкыль итде. Хәйрулла хәзрәт мәдфүн Ташкенд Чыгтай зияратында, каберендә кирпеч ихата бар.

Лотфулла Галикәев уку эшендә аз булып, дөньяга бирелеп, игенчелек вә текермән кебек эшләр белән мәшгуль улмышдыр. Күндерәк суы буе Шипай дигән авылда тегермәне булган, шунда торганда төнлә белән начальник становой килеп, арыкның күпере начар булса кирәк, бу начальник йоклаган Лотфулла Галикәевне уятып, “ник күперне юнәтмәдең” дип ачуланса кирәк. Бу мәрхүм бераз каршы итсә кирәк. Шуның өчен Лотфулланы револьвер белән атмышдыр. Шундан мәҗрух булып[1] калып, бер ай соңра җан тәслим кылмыш. Мәзлум[2] булып вафат. Аллаһ рәхмәт вә мәгъфирәт кылсын, амин.

Гатаулла Галикәев яшь вакытында Эстәрлебашында укып, соңра Бохарага барып, тәхсил кылып кайтып, Әстерхан губернасы Яңа кала шәһәрендә имам вә мөдәррис булып, тәгъйин кылмышдыр. Мәхәлләсе әтрафында казакъ халкы күп булып, шунда ничә еллар истикамәт кылып, зур гына дәүләткә малик булып, Русиянең олуг инкыйлабында вафат улмышдыр. Соңгы җәмәгатендән булган углы һәм Лотфулла исемендә булып, Каргалы мәдрәсәсендә укып, соңра сәүдә белән мәшгуль булып, инкыйлаб вакытында Азия тарафында йөреп кайтып, 1938 нче елларда Эстәрлебашка якын Дүртөйле дигән кечкенә башкорд авылында яшәгән. Кызына кайтдыгына Азиягә китеп, шунда вафат.

Әмир хәзрәтнең кызы Мөкәрәмә Каргалы мәдрәсәсендә укыган, шул ук шәһәрнең Фатих хәлфә Фәсыйх углына тормышка чыкмыш. Фатих яхшы гына укымышлы булып, Оренбург өязе Нитбаш Муса авылына имам булып, соңра Ак Идел буенда Эстәрлетамак өязе Җиргән авылында имам булып, дини мәрасимләрне[3] башкарып торды. Җиргәндә бу мәхәллә чуаш милләтендән булып, 1905 нче елларда исламиятне кабул кылып, рәсми мәсҗед салмышдыр. Йитмеш хуҗалык булып, шунларга дин мөрәббиясе[4] булып, Русиянең олуг инкыйлабына кадәр хезмәт идеп, соңра һиҗрәткә мәҗбүр булып, Азиягә һиҗрәт кылып, Ош шәһәрендә икамәт итмәкдәдер[5].

---

[1] Мәҗрух булып – яраланып.
[2] Мәзлум – рәнҗетелгән.
[3] Рәсми эшләр.
[4] Мөрәббиясе – тәрбиячесе.
[5] Икамәт итмәкдәдер – яши.

Әмир хәзрәтнең икенче абыстаендан Хәбибулла бу һәм Каргалы мәдрәсәсендә укып, Йөзәй авылына якын Тимербай авылында имам булып, соңра Уфада зиярәт мәхәлләсендә имам булып торып, берничә елдан соң имамлыкдан юшанып[1], үзенең ихтыяры илә Ак Идел буенда Мәнәвез дигән мәсҗеденә имам булды. Хәлифә хәзрәт (әмир хәзрәт) кызы Хөснеҗәмал Өршәкбаш Кармалы авылында Хәбибрахман Исхаков муллага тормышда булып, мондан Габдерәхим исемле углы булып, соңгы көн шул ук Карамалыда имам булып, Русиянең олуг инкыйлабы вакытында хибесханәдә вафат булмышдыр. Янә икенче углы Габделмәҗид бине Хәбибрахман Каргалы Хәйрулла хәзрәт мәдрәсәсендә Коръәнхафиз кылып, соңында шул ук Каргалыда борадәре Хәйрулла хәзрәткә могавин[2] имам булып торды. Инкыйлаб вакытында хөкүмәт тарафындан нәфи кылынып, соңгы көндә Уфа шәһәрендә тормыш кыладыр. Җәмәгате исә югарыда мәзкүр Лотфулла Галикәевдән калмыш Һәдия исемле кызны никахлап, бу көнгә кадәр сәламәтдер, балалары юк.

Әмир хәзрәтнең бер кызы Шәмсебану исемендә Кәмәлек буенда бер башкорд авылында Сәгъди исемле муллага тормышка чыгып, шунда вафат булмышдыр. Бер угыл баласы булса кирәк.

Әмир хәзрәтнең Гөлсем исемле кызы Оренбург өязе Салмыш буенда Йөзәй дигән авылда Габденнасыйр Урманов дигән кешегә тормышка чыгып, шунда вафат улмышдыр. Урмановның Йөзәй авылында Салмыш суында текермәне булып, шуның белән гомер кичермешдер, яхшы гына дәүләт ясый булгандыр. Габделкәрим Хәбибрахман һәм Фәйзрахман исемендә угыллары бар иде. Фәйзрахманы хафизе кәламулла[3] булып, соңра Истанбулда укып, шунда вафат булып калса кирәк.

***Эстәрлебашның безнең гасырымызда һәм борынрак заманаларында булып үткән мәшһүр хәлфәләрдән (дәрес әйтүче мөгаллимләр) түбәндәге затлардыр***: 1. Хаҗи хәлфә, исеме Габдулла Нигъмәтулла углы, Пермь губернасы Сарапул өязендән килеп, Эстәрлебашында укып дәрес әйтмешдер. Соңра, хаж сәфәренә китеп, Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә вафат булып калмышдыр, зияраты Җәннәтел-Бакыйгда.

2. Хәлим хәлфә Әмиров Бөре өязе Борай авылында туып, Эстәрлебашында укып дәрес әйткән, кайтып, Борай карьясендә вафат булмышдыр. Бер вакытлар Сибириядә Томский шәһәрендә имам да булып торды, соңрак, андан күчеп, Борайга кайтып, ахун имам булып, шунда вафат

[1] Юшанып – бушап, бу очракта: китеп.
[2] Могавин – ярдәмче.
[3] Хафизе кәлямулла - Коръәнне күңелдән белүче

итде. Аллаһның рәхмәтендә булсын, хуш сүзле, ачык, юмарт кешеләрдән иде. Сәламәт вакытында күреп сохбәт итдем[1].

3. Мөхәммәдьяр хәлфә Бәләбәй өязе Чыкдай вулысындан килеп, Эстәрлебашында укып, соңра дәрес әйтмешдер, голүме диния вә гарәбиятдә яхшы галим булса кирәк. Аллаһүммә әгъфәһү.[2]

4. Мөхәммәдьяр хәлфәдән Әбүнәгыйм исемендә бер угыл калып, ул һәм шул ук Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укып, голүме [...] вә гакаид фәнләрендән яхшы галим булып, дәрес әйтеп, күп кенә муллалар чыкарды. Гомерендә игенчелек вә малчылык белән һәм сәүдә юлында кәсеп итеп, гомер буенда дәрес укытып һәм сахибе дәүләт булып, 1925 елларда вафат булып, Эстәрлебашның олуг мәкъбәрәсендә дәфен иделмешдер. Аллаһның рәхмәтендә булсын.

5. Гаид хәлфә бине Фәйзула Бәләбәй өязе Слак авылындан килеп, Эстәрлебашында укып, соңра хәлфә булып дәрес итмәмешдер, бәлки 1 нче мәртәбә булса кирәк, Эстәрлебашында кибет ачып, сәүдә кыла башлаган яхшы дәүләт иясе булып, садакаи җариясендән Эстәрлебашында биш мәдрәсә бина кылып, вафаты соңында 100 десятинә тупрак Эстәрлебашның мәсҗед һәм суханә, янә Слак авылында 6 мәхәллә мәсҗедендә файдалану өчен вакыф итеп калдырды. Мөлкендә Эстәрлебаш белән Максуд авылы уртасында дүрт йөз десятинә йире бар иде. Эстәрле суы аша Комбазы суына кадәр иде. Вакытында яхшы утарлар корып, игенчелек белән мәгыйшәт итде. 1895 нче елларда вафат булып, Эстәрлебашның олуг мәкъбәрәсендә дәфен кылынмыш, башында язулы ташы бар. Бу хәлфәне сәламәт вакытында күреп беләм. Алдырмыш кыйраәтне хода кабул кылып, бакыят әс-салихатләрендә[3] әйләсен, амин. Мин фәкыйрь дә бу хәлфәнең мәдрәсәсендә 1903 нче елга кадәр укып ятдым. Аллаһ мәгъфирәт әйләсен. Амин.

Үзенең милек булган йирне Эстәрлебаш ягындан Юкәлекүл дигән чокырдан башлап, Эстәрле суы аша Комбазы тугаена кадәрле бер аршин тирәнлегендә үр (канау) казып чикләп куйды, хәзер дә канавы мәгълүм булып торадыр.

6. Зәйнулла хәзрәт Хосраушир углы Уфа өязе Арслан авылындан, тәрҗемәи хәле юкарыда язылып үтде, ләкабе – Әмир хәзрәт.

7. Безнең атамыз Гали хәлфә Әсан-Али углы Айдабулов казакъ таифәсе Әстерхан губернасына караган Бүкәй хан илендән Чиркәс ыругы Нарын кыйсемендән йикерме яшьләрендә Эстәрлебашына гыйлем эстәр өчен килеп, голүме диния дәресләрен тәмамлап, соңра Эстәрлебашның олуг

---

[1] Сохбәт итдем – күрештем, сөйләштем.
[2] Аллаһүммә әгъфәһү – Йә Алла, аны гафу ит.
[3] Бакыйят әс-салихатларында – изге эшләрендә

хәлфәләрендән булып, күп еллар дәрес белән мәшгуль булып, 1919 нчы миладидә иржәгый илә раббикә[1] әманәтенә буйсынып, әманәт җанны җәнабе Хакга тапшырып, Эстәрлебашның олуг мәкъбәрәсендә мәдфүндер. Язулы ташы һәм бардыр.

8. Безем остамыз Габделкәбир хәлфә Динмөхәммәд углы (Сатиев) әл-Арыслани Эстәрлебашка якын Тәтер Арслан авылындан килеп, дини голүме гарәбияне тәмамлап, соңра Эстәрлебашында мөдәррис-укытучы хәлфә булып калмышдыр. Мәрхүм яхшы мәгълүматлы голуме ризатия (фән гыйльме) бик оста булып, хисап, җәгърафия вә тарихдан һәм шәкердләрне осуле җәдидә тәртипле йиңел ана телендә укытуны бик тиешле дип сөйләр иде. Безем гасырымызда гәзитләрнең ни идекене безем Эстәрлебашында белмәсләр. Ул мәрхүм шул вакытда Бакчасарайда мәрхүм Исмәгыйль Гаспринский тарафындан нәшер иделмеш "Тәрҗеман" гәзитәсен 1 нче елындан башлап, ахыр гомеренә кадәр алып укыды һәм без шәкердләргә кич дәресдән соң б чакырып, укып күрсәтер иде һәм әйтер иде: "Бер заман килер, бондай гәзитәләр күп булыр. Шуның өчен сезләрне укуга үгрәнеп калсынлар дип укытдым", - дияр иде. Остазым Габделкәбир хәлфә 1317 нче сәнәи һиҗриядә вафат булып, Эстәрлебаш олуг мәкъбәрәсендә мәдфүндер, язулы ташы бардыр. Мин фәкыйрь йиде яшемдән башлап, бу мәрхүм хәлфәнең кулында хәрефдән башлап уналты яшемә кадәр сабак укыдым. 1896 нчы елларга кадәр Бакчасарайдан осуле җәдидә белән укыла торган китапларны почта белән алдырып, яшь шәкердләргә төрки телендә шуны укытыр иде. Минем үземә шул 7-8 яшьләремдә хисапдан җәдвәлны ятлап, дүрт гамәл хисапны үгрәтде. Аллаһ рәхмәтендә булсын, юкарыда язылып үтмешдер. Тарихи җәгърафиян зур китапларымыз вар иде. "Ибне Халдун тарихы", "Тарихе Тәбари" вә башкалардан күп иде. Шул дәрәҗәдә гыйлем сөюче булды ки, "Тәрҗеман" гәзитәсенең ахыр гомеренә кадәр чыкган гәзитәне китап рәвешендә җилдләп, олуг ничә җилдләр саклап калдырды. Гәзитәдә бәгъзе мәкаләләрне тикшереп, үзенең фикерене читләренә язып куяр иде. Аллаһ рәхмәтендә булсын.

9. Габдерәхим хәлфә табиб Шәгъбанов Богырыслан өязе Мөэмин авылы (Тамьян)ндан килеп, Эстәрлебашында укып, хәлфә булып, күп еллар дәрес укытып, байтак гына имамлар чыкармышдыр һәм гыйльме тыйбда яхшы галим булып, безем гасырымызда күп рәнҗүләргә дәва кылып, бичараларның хәятына сәбәп булды. Гыйльме тыйбда күп китаплары бар иде. Һәр көн китап карап, яз булса, яландан табигатьнең һәртөрле сачкә вә үләнләрне җыеп, үзе дару кылыр иде. Халык белән катышып йөрмәде. Һәрвакыт эш белән мәшгуль булып, гөл бакчалары игеп, бик яхшы сачәкләр

---

[1] Иржәгый илә Раббикә – Раббыңа кире кайт.

үсдерә иде. Безем тау буйларында үсә торган хуш исле чабыр үләнләрендән хуш исле майлар үзе чыгарыр иде. 1905 нче елларда булса кирәк, Эстәрлебашындан күчеп, туган авылына кайтып, имам булып, дәрес әйтеп, шул Мөэмин авылында мәдфүндер. Габдрахман исемле һәм Гобәйдулла исемле угыллары булып, олуг инкыйлаб заманында мәхбүслек йөреп вафат итмешләрдер. Аллаһның рәхмәтендә булсыннар. Мәзкүр Габдерәхим хәлфә бик фазыл, тәкъва гыйлем әһеле иде.

10. Фәтхулла хәлфә Фәттахетдин углы Бәләбәй өязе Усак Кичү авылындан килеп, Эстәрлебашында дәрес укыб һәм шунда хәлфә булып калмышдыр. Мәрхүм ничә еллар Эстәрлебашында дәрес укып, күп кенә имам вә мөдәррисләр нәшер итде. Фәкыйрегез дә бу рәхмәтле Фәтхулла хәлфәдән алты-йиде ел дәрес укып, соңра аның мәдрәсәсендән 1906 нчы елда Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә сәфәр итдем. Мәрхүм Фәтхулла хәлфә бик аз сүзле һәр төрле гыйлемдән хәбәрдар улып, соңгы көнләрдә күп Басра вә Истанбул голямәләре тарафындан язылмыш әсәрләрне бик нык мөхакәмә кылып[1] укыр иде. Диндә булган күп хорафатларны аңлар иде. Бөтен гомере китап карап, шуның берлә мәшгуль булды. 1920 нче елларда туган авылы Усак Кичү карьясенә күчеп кайтып, анда берничә еллар гыйлем юлында хезмәт итеп, шул карьядә ахыр нәфесне җәнабе Хакга тапшырып, Усак Кичү авылының мәкъбәрәсендә дәфен кылынмышдыр. Рәхмәтуллаһи галәйһә рәхмәтән васигатән. Габделмәҗид исемендә бер углы, Зөһрә исемле бер кызы калып, ошбу көндә углы шул ук карьядә мөгаллим булып тормакдадыр. Яхшы инсафлы мөгаллимләрдән мәхсүб булып[2] хезмәт итмәкдәдер, Зөһрә мөгаллимә булып хезмәт итмәкдәдер, мин фәкыйрь, 1955 нче елда барып, каберенә зиярәт кылдым, Аллаһ мәгъфирәт итсен. Амин.

11. Фәхреддин бине Хөснеддин Хвалынь өязе Шиков волосе Мастәк авылындан Эстәрлебашына килеп, дәрес укып, соңгы көнләрдә Эстәрлебашында хәлфә булып калмышдыр. Гыйльме кыйраәткә маһир булып, күп шәкердләргә гыйльме кыйраәт укыр иде. Байтак кына имамлар чыкармышдыр. Кыйраәтне шул ук Хвалынь өязендә мәшһүр Бәдреддин карыйдан алмышдыр. Бу Бәдреддин карый күп еллар Оренбург шәһәрендә вә башка урыннарда Коръән хәтем кылып, сукыр булуга карамасдан, авылында үзе терекчелек кылып яшәмешдер. Углы Гасыйм исемендә Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә 10 еллар гыйльме Коръән кыйраәт сәбга вә гашәрә белән Кәлямулланы хифыз итмешдер. Фәкыйреңез бу Гасыйм әфәнде белән Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә Бәшир Али мәдрәсәсендә бәрабәр торып, һәрвакыт хаҗ сәфәрендә бәрабәр йөрер идек. Мәрхүм яхшы хәлим, ачык йөзле бәндә

[1] Мөхакәмә кылып – тикшереп.
[2] Мәхсүб булып – саналып.

иде. Хәрам Шәриф нәбәвидә ихсан шәрифдә тәравих намазында бәрабәр хәтем итдек, рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән, амин.

12. Мәрхүм вәлидемез Шәйхелислам Габделкадыйр углы. Минзәлә өязе Сарман районы Татар Карамалы авылында йикерме яшьләрендә Эстәрлебашка килеп укымышдыр. Яшь вакытында Ык буе Олуг Чакмак карьясендә Габдулла хәзрәт Гафуров мәдрәсәсендә бераз укып, андан Эстәрлебашына килеп, Хәлилулла бине Рәхмәтулла хәлфә мәдрәсәсендә укып, соңра Хәлилулла хәлфә җәмәгать алып биреп, Казакъстан Бүкәй иле Таловка дигән районда Исәнбай авылында анамыз белән бәрабәр балалар укытып, берничә еллар торган булса, Эстәрлебашда мәшһүр Мөхәммәдхарис хәзрәт гасырында булмышдыр. Шундан 1882 нче елда Эстәрлебашка күчеп кайтып, шул ук Хәлилулла хәлфә мәдрәсәсендә Эстәрлебаш авылының эшче фәкыйрьләр балаларын укытуга тәгъйин кылып, кырык ел ошбу укытуда дәвам итеп, 1918 нче елда дарелбәкая күчте, Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә дәфен кылынды. Үз кулым белән ләхеткә салдым, Аллаһ мәгъфирәт әйләсен. Мәрхүм атамыз бик әһле гыйбадәт улып, үз гомерендә бервакыт намазны вакытындан калдырмай ахыргы көнендә өйлә намазны укып, чалмасын намазлыкына куеп, шул тәһарәте белән әманәт җанны тапшырды. Хәтта поездларда йөргән вакытларында да бервакытта намазны вакытындан калдырмай укыр иде. Анамыз мәрхүмә шулай ук әһле гыйбадәт улып, кадрел-халь гомер буенча Эстәрлебаш кыз балаларыны укытып, әманәт җанны атамыз белән бәрабәр 1918 нче елда тапшырып, Эстәрлебаш олуг мәкъбәрәсендә дәфен кылынды. Үз кулым берлән ләхет куенына салдым, Аллаһ мәгъфирәт әйләсен, амин.

13. Әбүнәгыйм хәлфә Мөхәммәдьяр углы Бәләбәй өязе Чокадытамак вулысындан Исламбәк авылыннан килеп, Эстәрлебашда укып, хәлфә булып калмышдыр. Яхшы голүме гарәбиядә галим кеше һәм күп еллар Эстәрлебашда дәрес әйтеп имамлар чыкарды һәм игенчелек илән вә башка кәсепләрдә булып, сахибе дәүләт булып яшәде. 1930 нчы елларда вафат булып, Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә мәдфүндер. Эстәрлебашында безнең гасырымызда булган яшьрәк хәлфәләрдән:

14. Хаҗиәхмәд Хәлилулла углы бабамыз Вәлиулла Рәхмәтулла углы белән бертугма агамыз Эстәрлебашда тугып-үсеп, ахырында Уральски обласы Ялпактал (Сламихин) казачий поселкасында Гобәйдулла хәзрәт Галикәев мәдрәсәсендә укып, 1889 нчы елларда кайтып, хәлфә булып дәрес укытды, күбрәк шәкердләре Дим буе Мәнәвез авылында һәм Кырга Канбәк авылларындан булыр иде. Бичара гомер буе хибес[1] юл белән мөбталә[2] булып,

[1] Хибес – кулга алыну.

[2] Мөбталә – дучар.

Эстәрлебашында 1916 нчы елларда вафат була, Эстәрлебаш олуг мәкъбәрәсендә атасы Хәлилулла Рәхмәтулла углы кабере янына мәдфүндер, язулы ташлары бар, Аллаһ җөмләсене мәгъфирәт кылсын, амин.

15. Әхмәдгали хәлфә казакъ таифәсендән Баймөхәммәд углы Эстәрлебашда укып, соңра хәлфә булып, байтак еллар дәрес укытды, 1925 нче елларда Дим буе Мәнәвез карьясендә имамлык барып, шунда берничә еллар соңра инкыйлаб вакытында мәхбүс була, Уфа хибесханәсендә вафат булмышдыр. Аллаһ гафу итсен. Бераз кыз балалары булса кирәк, кайда таралып беткәнләрдер, мәгълүм имәс.

16. Таһир Әхмәджан углы Нуриманов Минзәлә өязе Әлем авылындан килеп, Эстәрлебашда укып, берничә еллар хәлфә булып, соңра 1919 нчы елында Эстәрлебашның өченче мәхәллә мәсҗеденә имам булып тәгаенләнеп хезмәт итә, 1928 нче елда Эстәрлебашда олуг нахак Галиев вакыйгасы мөнәсәбәте белә 3 елга Себергә нәфи кылынып[1], сәламәт кайтып, Эстәрлебашка якын Әнәч авылында имам булып торган вакытында икенче мәртәбә 1939да янә мәхбүс булып, Уфа төрмәсендә мәзлум вафат булмышдыр.

17. Эстәрлебашында иң карт хәлфәләр исемендә йөргән Биктимер хәлфә Галиәкбәров Оренбург губернасы Таймас авылындан килмешдер. Бөтен гомере буенча мәсҗеддә гыйбадәт белән мәшһүр булып, ничә ни еллардадыр, хәтеремдә юк, ару гомергә ирешеп, 96 яшендә Эстәрлебашында вафат булып, олуг мәкъбәрәдә мәдфүндер. Язулы ташы бардыр. Аллаһ кылган гыйбадәтләрене кабул әйләп, иман берлә мөшәррәф булган бәндәләре җөмләсендән әйләсен, амин.

Башка безем гасырдашларымыздан аз вакыт булса, хәлфә намыны алып укыта башлаучылардан Габдрахман Гали хәлфә углы Мәҗид Хәсәнов, Фәхреддин хәлфә углы һәм минем шәрикем Габдулла Габделкәбир угыллары вә башкалар булып үтде.

***Эстәрлебашда булып үткән хафизе кәләмуллалардан.***

1. Шәмседдин суфый Эзәк авылындан;
2. Аның шәкерде Габделкәбир суфи;
3. Эзәк авылындан мәзкүр Шәмсетдин карыйның нәбирәсе булса кирәк[2].
4. Фазлыәхмәд карый.
5. Сукыр Шакир карый.

---

[1] Нәфи кылынып – сөрелеп.
[2] Исеме билгеле түгел.

6. Миргали углы Әхмәров Каргалыда хифыз кылып, соңгы көндә безнең гасырымызда Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә булып, сәламәт кайтып, 1910 нчы елларда булса, Бөре өязе Бөре авылында вафат булмышдыр. Аллаһ мәгъфирәт кылсын.

7. Янә Шакир карый – Яшерган авылындан Эстәрлебашында Гали хәлфә мәдрәсәсендә хифыз кылып, соңгы вакытда Дим буе Канбәк авылына имам булып, шунда вафат булмышдыр[1].

8. Хәсән карый сукыр Габдерәхим хәлфә мәдрәсәсендә укып, хифы з кылып, бәгъзе бер авылга чыгып, рамазанда хәтем кылып иде. Минем ут күршем иде. Кылган хәтемләрене Хода кабул әйләсен, амин.

9. Габдессабир суфи Габдерәхим хәлфәдә укып, карый булып, Эстәрлебаш мәсҗедендә 1923 елларда хәтем кылып үтде. Богырыслан өязе Тамьян (Мөэмин) авылындан минем алдымда да бераз Коръән тәҗвид үгрәнде, атасы Габделкаһир исемле иде. Бик яхшы бабай иде. Бу да 1932 нче елларда вафат булып, Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә мәдфүндер. Аллаһ мәгъфирәт әйләсен, амин.

10. Сәмигулла карый Эстәрлебашының Гобәйдулла Габдулла углы Монасыйпов вә Эстәрлебашында Таһир муллада хифыз кылып, рамазанда хәтем кылып, яшь вакытында вафат була, Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә мәдфүндер.

11. Габделвахид Әбүнәгыйм углы Монасыйпов яхшы хафизлардан булса да, хәтем кылмады, яшь вакытында 1931 елларда вафат булып, Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә мәдфүндер. Баласы юк, җәмәгате Гайшә Габдрахман төрек кызы Төхфәтуллина иде, хәзер дә сәламәтдер.

12. Ахыргы карыйлардан булса кирәк, фәкыйреңез Габделмәҗид карый бине Шәйхелислам Кадыйров Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә Хәрам шәриф нәбәви Кәлямулланы хифыз кылып кайтып, Эстәрлебаш мәсҗедендә 1925 елда бер кәррә хәтем кылдым. Кылган хәтемемезе Хода кабул әйләп, риядан ахыр сулуда азат әйләп, мөшәрәф итсә иде, амин. 1926 елында Идел буе Җиргән авылында хәтем кылып, 1927 нче миладия Оренбург шәһәрендә Хөсәеновлар мәсҗедендә имам Габделхәлим Дәүләтшин чакыруына бинаән, шул ук елда Кәрвансарай мәсҗедендә хәтем әйтдем, имамы Нигъмәтулла хәзрәт Тимәшев иде.

Эстәрлебашда Мәккәи-Мөкәррәмәйә барып хаҗ кылган кешеләр безем гасырымызда Зәйнулла хәзрәт Галикәев, Гаид хәлфә Фәйзуллин, Хөсәен хаҗи Кәримов, Габделкадыйр мәхдүм Тукаев, Габдерәхим Гали хәлфә углы

---

[1] Безем гасырымыз Эстәрлебаш мәсҗедендә 10 еллар кадәр рамазанда хәтем кылып, ахырында Эзәк авылында вафат булып калмышдыр. Яхшы хафиз, мөттәкый бәндәләрдән иде, кылган хәтемләрне Аллаһ кабул итсен, амин.

Чалатаев, Бәхетгани Мөхәммәдьяров, Габдерәкыйп Назыйров, фәкыйреңез Габделмәҗид бине Шәйхелислам Кадыйров, Габделмәҗид Әхмәрев, Габдулла бине Габделкәбир Сатиевлардыр.

***Заманымда фәкыйреңез тарафындан Коръән һәм кәлямулланы хифыз кылдырган шәкердләремдән:*** 1. Габдулла бине Зәйнулла хәзрәтнең углы Габделгазиз, 1910 нчы елда хифызны тәмамлап, яшьлекдә вафат булды.

2. Габдессабир карый кәлямулланы тәкрар кылып, алдымызда байтак хаталарны төзәтде. Хәзерге көндә сәламәт Федор районы Әтәч авылы Сәгыйдетдин мулланың углы Мөхәммәдшин 1921-1922 сәнәләрдә Эстәрлебашында алдымызда кәлямулланы хифыз кылып, 1 нче мәртәбә хәтем Эстәрлебашында бу карый мәхәллә дә хәтем кылды, хәтемендә үзем самигъ булып тордым. Хәзерге көндә Оренбург (Чкалов) шәһәрендә яшидер. Мәхәллә әһалисе каршысында бик мөхтәрәм булып, истикамәт белән карыйлыкында дәвам итәдер. 1954-1955 нче елларда хәтемендә булдым. Әһали мәхәллә бик разый булып, фәкыйреңезгә дә ихтирам белән дога кылмакдалар, Аллаһ кабул итсен, амин. Бу шәкердемнең хода гомеренә бәрәкәт биреп, безләрнең садакаи җарияләре булып калса иде.

Кәлямулланы дөрест уку, янә Хода хозурында, инша аллаһ, мәшгуль булмасам кирәк дип, өмидемез бик зурдыр. Үзем карый булуымдан башлап, рамазан шәрифләрдә тәравихда хәтем кылган урынларымыз: 1. 1326 сәнәи һиҗриядә 1908 нче миладия Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә Хәрам шәриф нәбәвинең “Раузаи мотаһһарә”сендә 23 тәварихда хәтем идеп, хәтем кичәсендә замандаш рафикъларым һәм Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә мөхтәрәм остазларымызны хәтерләп, хәтем догасы кылып тәмам итдем.

2. Мәдинәи-Мөнәүвәрәдән 1908 нче миладидә август аенда сәламәт Эстәрлебашына кайтып, шул ук елның рамазанында өемездә ата вә анамызны артдымызда куеп вә башка күрше вә дуст-ишләремез тәравихда хазир булып, 14 нче рамазанда хәтем әйтдем, Аллаһ кабул итсә иде, амин. Артымызда карый Габдессабир суфи самигъ булып, хәтем кичәсендә мәхәлләнең хәзрәт вә хәлфәләре хазир булып, күпчелек белән хәтем догасыны кылып тәмам булды.

3. 1909 нчы миладиядә Урал обласе Җаек суы буенда Илбишин[1] дигән Карач авылында шундагы сәүдәгәрләрдән Мөхәммәдҗан Манҗуков дигән кешенең чакыруы буенча Ялпакталдан килеп, 1 нче рамазандан башлап 10 нчы рамазанда хәтемемне тәмамладым, Хода кабул әйләсен, амин.

4. Мәзкүр Урал обласе Ялпактал (Сламихин) дигән казачий поселкасында мәрхүм Вәли Нигъмәт Гобәйдулла бине Зәйнулла Галикәевнең

---

[1] Лбищенск.

илтимасы[1] буенча 15 нче рамазан башлап 27 нче рамазанда хәтememне тәмамладым, хода риядан кылмай мәкъбүл[2] гамәлләрендән кылса иде, амин. Мәрхүм хәзрәт вә башка мәхәлләнең әһалиләре мәмнүн булып[3], хәзрәте өстемезгә бер сары төсдә чапан кидерде, “рәхмәт, балам, гомереңезне заяга кылмагансыз икән” дип, дога кылып, рәхмәт укыды.

5. Дим буе Никифар дигән авылда 1910 нчы сәнәдә киявемез Сәмигулла Абдуллин чакыруы буенча 14 көндә хәтемне тәмамлап, Эстәрлебашка кайтдым. Хода кабул әйләсен, амин.

6. Эстәрлебашында икенче мәртәбә өемездә хәтем әйтдем рамазан шәрифдә.

7. 1926 нчы миладиядә Ак Идел буе мәшһүр Җиргән дигән карьядә мәхәллә имамы Фатих Кәримовның чакыруына бинаән, 14 көндә хәтем идеп, Эстәрлебашка кайтып, бу мәхәлләнең әһалисе 1905 нче миладиядә Кәррә чуаш исемендә йөреп, ахырында падишаһ хөкүмәтендән күп еллар үзләренең ата-бабаларындан мөселман булып, кай замандадыр килгәнлек исбат кылып, падиша хөкүмәтенең исламияткә кире кайтуларына рөхсәт булып, шул 1905 нче миладиядә мәсҗед салып, йикерме ел тулу мөнәсәбәте белән безләрне рамазанда хәтемгә чакырдылар. Мөселман булган, йитмеш хуҗалык булып, исламиятләрендә бик мөхкәм[4] булып, ислам нуры белән мәнсүр[5], тыныч вә рәхәт яшәмәкдәдерләр.

8. 1927 нче миладия Оренбург шәһәрендә (Чкалов) Хөсәеновлар мәсҗеденең имамы мәрхүм Габделгалим бине Галләм Дәүләтшин хәзрәтнең чакыруына бинаән, 1 нче рамазандан башлап 14 нче рамазанда хәтемне тәмам кылып, шәһәрнең Балыклы (Озеро) мәхәлләсендә дә күп кешеләр тәравихда булдылар, Аллаһ кылган гамәлләремезне кабул идеп, Коръән әһлендән булып, Ходага әманәт җанымыздан насыйп итсен, амин.

Оренбургда бу ике хәтемездә мәдрәсәи Хөсәения мөдәррисләрендән Габдерәхим карый бине Хәсән самигъ булып торды. Ул вакытда 60 яшьләрендә булса кирәк. Яшь вакытында Истанбулда укып, углы талибләрдән улмышдыр.

Бу хәтем тәмам булгач, Оренбург шәһәрендә мәшһүр 1842 нче миладиядә бина кылмыш Кәрван сарай мәсҗеденә мөхтәсиб һәм имам Нигъмәтулла хәзрәтнең мәслихәте буенча 16 нчы рамазанда һәм икенче имам Габделкави бине Фатих нумерымызга килеп: “Безләрнең мәсҗедемездә хәтем кылсаңыз икән”, - дип илтимас кылдылар. “Безләрне Дәүләтшин

[1] Илтимасы - үтенече
[2] Мәкъбүл – яхшы табылган, кабул ителгән.
[3] Мәмнүн булып – риза булып.
[4] Мөхкәм – нык.
[5] Мәнсур – өстен.

Габделгалим хәзрәт чакыртып килтермеш иде. Аңарга мәслихәт кылдым, Мәслихәт, барыңыз, дисә, барырмын, килеп җавап алырсыз” дия кайтардым, янәдән килүләренә: “Яхшы, барырмын” - дип җавап бирдем. Шул ук 16 нчы рамазан кичәсендә барып, хәтем башладым, үземезне Кәрвансарай өендә торырга кушдылар, Аллаһ рәхмәт итсен, мөәзин әфәнде һәм рафикасы 15 көн буенча тәрбияләп хөрмәт итделәр. 24 нче рамазан кадер кичәсе көн хәтемемез тәмам булды. Кадер кичәсе булу мөнәсәбәте беләң Оренбургның һәр мәхәллә имамлары вә карыйлары Төркестандан мөфти булып килмеш дамеллалар хәтемемездә иштиракь кылдылар[1]. Авылдашымыз мәрхүм Мөхәммәдшакир бине Харис Тукаев хәзрәтләре дә хәтемемездә әһалигә бераз нотыклар сөйләп, дога кылып чыкдык. Хатын-кыз кардәшләремездән күп кенә кешеләр хәтем көнендә мәсҗеднең югары урыныда торып укыдылар, риядан булмай гамәлемез Хода ризалыгы өчен булса иде, амин.

1925 нче миладида Эстәрлебаш олуг мәсҗедендә 15 көн хәтем әйтдем. Мәхәллә имамы Габделгалим бине Хәбибулла бине Харис Тукаев иде. Мөхтәсиб – Мөхәммәдшакир бине Харис Тукаев иде. Мәхәлләнең мөтәвәллиләре[2] килеп, илтимас кылуларына муафыйк хәтемгә шөругъ кылдым[3]. Мөтәвәллиләрдән борадәремез Мөхәммәдшакир бине Хәлилулла хәлфә, Габделҗаббар бине Гатаулла Искәндәров һәм башкалар иде. Аллаһ тәбарәк хәтемләремезне кабул әйләгәй иде. Гомеремдә ун мәртәбә хәтем булып, шундан 1927 сәнәдән соң хәтем кыла алмадым. Сәбәбе – Русия олуг инкыйлаб булу сәбәпле, хәтемдән туктап калдым. Башымызга төрле бәлаләр дә вакыйгъ булды. Югарыда язылып үтде.

Безем гасырымызда Эстәрлебашында рамазан шәрифдә ахыргы унында хәзрәтләр һәм хәлфәләр.

Картлар игътикяфкә[4] керерләр иде. Ун көн буенча мәсҗеддә гыйбадәт кылып, шунда сәхәр вә ифтар кылып, көн буенча гыйбадәт вә Коръән укучы мөдәррис вә хәлфә – шул көнләрдә мәсҗеддә дәрес бирерләр иде. Фәкыйреңез дә мөхтәрәм Хәбибулла хәзрәтнең дәресендә булып, сәид ән-нәби фикъһдан, китап әл-кыйраәтдән тәдрисендә[5] булдым. Игътикяф вакытында мәсҗеддә йөздән артык адәм ятыр иделәр. Һәр елны кадер кичәсе ахшамында мәрхүм Габдулла хәзрәт бине Харис мәсҗедкә яткан адәмләргә ифтар кыладыр иде. Бу Хода ризалыгы өчен булган гаедне ахыр вакытына кадәр дәвам итдерде. Аллаһ гамәлләрен кабул кылып, ахирәтдә алдында насыйп итсен, амин. Янә ошбу игътикяф көнләрендә һәр көн ун хәлфә

[1] Иштиракь кылдылар – катнаштылар.

[2] Мөтәвәллиләре – мәчет, мәдрәсә эшен башкаручылар.

[3] Шөругъ кылдым – керештем.

[4] Игътикяф – изге саналган урыннан (мәчеттән) чыкмый берникадәр вакыт гыйбадәт кылып уткәрү.

[5] Тәдрисендә – дәресендә.

өйләдән мөкаддәм “Сахих әл–Бохари” китабыны укып тәмамлар, ахыргы көндә дога мәҗлесе булыр иде. Кичәсендә һәр сәнә тәравих намазында хәтме Коръән кылыр иде. Безнең гасырымызда иң хәтем кылган карый Габдкелкәбир суфи булды, андан соң аның шәкерде Эзәк авылы Фазыл-Мөхәммәд карый, Габдессабир карый, иң ахыргы вакытда фәкыйреңез хәтем кылды, хода кабул әйләсен. Гаед корбаны җәй көннәрендә килгән вакытда Тукаев хәзрәтләре барча араларында чалмыш корбан итене бергә җыеп, яланга чакырып, бөтен Эстәрлебаш вә башка күршеләрдән халыклар чакырып, шунда әһалигә ашатырлар иде. Ике йөз, өч йөз кадәр кеше булыр иде. Хәтта баралган ир, сабый балалардан берсе дә калмас иде. Кырык-илле чиләк сыешлы зур казанлар асып пешерерләр иде. Бу мәҗлесләр Эстәрлебашда мәшһүр Калячник борыны дигән урында, бәгъзе вакыт мәсҗед урманы буенда булыр иде. Бу җыелышда төрле бәйге: ат чабар, адәм йөгерешдерү кебек уенлар булыр иде. Йикерме аршын озынлыгында очына киртә кайрысын аерып, юешле хәлендә йиргә карап ултырып, шуның башына балалары үрмәләп менәргә тырышырлар иде. Кем менеп йитсә, аңар мәкянәт[1] бирелер иде. Янә бер киртә ултыртып, шуның очына аркылы ярты аршин озынлыгында бер агач кадаклап, шул агачка 15-20 тиенлек көмеш тәңкәне бер генә кыл белән асып куярлар иде. Кем дә кем мылтык белән шул тәңкәне атып төшерсә, аңар мәкянат бирелер иде. Янә башка уенлардан батырлар көрәше вә буйга, югарыга сикертү, бер-берен муенчасына аркан киеп тартырга тырышырлар иде. Кем алга чыкса, шул мәкянәт алыр.

Шулай итеп, уен тәмам булгач, 15 шәр кешедән хисаплап, йикерме-йикерме биш табын кылып, йитәрлек итеп, һәммәсенә кашык, ашъяулык таратып булгач, һәркемгә берәр табак аш бирерләр иде. Яшь балаларны үзенчәләрен аерып, ничә табын ясап, аларга да шул ук аш бирерләр иде.

Безем гасырымызда, 1896 нчы миладиядә булса кирәк, Николай икенче Александр углы атасы үлгәндән соң, тәхеткә ултырыр исеме булды. Майның 6 нчы көнендә шул мөнәсәбәт берлән безем Эстәрлебашда мәшһүр Тукаев хәзрәтләре вә башка карья әһалисенең иттифакы белән (коронование) падишаһның хөлус көн дип бер бәйрәм көне кылдылар. Бөтен авыл, тирә-як күрше рус авыллар, башка хөкүмәт түрәләре иштиракь итделәр. Бу җыелыш Эстәрлебашының түбән тарафында, зияратдан түбәнрәк Саз каршы дигән тагы башында булды. Таг башында чатырлар (палатка) корып, биек эскәнбикәләр эшләнде, килгән кунакларга чатырда чәй бирелде. Олуграк кешеләргә вә башка килмеш диһканләргә[2] эскәнбикә каршы өстәлләр куеп,

[1] Мәкянат – дәрәҗә, урын.
[2] Диһкан – крестьян.

шунда чәй бирделәр. Тәхминән[1], бер-ике мең кеше булса кирәк, мәйдан уртасына: “Ходa, падишаһны сакла!” дия русча флаг язылып, юкары бер капкага эленгән иде. Төш вакыты йитде, бөтен мөселманлар өйлә намазы зур җәмәгать берлә укып, соңрак Коръән тилавәт кылынып,[2] дога кылынды. Соңра бәйге башланды: ат чапдыру, кешеләр йөгертү, көрәшү вә башка уенлар булды. Ат Эстәрлебашка 18 чакрым Баим авылындан йибәрделәр, алдагы атка көмеш савыт, бер шәл бирделәр, йөгергән кешеләргә Эстәрлебашка ике чакрымдан артыграк Мәкъсуд авылындан башлап йөгерделәр. Бакый авылының бер башкорт алдан килә, аңа бер чапан мөкяфәт[3] бирелде. Башкаларына сөлге вә яулык кебек бүләкләр бирелде. Хәзердә бу тауны Кярнавайнә тавы дип исем бирмәкдәдерләр. Мәрхүм остазымыз Хәбибулла хәзрәт шул кичкә каршы җәмәгать вә балалары белән Уральскига сәфәргә китде. Мәҗлес тәмам булып, кичен халык шад булып таралдылар.

1915 нче миладиядә герман сугышы вакытында Русиягә күп әсирләр килү сәбәпле, шуларга Эстәрлебашында бер ярдәм кылу җәмгыяте ачылды. Һәркем ихтыяри 3 сум акча түләп, әгъза булдылар. Мин фәкыйрь дә әгъзалардан булып, яз көнендә әсирләр файдасына бер сабан туе ясауга карар кылынды. Хәтеремдә юк, май аеның ничәнче көне иде, сабан туена 50 тиен билет белән керергә булып, туй булды. Эстәрлебашка күрше Мәкъсуд авылы түбәнендә Хәсәнша аганың текермәне йортында булды. Бик күп җәмгыять булып, атлар йөгертеп, кешеләр йөгертеп, алдагыларга мөкяфәтләр бирелде. Бу туемызда күп кенә килер булып, бичара әсирләргә ярдәм кылынды. Бу мәҗлесдә Эстәрлетамакдан күп кенә начальниклар да хазир булдылар.

Мәзкүри елда Германия тарафындан Русия каршы Төркия хөкүмәте дә мөхарәбә[4] кылды, Батум шәһәре тарафында Төркиянең Карс-Аждархан, Сарыкамыш дигән шәһәрләрендә бихарәбә булып, Байкалда, Сарыкамышда күп кенә Төркия гаскәрләре әсиргә төшделәр. Кыш вакыты иде, боларны Русиянең байтак шәһәрләренә таратдылар. Шул вакытда Уфада торучы Маһипәрвәз бикә Шәехгалина дигән ханым хөкүмәтдән рөхсәт алып, төрек әсирләренә мөселманлардан ихтыяри иганә җыеп ярдәм кылырга һәм хөкүмәт рөхсәт бирүдә мөнәсәбәте белән һәр әтрафдан иганә җыеп йибәрделәр. Бу ханымның ире кавказлы иде, күзе сукыр иде. Картлыкга йитү белән йортында гына тәрбияләнеп ятыр иде.

---

[1] Тәхминән – чама белән.

[2] Тилавәт кылынып – Коръән укып.

[3] Мөкяфәт – бүләк.

[4] Мөхарәбә – сугыш.

Бу ел 1917 нче елда булырга кирәк, фәкыйрь дә ул елларны Хәлекәй авылында хөкүмәт мәктәбендә мөгаллимлек кылыр идем. Кулымдан килгән кадәр мин аз-маз иганә, гыйнвар айларында булса кирәк, үзем Уфага барып, юкарыда язылмыш Маһипәрвәз ханымны табып, өенә кабул итде. Мәрхүм Шәехгалин әфәнде белән дә танышдырды. Кулымда җыелган иганәләрне тапшырып, рәсми квитәнсә алып, соңра рөхсәт бирмәде: “Бездә аш ашарсыз” - дия тәкрар әйтүенә бинаән, ашка торып калдым. Соңра, бәнем Төркиядә укыганлыгымны белеп, миндән байтак нәрсәләр хакында мәслихәт сорады. Өендә күп кенә әсирләргә хәзерләнгән киемләрне вә күлмәк-ыштан, тастымал, баш вә аяк киемләрне күрсәтеп, шушыларны яратырлар микән дип сорашып, бик рәхмәт укып, “бик яхшы, әсирләргә зарур киемләрене садакаи җарияләрендән булса иде” дидем. Соңра фәкыйрь дә: “Ханым әфәнде, мөмкин булса, шифаханәгә барып, шул әсирләрне барып, хәтерләрен сорасам икән”, - дидем. “Бик хуш” дип кулыма рөхсәт кәгазе язып бирде дә, тугры шифаханәсенә юнәлдем. Барып кереп, шул бичараларның әхвәлене сорашдым, күбесе авыру, тамаклары карлыкган, чөнки кыш көнендә салкын вагонларда килү сәбәпле, суык алдырганлар, андан катык сораулары сәбәпле, шифаханәдә салкын катык китереп биргәнләр. Кулымдан килгән кадәрле аз-маз сәдакамны биреп, Аллаһга әманәт улыңыз дия хәерләшеп чыгып китәм. Шушы әсирләрне зиярәтемне мосаддыйк булып[1], Хода бу зиярәтемне дәргяһ гыйззәтендә кабул әйләкәй иде. Амин.

***Үземнең гомеремдә сабый вакытдан башлап укыган остазым түбәндәге затлардыр.*** Биш яшемдә вакытымда мәрхүм атамыздан “Иман шарты” укый башлап, соңра гарәпчә “Шорутес-салават” вә “Тәгълим әс-саләт”, осуле-тәүхид вә башка шундай китаплар укыдым. Бераз гарәпчә укый башлаган соңында пиремез сарыф, нәхү укырга Габделкәбир бине Динмөхәммәд Сатиев хәлфәгә тапшырды.

Кәлям шәрифне башлап, Эстәрлебашка хәзрәтләргә зиярәт өчен килмеш Ык буе Сарлы карьясе Әхмәдиша хәзрәтдән укыдым, атамыз мәрхүм кулыма ярты Кәлям шәриф тотдырып, хәзрәтнең алдына ултырып, “Сүрәи фатиха”ны укытды һәм дога кылды. Соңра атамыз мәрхүм кулыма йикерме тиенлек көмеш акча биреп: “Бар, хәзрәткә бир”, - диде. Кулым белән бирдем дә, янә дога кылды.

Юкарыда мәзкүр остамызның бәгъзе бер әхвәле тәрҗемәсе вә фикере, дәрескә иҗтиһады хакында хәтеремдә булганларны язам. Җәннәте мәкан остамыз Габделкәбир хәлфә кыска буйлы, ияк очында аз гына кара сакаллы, кара күзле иде. Шәкердләргә бик кызу иде. Һәрвакыт дәресләрендә

[1] Мосаддыйк булып – ныгытып.

тазалыгын, хәтта шәкердләрнең ашау әсбабларына кадәр күз салып карап йөрер иде. Дәрескә бик ижтиһадлы, бер дә дәресдән калган вакытны күрмәдем. Иртә намаздан башлап өйләгә кадәр, андан икендегә кадәр укытыр иде. Кичен ястүдән соң сәгать 10-11гә кадәр мәдрәсәдән китмәс иде. Чит авылларга кунак барып йөрмәде, һәрвакыт дәресен дәвам итде. Үз гомерендә ике мәртәбә кунакга барганын беләм, ул да атна кич беренче - Карамалыга Җиһангир хаҗи җеназасына килеп алулары сәбәпле, икенче - күрше Кәркәле авылына Галләметдин Рәхимкулов җеназасына барганын беләм. Йигерме биш чакрым туган Тәтер-Арслан авылына бер вакыт да кыш дәрес ташлап бармады.

Бөтен гомере китап, гәзитә вә журналлар карау белән булды. Мәдрәсәдән кич сәгать бер-икегә кадәр мөтәләга белән мәшгуль булыр иде. Мәдрәсәдә вакытымызда кич, дәресдән соңра чакырып, безләргә “Тәрҗеман” гәзитәсен укыр иде, гәзитәгә күңел салмак идек. Шул вакытда әйтер иде: “Балалар, бер вакыт килер, шул вакытка кадәр гәзитәләрне укып өйрәнеңез” - дияр иде һәм яңа укуларга мәдрәсәдә дәрес тәртипләре куярга тырышыр иде. Һәрвакыт почта белә Бакчасарайдан “Тәрҗеман” идарәсенә язып, яңа укуга муафикъ китаплар алдыра торыр иде. Һәм безләргә дә шундай китапларны алдырып укырга нәсихәт кылыр иде. “Хуҗаи сыйбъян”, мәшкъ[1] дәфтәре вә башка китаплар булыр иде. Тарих вә җәгърафиягә күп әһәмият бирер иде. Тарих, Ибне Халдун вә башка тарих китапларымыз сөйләп, безләргә төшендерер иде. Атнага ике көн түбәнрәк шәкердләрне җыеп, хисап-счетка гыйлемләрне үгрәтер иде. “Тәрҗеман” гәзитәсене беренче елындан башлап алып, гәзитәдә язылмыш мәкаләләрне тәфтиш кылып, үз фикерләрне читенә язып куяр иде. Хәтта рәт нумерларны еллык гәзитәне китап рәвешендә төпләп куяр иде. Күп вакыты гыйлем юлында ижтиһады сәбәпле, сәламәтлекендә хәстәлек пәйда булды. Ашказаны агырып, һазым[2] тәгам кыла алмас булып, әҗәленә шушы сәбәп булды. Мондай кешеләр күбрәк шундай хәстәлекләргә очрап калулары мәгълүм. Казанда мәрхүм Шиһаб әл-Мәрҗани хәзрәтләре дә шушы хәстәлек белән вафат итмешдер. Аллаһның рәхмәтенә гарыкъ булсыннар иде, амин. Эстәрлебаш мәкъбәрәсендә мәдфүндер, 1317 нче һиҗриядә август аенда вафат, Хода җанын җәннәтдә кылсын.

“Мулла җами” укый башлагач, Эстәрлебашның олуг мөдәррисләрендән һәм Хәбибулла бине Харис хәзрәтләренә мулла җами һәм фикъһ дәресләренә барып йөри башладым. “Әт-Тарика әл-Мөхәммәдия”, “Гайнел-гыйлем” китаплардан дәрес алдым. Бәгъзе вакыт рамазан шәрифләрдә “Сиярән-Нәби”

---

[1] Мәшкъ – матур язу.

[2] Һазым – аш үтү.

китабыны һәм фикъһдән китаплар укытыр иде. Рәхмәтле остазымыз гыйрфан рәхмәтендә булсын. Бохарадан укып кайтып, мәсҗед вә мәдрәсә вә суханәләрне гыймарәт кылып, бөтен Эстәрлебашның мәдрәсәләрне бик яхшы юлга салды. Мәдрәсә араларында ташдан юллар һәм кичендә һәр урынга фонарьлар якдырдып куйды. Язын һәр мәдрәсәнең артына биек каен агачлары утыртып, бер бакча хәленә китерде. Мәрхүм гаять тугры сүзле, гади генә киемләр кияр иде. Хаклык тугрысы һичбернең хәтеренә карамас иде. Голүме гарәбиядән һәр кайу фәнләрне моталәга итде. Гыйлем әл-кыйраәтдән, тәфсир вә хәдис вә нәхү китапларын да камил шәкердләрне канәгатьләндерерлек дәрес бирер иде.

Фәтхулла хәлфә Фәттахетдин углы Эстәрлебашында укый, соңра хәлфә гонванын[1] алып, Эстәрлебаш мәдрәсәсендә күп еллар дәрес укытды, фәкыйреңез исә бу мөхтәрәм хәлфәмездән байтак еллар дәрес укыды. Бик юаш табигатьле һәм галим кеше иде. Аз сүзле, мөлаем, акрын гына дәрес бирер иде. Хәдисдән “Мишкәт шәриф”, тәфсирдән “Җәләләйн”, осуле фикъһдән “Тәүзыйх” дәресләрене укыдым. Һәртөрле китапларны мотәлага кылып, хакыйкатьне аңларга иҗтиһад кылыр иде.  Мәрҗани хәзрәт вә Муса Җарулла хәзрәтләренең китапларыны мотәлага кылып, күп вакыт дөрес фикердә булмышлар дип сөйләр иде. Башка хәлфәләр күп тәгассыблык белән мәфтүн[2] булсалар да, бу мәрхүм остазымыз анлара һәр төрле дәлилләр буенча, үз фикерене сөйләр иде. Аллаһның гофран[3] бәндәләре җөмләсендә булса иде. Һичбер кешедән тамыг кылмас[4], үз көче белән үзенә хаҗәт кадәрле иген сачеп, үзе ташып, үзе сугып, җәй көнләрендә гомерне үткәрер иде. Эш вакытларында чабата киеп йөрер иде. Тормышында бер ат, бер сыеры, башка нәрсә булмас, һичкемгә хөсетлек итмәз, барына канәгать кылып, гомерене дәрес юлында үткәрде. Соңгы гомерендә Эстәрлебашындан туган авылы Усак Кичүгә кайтып, шунда карарланып, Усак Кичү мәкъбәрәсендә мәдфүндер. 1957 нче елда барып зиярәт итдем. Аллаһ мәгъфирәт итсен. Амин.

[1] Гонванын – исемен.
[2] Мәфтүн – баш-күз әйләнү.
[3] Гофран – кичерелә торган.
[4] Тамыг кылмас – өмет итмәс.

Тышлыктагы фотолар З. Г. Валиуллова  һәм В.Галиевнең шәхси архивларыннан алынды.